4°2018

# ФӘННИ ТАТАРСТАН

ISSN 2499-9741

КАЗАН

***Журнал «2014 –2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Мэдисон)

► **БАШ РЕДАКТОР**
КИМ МӨГАЛЛИМ улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
ГОМӘРОВ И.Г., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
Я.М. АБДУЛКАДЫЙРОВА, Н.Т. АБДУЛЛИНА, Е.Ф. ЛУКЬЯНЧЕНКО

## БУ САНДА

### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Һадиева Г.К.* Татар урбанонимиясен өйрәнү тарихы . . . . . . . . 7
*Хаҗиева-Демирбаш Г.С.* Татар мифонимикасы: үсеше һәм өйрәнү перспективасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
*Сәфәров Р.Т.* Татар телендә халык этимологиясенең чагылышы . . 24
*Хөснетдинов Р.М.* «Шура» (1908–1918) журналында барган «Тел ярышы»ның татар әдәби теле тарихында тоткан урыны . . . 29

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Мәрданов Р.Ф.* Гыйлем бәйгесенә багышланган әсәр: «Дастане җайә» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
*Мортазина Л.Р.* Югалмас мирас (танылган драматург Хәй Вахитның тууына 100 тулу уңаеннан) . . . . . . . . . . . . . . . 55
*Шәмсутова А.А.* М. Юныс шәхесе һәм иҗаты . . . . . . . . . . . 60
*Сафина А.М.* Татар әдәбиятында милли характерның формалашуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72

### ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВКА – 90

*Миңнуллин К.М.* XX гасырның икенче яртысы татар әдәбиятын өйрәнү контекстында Чыңгыз Айтматов иҗаты . . . . . . . . . . . 79

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Сөнгатов Г.М.* Татар халык әкиятләрендә йорт хайваннары образларының бирелеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
*Хөсәенова Г.Р.* «Таһир белән Зөһрә» сюжетлы дастаннар: өйрәнелү дәрәҗәсе, кульязмалары һәм сөйләмә вариантлары . . . 90

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Гыйләҗев И.А.* Россия империясендә татарларның иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни үсешендә төркичелек идеологиясенең урыны (XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы) . . . 99

### МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Фәтхуллова К.С.* Яңа шартларда туган тел укытучысының методик эшчәнлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
*Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М.* Әдәбият дәресләрендә хронотопны өйрәнү үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . 111

### СӘНГАТЬ

*Гыйльметдинова О.А.* Академик сәнгати белем һәм ислам сәнгате традицияләре, аларның бер-берсенә үзара йогынтысы *(Н.И. Фешин исем. Казан сәнгать училищесы мисалында)* . . . . 118
*Мохтарова Г.С.* Корамалардан тегелгән «Кұрақ» һәм анда дөньяның мозаик картинасы . . . . . . . . . . . . . 128

**ТАБИГАТЬ ФӘННӘРЕ**

*Җиһаншин И.И.* Төбәк дәрәҗәсендәге табигый территорияләрне тотрыклы үстерү проблемалары һәм аларны хәл итү юллары . . . . . 139

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Булатова М.Р.* Тел белгече, диалектолог һәм гаҗәеп остаз *(галимә Рамазанова Дөрия Бәйрәм кызына – 80 яшь)* . . . . . . . . 145

*Гайнуллина Г.Ф., Кузьмина Х.Х.* Күңел таләбе – фән *(галимә Бәширова Илида Басыйр кызына – 80 яшь)* . . . . . . . . 150

**ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР**

*Ш. Мәрҗани*. Казан вә Болгар хәлләре турында хәбәрләр *(Икенче бүлектән)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155

*Гали Рәхим*. Иске шагыйрьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163

**ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН**

*Закирова И.Г., Хисамов О.Р., Гомәров И.Г.* Иркутск өлкәсендә узган комплекслы экспедиция турында . . . . . . . . . . . . . . . . 172

**ЯҢА КИТАПЛАР**

*Заһидуллин И.К.* Алтата авылы тарихы [Бәяләмә: Хабибуллин А.А. Алтата – татарское село в степном Заволжье] . . 178

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Хадиева Г.К.* История изучения татарских урбанонимов . . . . . . . 7
*Хазиева-Демирбаш Г.С.* Татарская мифонимика: перспективы развития и изучения . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
*Сафаров Р.Т.* Отражение народной этимологии в татарском языке . . 24
*Хуснутдинов Р.М.* Значение «языковых состязаний» в журнале «Шура» (1908–1918) для истории татарского литературного языка . 29

## ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Марданов Р.Ф.* «Дастани джайэ» – произведение о знаниях . . . . . 35
*Муртазина Л.Р.* Незабываемое наследие (по случаю 100-летия со дня рождения известного драматурга Хай Вахита) . . . . . . . . 55
*Шамсутова А.А.* Личность и творчество М. Юнуса . . . . . . . . 60
*Сафина А.М.* Формирование национального характера в татарской литературе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72

## ЧИНГИЗУ АЙТМАТОВУ – 90

*Миннуллин К.М.* Творчество Чингиза Айтматова в контексте изучения татарской литературы второй половины XX века . . . . . 79

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Сунгатов Г.М.* Образы домашних животных в татарских народных сказках . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
*Хусаинова Г.Р.* Сюжетные дастаны «Тахир и Зухра»: степень изученности, рукописи и устно-фольклорные варианты . 90

## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Гилязов И.А.* Идеология тюркизма в общественно-политическом и культурном развитии татар Российской империи (конец XIX – начало XX века) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99

## НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Фатхуллова К.С.* Методическая деятельность учителей родного языка в новых условиях . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
*Мухарлямова Г.Н., Абдуллина Д.М.* Особенности изучения хронотопа на уроках родной (татарской) литературы . . . . . . . . 111

## ИСКУССТВО

*Гильмутдинова О.А.* Академическое художественное образование и традиции исламского искусства, взаимодействие (на примере Казанского художественного училища) . . . . . . . . 118
*Мухтарова Г.С.* Мозаичная картина мира лоскутного шитья «Курак» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

## ЕСТЕСТВЕННЫЕ НАУКИ

*Зиганшин И.И.* Проблемы устойчивого развития природных территорий и пути их решения на региональном уровне . . . . . . 139

## ПЕРСОНАЛИИ

*Булатова М.Р.* Языковед, диалектолог и наставник *(к 80-летнему юбилею ученой Рамазановой Дарии Байрамовны)* . . 145

*Гайнуллина Г.Ф., Кузьмина Х.Х.* Наука как призвание *(к 80-летнему юбилею ученой Башировой Илиды Басыровны)* . . 150

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Ш. Марджани*. Использованные сведения к истории Казани и Булгар *(Отрывок)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155

*Гали Рахим*. Древние поэты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163

## ПО СЛЕДАМ ЭКСПЕДИЦИЙ

*Закирова И.Г., Хисамов О.Р., Гумеров И.Г.* О комплексной экспедиции в Иркутскую область . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172

## НОВЫЕ КНИГИ

*Загидуллин И.К.* История деревни Алтата [Рецензия: *Хабибуллин А.А.* Алтата – татарское село в степном Заволжье] . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811.512.145

*Г.К. Һадиева*

## ТАТАР УРБАНОНИМИЯСЕН ӨЙРӘНҮ ТАРИХЫ

Городское онимическое пространство формируется по определенным закономерностям, отражающим исторические, этнические, культурные и социально-экономические условия. Совокупность названий улиц, переулков, площадей, проездов принято обозначать терминами городская топонимия или урбанонимия. В статье раскрывается содержание понятия урбанонимия. Рассматриваются история изучения и развития татарской урбанонимии города Казани.

**Ключевые слова:** урбанономика, татарская урбанонимия, улица, город Казань, исторические этапы, номинация.

XX йөз урталарыннан тел белгечләре шәһәр топонимиясен өйрәнә башлыйлар. Төрле елларда Г.П. Бондарук, И.Д. Воронин, М.В. Горбаневский, К.С. Горбачевич, Ю.К. Ефремов, А.М. Мезенко, Э.М. Мурзаев, В.П. Нерознак, В.А. Никонов, Н.В. Подольская, Е.М. Поспелов, Г.Ф. Саттаров, Г.П. Смолицкая, Н.С. Студенов, А.В. Суперанская һ.б. галимнәрнең әлеге өлкәгә караган хезмәтләре басылып чыга.

Шушы чорда шәһәр объектлары арасындагы бәйләнешләрне ачыклауга һәм системага салуга юнәлтелгән типологияләр барлыкка килә. Еш кына әлеге типологияләр топонимия белән тыгыз бәйләнештә тора. Шуннан чыгып, галимнәр, аерым бер территориянең топонимнарын чагылдырган мәгълүматларга таянып, типологиянең классификациясен төзиләр. Әлеге бурыч шәһәр эчендәге объектларны төрләргә бүлү белән генә чикләнми: галимнәр, шулай ук, атамаларның барлыкка килү, алмашыну, үсеш процессларын да тикшерәләр, тарихи-мәдәни мирасны саклауга юнәлтелгән сүзлекләр, юл күрсәткечләре, карталар һ.б.ны төзиләр. Шулай итеп, тел галимнәре топонимнар системасын өйрәнүдә структур якын килү һәм аңа хас сыйфатларны, аерым алганда, территориаль беркетелү, аерым объектның үзенчәлекләрен һ.б.ны билгеләп үтәләр.

1960 елларда бу юнәлештәге эзләнүләр шактый активлашса да, 70 нче елларда урбанонимнарны өйрәнү эше берникадәр тукталып тора. Әлеге чорга караган хезмәтләрнең берсе – Н.В. Подольскаяның «Урбанонимия центральных областей РСФСР» дигән мәкаләсе. Галим беренчеләрдән булып Россиянең Европа өлешенә кергән шәһәрләрнең урбанонимнарын чагыштырма планда өйрәнә һәм системалаштыра [Подольская, с. 123–129].

1985 елда Мәскәү шәһәре урбанонимнарына багышланган «Географические названия в Москве» дигән җыентык

дөнья күрә. Бу җыентыкта төп урынны А.В. Суперанскаяның мәкаләсе алып тора. Галим урбанонимнарның, башка географик атамалардан аермалы буларак, махсус катлам тәшкил итүен ассызыклый. Аның билгеләвенчә, «шәһәр эчендәге бөтен объектлар кеше тарафыннан барлыкка китерелгән. Шуңа күрә кешенең бу территориягә бәйле башкарылган эшчәнлеге әлеге процесска турыдан-туры тәэсир итә. Нәтиҗәдә, урбанонимнар, топонимнар белән чагыштырганда, башка принципка нигезләнеп барлыкка килә һәм бик шартлы рәвештә генә топонимнар белән берләштерелергә мөмкин» [Суперанская, с. 161]. Галим урбанонимнарны урам, мәйдан, бина һәм шәһәр эчендәге башка объект атамаларының бердәмлеге, дип билгели [шунда ук, б. 72].

1994 елда М.В. Горбаневский Россия урбанонимнары системасына хас үзенчәлекләрне тулы итеп чагылдырган хезмәтен яза. Ул үзенең «Русская городская топонимия: проблемы историко-культурного изучения и современного лексикографического описания» исемле докторлык диссертациясендә Россиянең Европа өлешендә урнашкан 30 дан артык зур һәм кечкенә шәһәр урбанонимиясен тикшерә. Ил үзәгендә урнашкан шәһәр топонимнарын анализлау нәтиҗәсендә, автор урбанонимнарның төп ясалыш модельләрен ачыклый [Горбаневский, с. 432].

Шулай да әлеге хезмәт кенә урбанонимика өлкәсенә караган барлык проблемаларны да чишә алмый. Фәндә ачыкланмаган мәсьәләләрнең берсе – шәһәр атамалары типологиясенең үзгәреп торуы. Шәһәрләр киңәйгән, үскән саен яңа урам исемнәре барлыкка килә, шулай ук төрле тарихи, сәяси максатларга бәйле рәвештә бер атама икенчесенә үзгәртелә.

Р.В. Разумов рус шәһәрләре урбаноним системаларының XVIII–XX гасырлар дәверендә үзгәреш тарихларын өйрәнә. Аның «Система урбанонимов русского провинциального города конца XVIII–XX веков: на примере Костромы, Рыбинска и Ярославля» дигән кандидатлык диссертациясендә күпчелек рус шәһәрләрендә урын алган топонигезләр ачыклана. Автор шәһәр атамаларының лексик-семантик яктан кичергән эволюцияләрен тасвирлый, урбанонимнарның төрле дәверләрдә таралыш тапкан типларын тикшерә һәм аларны җәмгыятьтә барган социаль-сәяси процесслар күзлегеннән аңлата [Разумов, с. 293].

Соңгы елларда рус тел белемендә шәһәр топонимиясен тикшерүгә игътибар арта төште. Мәскәү, Санкт-Петербург, Калуга, Кострома, Тамбов, Ульяновск һ.б. шәһәрләрнең топонимиясен, урам исемнәрен, башка географик объектларның атамаларын тикшерүгә багышланган фәнни хезмәтләр барлыкка килде, кандидатлык диссертацияләре язылды. Биредә И.Б. Горланованың «Топонимия города Костромы (структура, семантика и функционирование в синхронно-диахронном аспекте)» (2006), Г.П. Смолицкаяның «Названия московских улиц» (2006),

Н.Ю. Забелинның «Московская городская топонимия структурно-семантический анализ топонимической системы» (2007), А.Ю. Асановның «Урбанонимия города Тамбова в лингвокогнитивном аспекте» (2014) һ.б.ны атап үтәргә мөмкин.

Татар урбанонимиясе мәсьәләсенә килгәндә, аның милли тарих белән тыгыз бәйләнештә торуын ассызыклап үтәргә кирәк. Бүгенге көндә борынгы татар шәһәрләре атамаларына караган мәгълүматлар сакланмаган диярлек. Урбанонимнар җәмгыятьнең сәяси, социаль, икътисади, мәдәни сфералары белән тыгыз бәйләнештә торып, әлеге сфералардагы яңарышларны чагылдырып торучы элементлар булганга күрә, аларны телнең һәрдаим үзгәрешләр кичерә торган өлкәсе итеп билгеләргә мөмкин. Мәсәлән, тарихи вакыйгаларга нисбәтле, борынгы татар шәһәрләре саналган Казан, Алат, Арча, Лаеш, Тәтеш шәһәрләрендә элеккеге татар атамалары чагылмый диярлек.

Бүгенге көндә Татарстанның Казан, Алабуга, Азнакай, Бөгелмә, Яшел Үзән, Яр Чаллы, Чистай һ.б. шәһәрләре урбанонимиясен өйрәнүгә багышланган махсус монографик хезмәтләр юк. Хәзерге чорда Татарстан Республикасының шәһәр топонимнары икетеллелек шартларында тикшерелергә тиеш, шул ук вакытта төрле шәһәрләргә караган урбанонимнарның бер үк лексик-семантик материалга нигезләнүе дә күзәтелә.

Мәкаләбездә татар урбанонимиясенең өйрәнелү тарихын Казан шәһәре мисалында яктыртырга булдык.

Казанның урам исемнәре телгә алынган, аларның урнашу тәртибе һәм урыны күрсәтелгән хезмәтләрнең эчтәлекләре һәм жанрларына карап, Г.Ф. Саттаров аларны өчкә аерып карый:

1. Казан шәһәре тарихын өйрәнү белән мөнәсәбәтле рәвештә аның урамнары турында беркадәр сүз алып барылган тарихи очерклар.

2. Казан буенча юлъкүрсәткечләр.

3. Казанның кайбер урам яки башка объектларының исемнәренә лингвистик күзәтүләр ясалган мәкаләләр [Саттаров, 1971, б. 47].

Казан шәһәренә багышлап, күпсанлы тарихи очерклар, китаплар язылган. Платон Заринский «Очерки древней Казани» дигән хезмәтендә Казанның топонимиясе, төзелү урыны турында яза. Бу хезмәтендә автор XVI йөзнең икенче яртысындагы Казанның топографиясен тасвирлый, шәһәрнең кайбер географик объектларының исемнәренә туктала [Заринский, с. 220].

Н.А. Спасскийның «Очерки по родиноведению. Казанская губерния» дигән хезмәтендә Казан шәһәре һәм аның урамнарының тарихын яктыртуга зур урын бирелә. Автор Казанның күп кенә урамнарын, бистәләрен, мәйданнарын һәм башка объектларының исемнәрен атый, аларның кайсы гасырда һәм ни сәбәпле барлыкка килүләрен тасвирлый. XX гасыр башында Казанда барлыгы 230 урам булып, аларның гомуми озынлыгы 122 чакрымга җитүен ассызыклый [Спасский, с. 245].

Тарихчы Н.Ф. Калинин 1929 елда басылган «Казань XVIII века» дигән мәкаләсендә Казан топографиясен шактый тулы итеп тасвирлый [Калинин, с. 119–130].

XIX йөзнең икенче яртысында һәм XX йөздә Казан өчен байтак юл күрсәткечләр һәм адрес мәгълүматлары күрсәтелгән китаплар басыла. Алар: А.С. Дубровинның «Указатель города Казани и достопримечательностей с кратким очерком древностей Казанской губернии» (1890), П.А. Верещагинның «Указатель достопримечательностей города Казани» (1895), Н.П. Загоскинның «Спутник по Казани» (1895), М.В. Казанскийның «Путеводитель по Казани» (1899), Ш.К. Шаһидуллинның «Идел нәһерендә юлдаш» (1908) хезмәтләре; Е.Г. Бушканецның «Город Казань. Краткий путеводитель для путешествующих по Волге» (1954), «Исторические памятники Казани. Краткий путеводитель-справочник для туриста» (1959), «Казань. Путеводитель» (1961), «Казань – путеводитель» (1964) дигән юл күрсәткечләре; А.И. Григорьевның «Казанский Кремль. Краткий путеводитель» (1959); Т.С. Бобченко, А.В. Гарзавина, К.Р. Синицыналарның «Казань: Путеводитель» (1970); В.В. Кузьмин, Ю.И. Смыков, А.Х. Халиковларның «Казань – путеводитель» (1977) һ.б. юл күрсәткечләре; С.М. Шпилевскийның «Указатель исторических достопримечательностей г. Казани» (1873), Н.Я. Агафоновның «Историческая объяснительная записка наименований казанских улиц» (1899), К.Г. Козьминның «Адресная книжка г. Казани» (1906), П. Васильевның «Календарь – указатель города Казани на 1882 год» (1881), Н.Г. Шебуев редакциясендәге «Вся Казань. Адресная и справочная книга» (1899), «Адресная книга города Казани на 1906 год» (1906) .

В.И. Белокопытов һәм Н.Я. Шевченконың «Их именем названы улицы Казани» дигән хезмәтендә Казан урамнары турында бай материал тупланган [Белокопытов, с. 52].

С.А. Мартьянова «Лексика писцовых книг города Казани XVI–XVII вв.» дигән мәкаләсендә беренче тапкыр Казанның кайбер урам исемнәренә һәм башка топонимнарга лингвистик анализ ясый. Әлеге мәкаләдә автор Казан шәһәренең борынгы топонимиясен ике этнолингвистик катламга: 1) рус теленә алынган татар атамаларына һәм 2) рус теленең үз исемнәренә бүлеп карый [Мартьянова, с. 110–115].

Архитектор В.П. Остроумовның «Казань. Очерки по истории города и его архитектуры» дигән хезмәтендә татар бистәләренең һәм урамнарының тарихи планировкасы һәм исемнәренең килеп чыгышы турында сүз алып барыла [Остроумов, с. 76].

Г.Ф. Саттаровның «Ни өчен шулай аталган? Татарстан топонимнары» дигән хезмәтендә урам исемнәрен өйрәнүнең торышы, аларның элекке һәм хәзерге исемнәре, урам исемнәрен алмаштыру-яңарту, язуда дөрес чагылдыру проблемалары күтәрелә. Шулай итеп, профессор Г.Ф. Саттаров, беренчеләрдән

булып, татар урбанонимиясен тарихи һәм лингвистик яктан тикшерә [Саттаров, 1971, б. 47–79]. Шуңа нисбәтле, галим татар топонимикасы фәненең урбанонимика бүлегенә нигез сала.

1993 елда Г.Ф. Саттаров «Башкалабыз атамаларына – милли рух» дигән мәкаләсендә урам атамаларында милли үзенчәлекләрнең чагылмавы, татар урамнары исемнәренең бик азы гына татарча булуы, аларга татар халкына мөнәсәбәте булган күренекле шәхесләрнең исемнәрен бирергә кирәклеге мәсьәләсен күтәрә [Саттаров, 1993, б. 164–168].

К.Ф. Әмировның «Казань: где эта улица, где этот дом?» дигән белешмә китабында Казан шәһәре урамнары турында шактый тулы тарихи-лингвистик мәгълүмат бирелә [Амиров, 1995].

Хәзерге татар теле белемендә татар урбанонимнарының аерым аспектлары Р.М. Әмированың «Казан шәһәре татар эргонимиясе» (2013), А.Ә. Гафурованың «Специфика функционирования ономастической лексики в татарских и англоязычных рекламных текстах» (2012), Г.К. Һадиеваның «Урбанонимия города Казани» (2012), Э.Ю. Галиеваның «Особенности лексико-морфологических групп урбанонимов города Бугульма» (2013), М.Ф Низамова белән Д.А. Сәлимованың «Структурно-семантические характеристики урбанонимов (на материале онимов города Елабуги)» (http://econf.rae.ru/article/6387) хезмәтләрендә чагылыш таба

Бүгенге көндә вакытлы матбугатта татар урбанонимнары проблемасына багышланган мәкаләләр бастырыла, массакүләм мәгълүмат чараларында топонимнарны тәрҗемә итү, аларны алмаштыру, тарихи атамаларны кайтару проблемалары күтәрелә.

Лингвистлар һәм фәлсәфәчеләр фикеренчә, тел берәмлекләрендә гасырлар дәвамында җәмгыять эволюциясе нәтиҗәсендә формалашып килгән милли психология, менталитет һәм милли үзаң чагылыш таба. Татар урбанонимнарының килеп чыгышы тарихы шуның белән тыгыз бәйле. Татарстан Республикасы урбанонимиясенең күпчелеген рус атамалары тәшкил итсә дә, татар халкы бары тик үз милләтенә генә хас булган үзенчәлекләрне дә урбанонимнарга күчергән. Бу аңлашыла да: урам исемнәре җирле халыкның дөньяны күзаллавына, аның гадәт-йолаларына, тарихына бәйле.

Россия тарихына бәйле рәвештә, татар урбанонимиясен, без, түбәндәге тарихи чорларга бүлеп карыйбыз: 1) революциягә кадәрге чорда барлыкка килгән урбанонимия; 2) совет чоры урбанонимиясе; 3) хәзерге чор урбанонимиясе (1990 еллардан бүгенге көнгә кадәрге чор). Алга таба һәрбер дәвернең үзенчәлекләрен карап китик һәм татар урбанонимиясенең үсеш тарихына күзәтү ясыйк.

Борынгы Казан шәһәренә Идел Болгарстаны чорында нигез салына. XV йөздә шәһәр Казан ханлыгы башкаласына әйләнә [Фахрутдинов, с. 120]. Казан шәһәре халкын, башлыча, болгар-татарлар һәм башка җирле халык вәкилләре тәшкил

иткән. 1552 елда Казан ханлыгы рус дәүләтенә кушылгач, җимерелгән шәһәр яңадан торгызыла. Казан Кремленең чикләре киңәйтелә, яңа бистәләр төзелә. Татарлар шәһәр эченнән куылгач, шәһәргә руслар күченеп килә. Казан шәһәре дә рус шәһәрләре сыйфатларын чагылдыра башлый: борылмалы урамнар, тупиклы тыкрыклар, күпсанлы ерымнар барлыкка килә. Казан шәһәренең язу кенәгәсендә кайбер урам һәм тыкрык исемнәре *Тау өсте, Тау асты, Ерым арты, Ярык өсте* дип теркәлгән. Кабан күленең сул яры буенда *Татар бистәсе* була.

XVIII гасыр урталарына кадәр Казан ирекле рәвештә төзелүен дәвам итә. Ләкин Санкт-Петербургта оештырылган Төзелеш комиссиясе Казанны, башка 200 шәһәр белән беррәттән, регуляр план буенча төзелергә тиешле шәһәрләр исемлегенә кертә. Шулай итеп, 1767 елдан башлап, Казанда В.И. Кафтырев исемле архитектор шәһәр планы төзү эшен башлап җибәрә. Аның проектлары буенча Казанда дистәләгән торак, административ һәм дини биналар төзелә.

Бу вакытта Казан составына 9 зур урам, 170 кече урам һәм тыкрыклар, 10 мәйдан, 8 бистә кергән. Үзгәртүләр, башлыча, үзәк районнар эчендә башкарыла – шәһәр читендәге төзелеш һаман да ирекле характерга ия була.

Казан урамнары җилпәзә һәм турыпочмак системасында төзелә. Үзәк нокта булып Кремль санала, Кремльдән *Проломный, Воскресенский, Арский* урамнары сузылып китә. Төзелешнең башка юнәлешен билгеләүче булып *Болак* белән *Кабан күле* тора. Аларга параллель рәвештә *Вознесенский, Московский, Екатерининский* урамнары урнаша.

1815 һәм 1842 елдагы янгыннардан соң шәһәр үзәгендә таш биналар төзелеше активлаша. *Пләтән, Әмәт, Савин, Калуга, Игумново* исемле чиктәш авыллар шәһәр бистәләре статусы ала. *Проломный, Георгиевский, Петропавловский, Гостинодворский, Воскресенский* урамнарына таш түшәлә [Амиров, с. 7].

Бу чорда чиркәү һәм монастырь исеме белән аталган урам исемнәре күп була: *Воскресенский, Спас, Георгиевский, Петропавел, Вознесенский* урам һәм тыкрыклары; *Преображенский, Архиепископ, Федоровский, Архангель, Пләтән* бистәләре. Соңгы икесе XVII йөздә шул исемдәге монастырьларга караган авыл атамаларыннан алынган. XIX йөздә алар шәһәр эчендә калганнар, ә исемнәре урамнарга күчкән.

1899 елда гына шәһәр Думасы утырышында шәһәр башлыгы С.В. Дьяченко урам исемнәрен алмаштыру белән шөгыльләнергә кирәк дигән мәсьәләне күтәрә. Моның проектын төзү Казан тарихчысы Н.Я. Агафоновка тапшырыла. Ул шул ук елны үзенең проектын тәкъдим итә [Агафонов, 1899]. Бу проектның зур гына кимчелекләре була. Н.Я. Агафонов Казан урамнары исемнәрен алмаштыру мәсьәләсендә, югары катлау вәкиле буларак, үз сыйныфы мәнфәгатьләреннән чыгып эш итә. Ул Казан урамнарына, бе-

ренче чиратта, патшалар (*Александр II, Николай, Екатерина* урамнары), эре түрәләр, дворяннар (кенәз *Курбский*, подполковник *И.И. Михельсон*, Казан чиновниклары һәм дворяннары *М.А. Әхмәтов, И.С. Жарков, Ф.Н. Хворов*) һәм бай сәүдәгәрләрнең (*Г.Д. Чепарин, В.П. Ложкин*) исем-фамилияләрен бирүне күздә тоткан. Шул ук вакытта Н.Я. Агафонов проектының үз заманы өчен уңай, прогрессив яклары да булган. Автор күп кенә урамнарга атаклы язучылар, галимнәр, мәгариф һәм мәдәният эшлеклеләренең исемнәрен бирергә кирәк дип санаган. Казандагы аерым урамнарның исемнәрен *Л.Н. Толстой, А.С. Пушкин, С.Т. Аксаков, Г.Р. Державин, К. Фукс, А.М. Бутлеров*, татар галимнәреннән *Хәлфиннәр* һ.б. хөрмәтенә алар исеме белән алмаштырырга тәкъдим итә. Ул елларда ук бөек рус язучылары *Л.Н. Толстой, А.С. Пушкин* исемнәре бирелгән урамнар бүген дә шулай аталалар [Саттаров, 1971, б. 72–73].

XX йөз башларында дәвалау, сәүдә, сәнәгать оешмалары исемнәрен алган *Госпитальный, Газовый, Заводской, Кузнечный, Горшечный, Бойничный, Толчок* урамнары, *Тулуповка, Рыбноряд* мәйданнары, географик үзенчәлекләренә нисбәтле *Подлужный*, *Заречный*, *Луговой* урамнары барлыкка килә.

1914 елда Казанның яңа планы төзелүе сәбәпле, дистәләгән урам исемнәрен алмаштыруны күздә тоткан карар чыгарыла. Үзгәрешләр, иң беренче чиратта, яңгырашы күңелгә ятмаган атамаларга кагыла: мәсәлән, *Кошачий* һәм *Собачий* тыкрыклары үзгәртелә, *Юшков* тыкрыгы *Некрасов* урамына әверелә.

Совет чорында татар урбанонимиясе тарихының яңа дәвере башлана. 1920 елның 25 июнендә Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелә. Шәһәр торгызыла, халык саны арта башлый. Бөек Ватан сугышына кадәр Казан индустриаль үзәккә әверелә. Моңа нисбәтле, *Дементьев, Технический* һ.б. индустриаль урамнар калкып чыга.

Россиянең башка шәһәрләрендәге кебек үк, Казанда да 1917 елның инкыйлабыннан соң күп кенә урамнарның исемнәре үзгәртелә. Хакимият алмашыну белән шәһәр урбанонимия тарихының яңа дәвере башлана. Идеологиягә нисбәтле исемнәр барлыка килә башлый: *Восстание*, *Маркс*, *Энгельс, Ленин* урамнары һ.б. Октябрь инкыйлабыннан соң илдә булган зур үзгәрешләр йогынтысында барлыкка килгән һәм шул елларның рухын җиткергән урбанонимнар саны шактый: *Совет, Пролетар, Кызыл Октябрь, Пионерлар* урамнары һ.б. Шулай ук патша хакимиятенә каршы чыгучыларның исемнәре барлыкка килә: *Разин, Пугачев* урамнары.

1950 еллардан башлап татар урамнарына Бөек Ватан сугышы геройлары, сәнгать, әдәбият эшлеклеләре, галимнәрнең исемнәре бирелә. Алар арасында татар фамилияләре дә еш очрый. Мәсәлән, *Хөсәен Ямашев, Га-*

*дел Кутуй, Салих Сәйдәшев, Әмирхан Еники, Һади Такташ* урамнары.

XX йөзнең 60 нчы елларында илдә барган прогрессив үзгәрешләр нәтиҗәсендә галәмгә беренче космонавт чыгару куанычын уртаклашу һәм хөрмәт белдерү йөзеннән Казан урамнарына *Гагарин, Космонавтлар, Академик Королев* һ.б. исемнәр бирелә. Илдә барган сәнәгать революциясе дулкынында *Мотор, Водоканал, Индустрия, Завод* дигән урам исемнәре барлыкка килә.

Совет заманы урбанонимиясе алдагы чор традицияләрен дәвам итә. Аерым алганда, кайбер урамнарның атамалары географик объектларга нигезләнә *(Озерная, Дачная)*; профессия һәм һөнәрчелек исемнәрен йөрткән урамнар барлыкка килә *(Химиклар, Журналистлар, Мехчылар)*.

Татар урбанонимиясенең хәзерге чоры, иң беренче чиратта, тарихи атамаларның яңадан кайтуы белән характерлана. Моңа мисал итеп *Кәҗә бистәсе* станциясе, *Сукно бистәсе* станциясе, *Ташаяк* урамы атамаларын китерергә мөмкин.

XXI йөз башларында кайбер урбанонимнар башка исемнәргә үзгәртелә. Мәсәлән, *3 нче Земляничный – Рәхим Саттар, 2 нче Владимирский – Коновалов, Шатурский* урамының бер өлеше – *Симонов, Портовый* урамының бер өлеше – *Девятаев, Татцик – Мәсгут Латыйпов, Лесопарковый* урамының бер өлеше – *Алтынов, Совхозный – Сафин, 4 нче Союзный – Әнвәр Кәримов, 50 лет Октября – Академик Кирпичников, Сакко и Ванцетти – Рөстәм Яхин, Тукай тыкрыгы – Михаил Худяков, Ухтомский – Борһан Шаһиди, Школьный тык. – Катановский тык., Революция – Нәкый Исәнбәт, Калинин* урамының бер өлеше – *Әмирхан Еники, Володарский – Гаяз Исхакый, Кирпично-Заводской – Һади Атласи, Ново-Кремлевский – Ташаяк, 2 нче Армавирский – Муса Бигиев, Карл Либкнехт – Алафузов, Проходной – Сардар Вәисов, Забайкальский – Галимҗан Баруди, Ярмарочная площадь – Меңьеллык мәйданы, Нариманов* урамының бер өлеше – *Сара Садыйкова, Трубный – Гомәр Гали, Набережный – Азатлык* һ.б. Күргәнебезчә, татар урбанонимиясе системасында күренекле татар шәхесләренең исемнәре мәңгеләштерелә, милли исемнәр бирелгән урамнар саны арта. Шул ук вакытта, урам исемнәрен алмаштыру – тирәнтен уйлап хәл итүне сорый торган җаваплы һәм мөһим эш булып санала.

Бүгенге көндә Татарстанда барлыкка килгән яңа атамаларны урам исемнәрен башкага алмаштыру нәтиҗәсендә генә барлыкка килгән дип әйтеп булмый, чөнки шәһәр һәм авылларда яңа төзелгән урамнар барлыкка килә. Бу аларның киңәюен күрсәтеп тора [Хадиева, с. 217].

**Әдәбият**

*Агафонов Н.Я.* Историческая объяснительная записка наименования Казанских улиц // Материалы к вопросу переименования улиц города Казани. Казань, 1899.

*Амиров К.Ф.* Казань: где эта улица, где этот дом? Справочник улиц города Казани. Казань: Изд-во Казань, 1995. 320 с.

*Белокопытов В.И.* Их именами названы улицы Казани / В.И. Белокопытов, И.Я Шевченко. Казань, 1973. 527 с.

*Горбаневский М.В.* Русская городская топонимия: проблемы историко-культурного изучения и современного лексикографического описания: дис. ... д-ра филол. н. М., 1994. 432 с.

*Заринский П.* Очерки древней Казани. Казань: Губерн. тип., 1877. 220 с.

*Калинин Н.* Казань XVIII века: по неизд. картогр. и иконогр. материалам. Казань: Лито-тип. Татполиграфа, 1929.

*Мартьянова С.А.* Лексика писцовых книг города Казани XVI–XVII вв. // Ученые записки Казанского университетата. Казань. Т. 112, кн. 6. 1952. С. 110–115.

*Остроумов В.П.* Казань. Очерки по истории города и его архитектуры. Казань: Изд-во Казанского ун-та, 1978.

*Подольская Н.В.* Урбанонимия Центральных областей РСФСР // Вопросы географии. М., 1974. № 94. С. 123–129.

*Разумов Р.В.* Система урбанонимов русского провинциального города конца XVIII–XX веков: на примере Костромы, Рыбинска и Ярославля: дис. … канд. филол. наук. Ярославль, 2003. 293 с.

*Саттаров Г.Ф.* Башкалабыз урамнарына – милли рух // Казан утлары, 1993. № 1. Б. 164–168.

*Саттаров Г.Ф.* Ни өчен шулай аталган? Татарстан топонимнары. Казан: Татар. кит. нәшр, 1971. 127 б.

*Спасский Н.А.* Очерки по родиноведению. Казанская губерния. Казань: Типо-лит. Имп. ун-та, 1910. 165 с.

*Суперанская А.В.* Типология именования внутригородских объектов Москвы // Географические названия в Москве. Серия «Вопросы географии». М.: Мысль, 1985. С. 160–170.

*Фахрутдинов Р.Г.* История татарского народа / Р.Г. Фахрутдинов, Р.Р. Фахрутдинов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. 407 с.

*Хадиева Г.К.* Урбанонимия города Казани // Альманах современной науки и образования. Тамбов: Грамота, 2012. № 9 (64). С. 216–218.

***Һадиева Гөлфия Камил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан федераль университеты доценты*

УДК 811.512’373

*Г.С. Хаҗиева-Демирбаш*

# ТАТАР МИФОНИМИКАСЫ: ҮСЕШЕ ҺӘМ ӨЙРӘНҮ ПЕРСПЕКТИВАСЫ

Статья посвящена семантической реконструкции мифонимов в татарском языке. Объектом исследования являются татарские мифонимы, а предметом анализа выступают этнолингвистические механизмы концептуализации мира. В статье выделяются мифонимы, связанные с высшим пантеоном мусульманской и христианской религий, а также мифонимы, связанные с «низшей мифологией». Автором проводится разграничение понятий «теоним» и «демоним», выделяются их ономастические особенности. Выдвигается гипотеза о том, что мифоним является уникальным материалом, зафиксированный в фольклорном творчестве народа, который тесно связан с этнокультурой, этническим составом народа, различными взглядами, приметами и обычаями. В ходе проведенного этнолингвистического анализа было установлено, что мифонимы репрезентируют этнокультурные сведения, запечатлённые в мифологическом народном сознании. Применены методы лингвокультурологической интерпретации, семантической реконструкции, этимологического анализа.

**Ключевые слова**: этнолингвистика, мифонимика, мифонимы, теонимы, демонимы, мифопоэтическая картина мира.

Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан үткәрелгән күпсанлы экспедицияләр төрле төбәкләргә сибелеп яшәгән, шул исәптән Татарстанда яшәүче төрле киңлектәге мәдәniяткә караган татарларның мифологик лексикасын барларга, теркәргә, эзлекле фәнни яссылыкта тикшерергә, шулай ук үткән һәм бүгенге көн күзлегеннән якын килеп өйрәнергә мөмкинлек бирә. Татар халкында киң таралган һәм хәзер дә кулланылышта йөргән, фольклор-диалектологик жанрларда гына сакланып калган гаять дәрәҗәдә кызыклы архаик лексик катламны тәшкил иткән мифологик лексиканы җыеп, фәнни әйләнешкә кертү бүгенге татар тел белеменең мөһим бурычларынннан санала һәм перспектив юнәлешен тәшкил итә. Хәзерге татар тел белеменең этнолингвистик мәсьәләләрен чишүдә мифологик лексиканың киң базасын булдыру һәм системалаштыру иң нәтиҗәле чара булып санала. Аерым бер мифонимның генезисын ачыклап, гомумтөрки контекст кысаларында этнолингвистик аспектта реконструкцияләү эше ономастика тармагына караган мифонимиканың үсеш мәсьәләләрен хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Мифонимика – ономастиканың мифоантропоним, мифотопоним, мифофитоним, теоним, демоним кебек ономастик берәмлекләрнең телдәге функцияләрен, мәгънәләрен һәм төзелешләрен, барлыкка килү закончалыкларын өйрәнә торган бер тармагы

[ЭСЛТП, 2008, с. 107]. Әкият, дастан, риваять, табышмак, мәкаль-әйтем кебек фольклор жанрларында төрле ышануларга нигезләнеп барлыкка килгән онимнар тупламасы мифонимия дип атала [Суперанская, 2006, с. 180]. Ономастик лексиканың бер катламын тәшкил иткән мифонимиягә кеше исемнәре, хайван, үсемлек, географик һәм космографик объект атамалары, шулай ук реаль булмаган предмет, объект исемнәре керә.

XX гасыр ахырында рус теле белемендә мифонимнарның үсеш-үзгәреш үзенчәлекләре Д.К. Зеленин, А.Н. Веселовский, О.М. Фрейденберг, П.Г. Богатырев тарафыннан лингвофольклористика кысаларында билгеләнсә, соңрак исә әлеге юнәлеш С.Е. Никитина, А.Т. Хроленко хезмәтләрендә үстерелә. Славян һәм рус телләрендә мифонимнар мәсьәләсе этнолингвистика кысаларында Т.А. Агапкина, Е.И. Алещенко, О.В. Белова, Е.Л. Березович, О.В. Волощенко, О.Г. Горбачевой, Н.В. Дранникова, Т.И. Кондратьева, С.Е. Никитина, В.Я. Пропп, С.М. һәм Н.И. Толстойлар, В.Н. Топоров, А.В. Юдин хезмәтләрендә өйрәнелә. Е.Л. Березович топонимия һәм фольклор арасындагы бәйләнешләр проблемасына мөрәҗәгать итеп, болай дип искәртә: «Топонимнарның фольклор ремотивациясе гомумтел ремотивациясе белән аңлатыла, шул рәвешле топонимнарның эчке формасы халык авыз иҗаты ярдәмендә ачыла» [Березович, 2016, с. 159].

Төрки-татар мифонимнарын өйрәнә башлауның беренче тәҗрибәсен Ибне Фадланның сәяхәтнамәсендә күзәтергә мөмкин. Ул, беренчеләрдән булып, Идел буенда алыплар турындагы легендада мифонимнарның кулланылышы хакында бәян итә. Алга таба алар Әбү Хәмид әл-Гарнати хезмәтендә (X–XI гасырлар), «Кодекс Куманикус» (XIV гасыр), «Казан тарихы» (XVI йөз) кебек тарихи ядкәрләрдә дә урын ала. XVIII гасырда исә Г.Ф. Миллерның «Описание живущих в Казанской губернии языческих народов» хезмәтендә (текст ахырында) мифологик эчтәлекле терминнарны аерып чыгару тәҗрибәсе күзәтелә һәм автор аларның рус теленә тәрҗемәсен дә китерә (Бог – Тере Гудай, Дьявол – Шайтан, Гора – Ата, Бугор – Им-ата һ.б.). Н.Ф. Катановның «Алфавитный указатель собственных имен, встречающихся в 1-м томе “Образцов народной литературы тюркских племен”» хезмәте [Катанов, 1888] мифонимнарны өйрәнүнең әһәмиятле чыганагы булып санала, анда фольклор исемнәре тарихи-лингвистик аспектта тикшерелә. Ул үзе төзегән Күрсәткечтә фольклорда кулланылган каһарманнарның исемнәрен, аларның вазифаларын, атамалар семантикасында чагылыш тапкан традицион эпитетларны санап китә. Н.Ф. Катановның әлеге хезмәте төрки мифонимика үсешендә җитди адым саналырга хаклы. XIX гасырның икенче яртысында К. Насыйри тарафыннан татар фольклористикасында беренче тапкыр мифологик персонажларны төркемләү (су астында торучы әкәмәтләр, җир өстендә яшәүче әкәмәтләр)

омтылышы ясала, *елан* белән бәйле *Ак елан, Аждаһа, Юха елан* кебек персонажларның генезисы, функцияләре билгеләнә, татар халкының ышанулар системасында «ия»ле авыруларның үзенчәлекләре тасвирлана.

Совет чорында Н. Исәнбәт татар мифларыннан материал туплый һәм аларны татар халык иҗатының афористик жанрларына багышланган саллы томнарына һәм башка хезмәтләренә кертә. XX гасыр ахырында исә төрки-татар мифологиясен һәм аның мифонимнарын өйрәнүгә Х. Ярми, Ф.И. Урманчеев, М.Х. Бакиров, Х.Ш. Мәхмүтов, Г.Х. Гыйльманов, К.М. Миңнуллин, Л.Ш. Җамалетдинов, А.Х. Садыйкова, Ф.З. Яхин, Л.Х. Мөхәммәтҗанова һ.б. фольклористларның хезмәтләрендә житди игътибар бирелә.

Татар тел белемендә Г.Ф. Саттаров, Ф.Й. Йосыпов, Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, М.И. Әхмәтҗанов һ.б.ның хезмәтләрендә төрле этник төркемнәрдә чагылыш тапкан мифонимнарны барлау, аларны классификацияләү максаты куела.

Мифонимнар башкорт [Хисамитдинова, 2010], азәрбайҗан [Халыгов, 2004, с. 25], төрек [Şahin, 2016, s. 64–69], казакъ [Керимбаева, 2004; Керимбаев, 2004], шор [Токмашев, 2005] телләрендә өйрәнелә. И. Шаһин билгеләвенчә, төрек тел белемендә антропонимик терминологиянең тар мәгънәдә өйрәнелүе мифонимнарны фольлористика фәне кысаларында гына карауга китерә. Ул, фикерен дәвам итеп, мифонимнарның лингвистик, морфологик, семантик үсеш-үзгәрешләрен ономастиканың өйрәнү объекты буларак тикшерергә тиешлеген бәхәссез дип саный [Şahin, 2016, s. 68].

Төрки-татар мифологиясендә мифонимнар тәңречелек тәгълиматына нигезләнгән көчләргә, төрле ияләр һәм түбән рухларга аерымланалар [ТМ, 1996, б. 8]. Әлеге бүленеш приципларын исәпкә алып, мифонимнарны тәңречелек тәгълиматы белән бәйле югары алла атамаларына (Җир-Су, Умай, Алас һ.б.), «түбән көчләрне» тәшкил иткән, алла статусына ия булмаган ияләргә, кара көчләргә, рухларга, һәм йола-гадәтләргә, ышануларга, кешенең көндәлек яшәеше белән бәйле мифологик персонаж исемнәренә аерып карарга мөмкин. Г.Х. Гыйльманов билгеләвенчә, «аллалар сыйныфыннан аермалы буларак, түбән мифология күк дөньясы белән түгел, күбрәк Җир дөньясы, кеше тормышы белән бәйләнгән» [ТМ, 1999:, б. 4]. «Югары» һәм «түбән» көчләргә аерымлануларыннан чыгып, мифонимнарның ике төре – теоним һәм демонимнар билгеләнә. Ф.И. Урманчеев «Татар мифологиясе» сүзлегендә аллалар, алиһәләр, явыз затлар белән бәйләнешле, «түбән» мифология каһарманнарын аерып күрсәтә [ТМ, 2008, б. 17–25].

Теонимнар – мифонимнарның бер төре буларак, илаһи көчләрнең исемнәрен тәшкил итәләр [Подольская, 1978, с. 125]. Теонимнар борынгы төрки чорда ук барлыкка килгәннәр. Билгеле булганча, төрки халыкларның

рухи мәдәнияте катлаулы һәм зур үсешкә ия була.

Төрки-татар теонимнарыннан Умай – борынгы төркиләрдә хатын-кыз башлангычын гәүдәләндергән уңдырышлылык алиһәсе. *Умай* сүзе борынгы заманнарда (б.э.к. кергән булырга тиеш. Бу сүз татар телендә *омай* > *ымай* > *май* күчешләре кичерә. *Май* татар сөйләшләрендә «күп; муллык» сүзен аңлата [ТТЭС – 2, 2015: 347]. Беренче тапкыр *Умай* мифонимы VII–VIII гасырларда рун язмасында телгә алына. Күк алласы Тәңрenең хатыны дип кабул ителә. Аерым галимнәр фикеренчә, килеп чыгышы ягыннан Умай Иран мифологиясеннән Хумай-Һомай кош образы белән дә бәйле санала. Умайның вазифасы төрле халыклар мифологиясендә төрлечә күзаллана. Себер татарларында Умай турында мөһим мәгълүматлар сакланып калган. Мәсәлән, «Себер татарларында Умайны бала кендеге белән дә тиңләштерәләр. Моның нигезендә дә шул ук мәгънә ята: кешенең асылын билгеләүче, аңа сулыш, җан өрүче» [ТМ, 1996, б. 21]. Бу исә, үз чиратында, Себер татарларының башка төрки халыклар, бигрәк тә шул тирәдәге алтайлылар, хакаслар, телеутлар белән тыгыз этник һәм этник-мәдәни бәйләнешләрдә булуын төгәл раслаган күркәм күренеш [ТМ, 2011, б. 148]. Татарларда Умай турында карашлар кайбер башка төрки халыклардагы кебек төгәл һәм эзлекле түгел.

Төрки-татар дөньясында Урта дөнья алласы булган *Җирсу, Йер-су(б)* җир һәм су гәүдәләнешен чагылдыра [ТМ, 2009, б. 65]. Орхон-Енисей язмаларында беренче тапкыр Күлтәгин истәлегендә телгә алына: «Төркләрнең югары күге, төрекләрнең изге Җир-су шулай дип әйттеләр: “Төрки халкы юкка чыкмасын иде!” – дип әйттеләр». Борынгы төркиләрне һәрвакыт саклап, һәрбер эшләрендә ярдәм итеп торган Җир-су – төрле урыннарның, табигать объектларының (тау, урман, елга, күл) рух хуҗасы булып та саналган.

Мифологиянең түбән көчләрен төрле демоннар, кечкенә илаһи көчләр, ияләр, җеннәр тәшкил итәләр [Давлетшина, 2011, с. 60]. Демоннарның кешеләр арасындагы туганлык һәм көнкүреш мөнәсәбәтләре дә билгеләнә. Мифологик тикшеренүләрдән мәгълүм булганча, «түбән көчләр» «югары көчләргә» караганда борынгырак, чөнки әлеге катлам коллектив күзаллауга нигезләнә. Мифонимнарның «түбән» катлавын чагылдырган төре демонимнар дип атала [Şahin, 2016, s. 67].

Демонимнарның көндәлек тормыш белән бәйләнгән төркемә «түбән» көчләрнең атамалары керә: *Бичура, Өй иясе, Су анасы, Урам иясе, Тыкрык иясе, Ындыр иясе, Умарталык иясе* һ.б. Татар халкының традицион культурасында, гомуми һәм борынгыдан килгән карашлар буенча, кешенең тирә-ягында булган һәрнәрсәнең, предметларның, хәтта табигать күренешләренең үз иясе була. Ияләр үзләренең төп вазифаларын башкарган урыннарда – өйләрдә, абзарларда, су, елга, күлләрдә

гомер итәләр. Татар рухи мәдәниятенең җирле вариантларында атамаларда төрлелек күзәтелә. Томск татарларында Су ияләре, Урман иясе белән бәйле риваять-легендаларның күплеге билгеләнә [ТМ, 1996, б. 127; ТМ, 2011, б. 73].

*Йорт иясе, абзар иясе* турындагы сюжетлар Томск татарларында һәм башка җирле төркемнәрдә дә очрый. Свердловск өлкәсе татарларында *Сыу ийәсе, Сыу инәсе, Урман ийәсе, Абзар ийәсе, Мал хуҗасы, Абзар хуҗасы, Өй хуҗасы, Йорт хуҗасы Мижа хуҗасы, Өй ийәсе, Йорт ийәсе, Урам ийәсе, Каралды ийәсе, Ат ийәсе* мифонимнары чагылыш таба.

Җирле вариантларда очрый торган *Хозер Ильяс* персонажын (Хызыр, Хозер, Хозер бабай, Хызыр Ильяс һ.б.) юл иясе дип йөртәләр [Давлетшина, 2011, с. 61]. Татар халкы ышануларында киң таралыш тапкан Хозер Ильясның юл иясе буларак кабул ителүе, аның составындагы Ильяс образы белән бәйле дип тәгаенләнә. *Хизр, Хидр* – мифик пәйгамбәр. *Хидр* дигән могҗизалы зат турында легендалар Шумер-Аккад заманнарыннан ук булган. Шумерча бу сүз «яшел кеше, мәңге яшел» мәгънәсендә дә булган [ТТЭС – 2, 2015, б. 392]. Татар халкының ышануларында Хозер Ильяс – юлчыларга – юлдаш, адашкан кешеләргә ярдәм итә торган ак сакаллы карт буларак ачыклана. Ислам динендә *Ильяс пәйгамбәр* (христиан динендә Илия) буларак билгеле әлеге персонаж «җирдә һәм суда сәяхәт итүчеләрне яклаучы» дип характерлана. Татар паремиологик фондында *Хозыр* компоненты белән бәйләнешле «Авызына Хозыр төкергән» гыйбарәсе кызу канлы кеше турында әйтелә, татар телендә *Хозыр Ильяс* мифонимының тулы идиоматизация кичерүе күзәтелә.

Ислам мифологиясе белән бергә кергән демонимнарга *Җен, Шайтан, Иблис, Дәҗҗал* һ.б.ны кертеп карарга мөмкин. Мифологик караш буенча, алар җир өстендә, без яшәгән гадәти дөньяда гомер кичерәләр. Төркитатар мифологиясендә ислам мифологиясеннән алынган демонимнарның берсе – *Җен* – явыз рух, Аллаһ тарафыннан барлыкка китерелгән өч төркем акыллы затларның берсе. Р.Г. Әхмәтьянов *Җен* демонимын түбәндәгечә аңлата «җен диал. йен “злой дух, бес, джинн” ~ башк. *йен* > мар. диал. *зын,* удм. *зин* < гар. *җинн* “җен; яшерен зат” – *җнн* «яшерү» фигыленнән. *Әҗинә* “хатын җен, җен хатыны”» [ТТЭС – 1, 2015, б. 265]. «Җен» – нинди дә булса вазифа үтәвенә карап, кеше кыяфәтенә, предмет, атмосфера күренешенә керә алучы күренми торган демонимик зат. Җеннәр безнең тормышыбызга үтеп, кешегә күренми генә гаиләләре белән параллель тормышта яши алалар. «Җен демонимы ислам дине белән килеп керә һәм киң тарала, локаль мәдәнияткә нисбәтле трансформацияләнә һәм борынгы төрки мифологиянең архаик системасының җимерелү процессында яңа интерпретация ала» [Давлетшина, 2016, с. 27]. Коръән тәгълиматы буенча, Җеннәр

төтенсез уттан яратылганнар, теләсә нинди кыяфәткә керә алалар; үтә катлаулы эшләрне җиңел башкаралар. Җирдә Адәм галәйһиссәләмгә кадәр үк яшәгәннәр, гадәттә кешеләрнең дошманы буларак сурәтләнәләр. Адәм балалары белән Җеннәрнең үзара мөнәсәбәтләре Коръәндә дә әйтелә. Җеннәрнең бер төркеме Корьәнгә иман китереп, ислам динен кабул итә һәм аңа тугрылыклы булып кала, икенче төркеме исә Иблискә ияреп, Аллаһка иман китерүдән баш тарта һәм мәҗүсилектә кала.

Борынгы гарәп һәм ислам мифологиясеннән төрки-татар мифологиясенә үтеп кергән *Дәҗҗал* (гар. алдакчы, ялганчы) демонимы христиан динендәге Антихристка туры килә. Даджал (دَجَّالٌ гарәп «ялганчы») – антихрист, антимессия, ахырзаманда килүче. Гарәп телендә *Дәтьял* «антихрист; изверг» дигәнне аңлата. Р.Г.Әхмәтьянов карашынча, *Дәтьял* демонимының килеп чыгышы гарәпчәдән түгел, башка чыганакка да карарга мөмкин (*Дециал* – «унынчы бала» исеме – *Дектиан* дип әйтелгән, тарихта Дециал буларак билгеле) [ТТЭС – 1, 2005, б. 241]. Татар телендә *дәҗҗал* сүзе күчерелмә мәгънәдә «ялганчы, алдакчы» дигәнне дә аңлата [ТТАС, 2005: 154]. Дәҗҗал хәдисләрдә һәм ахырзаман белән бәйләнешле дастан-кыйссаларда телгә алына. Мөселман тәгълиматы буенча, Дәҗҗалның эш-гамәлләре Иблис белән бәйләнгән.

Демонимнарның икенче төркемен аллалар дәрәҗәсендә торып, ниндидер гайре табигый көч-куәткә, кодрәткә ия көчләрнең атамалары тәшкил итәләр. Көндәлек тормышта очраган көчләрдән аермалы буларак, алар башка дөньяда яшиләр. Төркитатар мифологиясендә төрле ияләргә багышланган мифологик хикәятләр җитди урын алып тора. *Су анасы* һәм *су атасы, су иясе* образлары барча төрки халыкларда (бигрәк тә кыпчакларда) очрый. Фольклордагы Сусылу образы татар-башкортларда гына чагылыш таба [ТТЭС – 2, 2005, б. 176]. Татар диалектларындагы *суwәсе* «су иясе» [ТТЗДС, 2009: 582], *сумийә* «су иясе» [ТТЗДС, 2009, б. 586] кебек вариантларда борынгы фонетик яңгыраш һәм күчеш чагыла. Су асты патшалыгы белән бәйле *Су анасы* образы – киң таралган сюжетларның берсе. Ул озын чәчле, куркыныч хатын-кыз образында күзаллана. Шулай ук демонимнар арасында татар фольклорында *Су иясе, Су анасы, Су бабасы* образлары да очрый. *Су кызы* образы татар халкының иң борынгы дастаннарыннан саналган «Түләк һәм Сусылу» дастанында чагылыш таба.

Татар мифологиясендә *Бичура* демонимы төрки-татар дөньясында киң таралган. *Бичура* диал. *пичура, мичура, бисура, мисура* «домовой». *Бичен, Мичкәй, Присура, Мичура вариантлары* бичуралар мич тирәсендә яшиләр дигән мифның чагылышы [ТТЭС – 1, 2015, б. 191]. Бичура – йорт иясе, йорт хуҗасы, йорт пәрие [ТТАС – 1, 2015, б. 545]. *Мич артында мичура билен буып утыра* (себерке) дигән татар табышмагында *Бичура* демонимы

чагылыш таба. Бичураның шактый катлаулы, каршылыклы, өййорт тирәсендә, хәтта урманнарда гомер итүче затларга да якын торган хәшәрәт булуы билгеләнә [ТМ, 2008, б. 227]. Татар мифологиясендә бичураларның ике төре билгеләнә: бер төркеме кешеләргә вак-төяк явызлыклар эшләп торса, икенчеләре яхшылыклар кыла икән.

Телнең этномәдәни тирәлегендә мифонимнар үзенчәлекле ономастик парадигманы тәшкил итеп, халык турында мәдәнитарихи, мифологик, этномәдәни белемне поэтик чагылдыру вазифасын үтиләр. Мифонимнар мәгънә бердәмлеген һәм кеше тарафыннан тирә-юнь турындагы мәгълүматны ачалар, шулай ук телнең этномәдәни тирәлеген ачыкларга ярдәм итәләр. Мифонимнар – диахроник семантик үсешкә ия булып, халыкның психологик торышын, күзаллауларын ачарга ярдәм итә торган берәмлекләр.

**Әдәбият**


*Березович Е.Л.* Русская топонимия в этнолингвистическом аспекте: Мифопоэтический образ пространства. М.: КомКнига, 2010. 240 с.

*Давлетшина Л.* Религиозно-мифологические представления о «нечистой силе» в традиции тюменских татар // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота, 2016. № 9. Ч. 1. С. 25–27.

*Катанов Н.Ф.* Алфавитный указатель собственных имен, встречающихся в первом томе Образцов народной литературы тюркских племен, собранных В.В. Радловым: Представлено Акад. в заседании Ист.-филол. отд. 22 сент. 1887 г. / сост. Н.Ф. Катанов. СПб.: Тип. Имп. Акад. наук, 1888.

*Керимбаев Д.М.* Состав и этнолингвистическая характеристика собственных имён казахского фольклора: автореф. дис. ... канд. филол. н. Алматы, 2004. 28 с.

*Керимбаева С.Е.* Ономастическая экспликация мифологической модели мира в казахском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Алматы, 2004. 28 с.

*Насыйри К.* Сайланма әсәрләр: Ике томда. Беренче том. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 339 б.

*Подольская Н.В.* Словарь русский ономастической терминологии. М.: Русские словари: Астрель, 1988. 135 с.

*Саттаров Г.Ф.* Татар антропонимикасы. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1990. 276 б.

ТМ, 1996 – Татар мифлары: Ияләр, ышанулар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. Казан: Татар. кит. нәшр., Т. 1. 1996. 384 б.

ТМ, 2008 – Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 1 т. (А–Г) / Фатих Урманче. Казан: Мәгариф, 2008. 303 б.

ТМ, 2009 – Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 2 т. (Д–С) / Фатих Урманче. Казан: Мәгариф, 2009.

ТМ, 2011 – Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 3 т. (С–Я) / Фатих Урманче. Казан: Мәгариф, 2011. 198 б.

*Токмашев Д.М.* Теоретические проблемы фольклорной ономастики [Электронный ресурс] // Вестник Томского государственного педагогического университета. – 2011. – № 9. – URL: http://cyberleninka.ru/article/ n/teoreticheskie-problemy-folklornoy-onomastiki-na-materiale-shorskogo-folklora

ТТАС, 2005 – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 с.

ТТАС, 2015 – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: Т. 1: А–В. Казан: ТӘһСИ, 2015. 712 б.

ТТЗДС – Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 836 с.

ТТЭС – 1 – Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: 2 томда. 1 том (А – Л). Казан: Вакыт, Мәгариф, 2015. 543 с.

ТТЭС – 2 – Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: 2 томда. 2 том (М–Я). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 567 б.

*Хазиева-Демирбаш Г.С.* Татарские личные имена в этнокультурном пространстве языка. Казань: Магариф – Вакыт, 2017. 444 с.

*Халыгов Ф.Р.* Фольклорная ономастика азербайджанского языка: автореф. дис. ... д-ра филол. н. Баку, 2004. 55 с.

*Хисамитдинова Ф.Г.* Мифологический словарь башкирского языка. М.: Наука, 2010. 456 с.

ЭСЛТП – Энциклопедический словарь-справочник лингвистических терминов и понятий. Русский язык: в 2-х томах / А.Н. Тихонов, Р.И. Хашимов, Г.С. Журавлева и др. / под общ. ред. А.Н. Тихонова, Р.И. Хашимова. Т. 1. М.: Флинта: Наука, 2008. 820 с.

*Яхин Ф.* Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Казан: Татар. дәүләт гуманитар ин-ты, 2000. 286 б.

*Şahin İ.* Adbilim (Çerçeve, Terim, Yöntem ve Sınıflandırmalarıyla). Ankara: Pigem Akademi, 2016. 155 s.

***Хаҗиева-Демирбаш Гүзәлия Сәйфулла кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145·81´373.61

***Р.Т. Сәфәров***

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ХАЛЫК ЭТИМОЛОГИЯСЕНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

В статье на материале татарского языка раскрывается содержание понятия «народная этимология», сущность которого состоит в осмыслении морфологического состава слова и мотивировки его значения на основе сближения с созвучными словами, отличными от него по происхождению. Автор, основываясь на классификации В.А. Богородицкого, приводит примеры к таким процессам реэтимологизации как субституция звуков, семасиологизация и морфологизация. Также рассматриваются возможности реэтимологизации как одного из наиболее ярких стилистических средств, используемых в литературных произведениях для создания комического.

**Ключевые слова:** татарский язык, народная этимология, процессы реэтимологизации, морфологизация, комическое.

Сүзнең килеп чыгышы яки мәгънәсе аңлашылмаган очракта аны үзеңчә аңлау һәм аңлату күренеше тел белемендә төрле терминнар белән белдерелә: *халык этимологиясе, ялган этимология*, *реэтимологизация,* шулай ук *псевдоэтимология, квазиэтимология* һ.б. Бу темага багышланган махсус әдәбиятта әлеге атамаларның саны дистәдән артып китә.

Хәзерге татар тел белемендә күренеш буларак та, термин буларак та *халык этимологиясе* төшенчәсе ешрак кулланыла. Аның эчтәлеге чыганакларда түбәндәгечә ачыклана:

**халык этимологиясе** дип таныш булмаган сүзнең мәгънәсен җиңел аңлашыла торган сүзләр җирлегендә аңлатырга тырышуны әйтәләр [Татар лексикологиясе, т. 1, б. 285];

**халык этимологиясе** дип, гадәттә, алынма сүзләрне туган тел сүзьясалышы модельләреннән чыгып аңлау вә таркатуны атыйлар [Әхмәтьянов, т. 1, б. 28];

**халык этимологиясе** – **реэтимологизация**, ягъни сүзнең яңа эчке форма алуы, мотивлашмаган булудан мотивлашканга әйләнүе [Сафиуллина, б. 164];

**ялган этимология**, икенче төрле әйткәндә, **халык этимологиясе** – сүзнең килеп чыгышын очраклы аваз тәңгәллекләренә нигезләп, башка сүзләргә охшатып аңлату [Сәлимов, б. 139].

Рус тел белемендә күптөрле билгеләмәләрне анализлап караганнан соң, Л.Д. Введенская белән Н.П. Колесников «Этимология» дигән хезмәтләрендә «**народная этимология** – это такая переделка фономорфологической структуры непонятного слова, которая сближает его с более привычным словом как фонетически, так и по значению, и позволяет осмыслить его», дигән фикергә киләләр [Введенская, Колесников, с. 37].

Р. Әхмәтьянов «Татар теленең этимологик сүзлеге»ндә 100 дән артык сүзне халык этимологиясе белән бәйләп аңлата. Без, диалекталь сүзләрнең этимологиясен тикшерү бу санны бермә-бер арттырачак, дигән карашта торабыз.

Татар тел белемендә халык этимологиясе бүгенгә кадәр теоретик планда система буларак махсус өйрәнелмәгән. Рус галимнәреннән әлеге күренешне тикшергән Т.М. Бузанова реэтимологизация процессларын, В.А. Богородицкий тәкъдим иткән классификациягә таянып, авазлар субституциясе, морфологизация һәм семасиологизация буларак өч юнәлешкә бүлеп карый [Бузанова, б. 11].

Алынмаларда яки эчке мотивациясе онытылган ана теле сүзләрендә нинди дә булса аваз (лар) мотивациясе таныш икенче сүзнең авазларына якынайтыла, нәтиҗәдә бу – сүзнең авазлар субституциясенә, ягъни авазлар составын үзгәртүгә китерә. Мәсәлән, *буа* сүзе халык аңында елганың *буылган* урыны дип кабул ителгән, ләкин аның борынгырак әйтелеше *бөя* яки *бүwә* булган, һәм аны суны «буу» белән бәйләмиләр [Әхмәтьянов, т. I, б. 210].

Морфологизация – сүзнең аңлашылмаган берәр элементын сөйләүчегә аңлашыла торган элементка алмаштыру. Ягъни чит сүзнең структурасы аңлашылмаса, ул моңарчы бер телдә дә булмаган яңа бер тамырга һәм морфемага таркатыла. Биредә мисал итеп татар телендәге алынмалардан яңа сүзләр ясалышын китерергә мөмкин.

Мәсәлән, бүгенге көндә сөйләм телендә *канцелярия* сүзенең *кәнсәләр* формасы кулланыла: *Кәнсәләргә нык-нык басып Сәлим керде* (Г. Афзал). Аның *-ләр* компоненты күплек сан кушымчасы дип аңлашылган, һәм моңарчы булмаган *кәнсә* сүзе барлыкка килгән: *Беркөнне, кәнсәгә кереп, Саматка бик озак карап тордым* (Г. Галиева). Бу сүз башка төрки телләрдә дә теркәлгән, мәсәлән: башк. *кәнсә* [БТДҺ, б. 173], үзб. *кенгса* «контора» [Әхмәтьянов, т. I, б. 396].

Татар телендә алынма сүз нигезенең соңгы иҗеген килеш кушымчасы дип аңлау нигезендә туган этимологияләргә дә кызыклы гына мисаллар китерергә мөмкин. Мәсәлән, соңгы иҗеген урын-вакыт килеше күрсәткече дип аңлатып, рус телендәге *комната* сүзе *кумна* һәм *да* өлешләренә таркатылган, нәтиҗәдә *кумна, кулма* кебек берәмлекләр барлыкка килгән [ТТЗДС, б. 337]. Р. Әхмәтьянов, әлеге сүзләр «1930 елларда күп «кара халык» шәһәрләргә күченә башлагач пәйда булган», дип саный [Әхмәтьянов, т. I, б. 468].

Рус телендәге *ка́торга* сүзен *катор//катыр//катр* лексемасының юнәлеш килеше формасы дип аңлату нигезендә моңарчы булмаган яңа сүз килеп чыккан: *Бөтен ыруы карак, бөтенесе бур, бөтенесен катыр җибәрергә!* (Г. Бәширов); *Богау киеп катор киткән каенатам!* (Ф. Гыйззәтуллина). Бу очракта *Себергә җибәрү, Мәскәүгә китү* кебек гыйбарәләрнең *Себер*

*җибәрү, Мәскәү китү* рәвешендәге юнәлеш килеше кушымчасыннан башка кулланылуларының да йогынтысы булмый калмагандыр.

Халык этимологиясе нигезендә ясалган тагын бер сүз язма чыганакларда теркәлмәгән. Бу *шоба* яки *шыба* сүзе. Бүген ул әдәби телдә дә, сөйләшләрдә дә тулы формасында *шобага*// *шыбага* дип кулланыла, ләкин аның күрше телләрдә кыскартылган формада саклануы (чув. *шӑпа*, мар. *шыва*, *шӧвӓ*) кайчандыр аерым урынчылыкларда *шоба-га* кебек аңлашылуын күрсәтә. Р. Әхмәтьянов, бу кыскарган вариантлар татарчадан алынган, дип исәпли [Әхмәтьянов, т. II, б. 491].

Шарлык сөйләшендә көнчыгыш какысын *сүәрби* дип атыйлар, диалектлар сүзлегендә ул *сүwәрби* буларак теркәлгән [ТТЗДС, б. 587]. Халыкта рус телендәге *свербúга* сүзенең *-га* компоненты юнәлеш килеше кушымчасы булып кабул ителү сәбәпле, татар телендә ул төшереп калдырылган. Монда *юага бару, җиләккә бару* кебек сүзтезмәләрдә *юа, җиләк* сүзләренең юнәлеш килешендә кулланылуының тәэсире сизелә.

‘Арзан, кыйммәт түгел’ мәгънәсендәге *очсыз* сүзе дә халык аңында *оч-сыз* дип аңлашылып ясалган сүзләрдән барлыкка килгән: *– Ни бәя соң менә бусысы? – Очсыз, җиңги җаныем, очсыз! Гүпчи дә юк инде, шалкан бәясе!* (Г. Бәширов).

Моның белән генә чикләнмичә, *арзанлы* сүзе тәэсирендә булса кирәк, *очсызлы* сүзе барлыкка килгән. *Ульян каласының үзәк урамында, «Сарман» көенә җырлый-җырлый, очсызлы ризыклар сата торган кибет эзләде алар* (Ф. Яруллин).

Монда ниндидер ‘зур бәя’ мәгънәсендәге **оч* сүзенә *-сыз* кушымчасы ялганган дип күзаллана. Югыйсә башка төрки телләрдә бу сүз әлеге формада кулланылмый. Чаг.: төр., аз. *ucuz*, кр.-тат. *уджуз*, кар-балк. *учуз*. Хәтта татар теленең кайбер сөйләшләрендә ул *очыз* формасында сакланган. Мордовиядә чыккан «Татар газетасы»нда: *Саранскиның иң зур залы шыгрым тулы иде, чөнки бу концертка билетлар бик очыз иде.* Башкорт телендәге *осһоҙ* исә я татар теле йогынтысы белән ясалган, я татарчадан алынма булып чыга.

Семасиологизация – эчтәлеге һәм тышкы формасы аңлашылмаган сүзгә яңа мотив, яңа мәгънә салу күренеше. Мәсәлән, халык этимологиясенә күрә, рус телендәге *кацавейка* ‘авыл хатын-кызларының өске киеме’ *кесә* сүзенә нисбәт ителгән һәм *кесәбикә* сүзе барлыкка килгән. *Төнбоек* сүзенең дә иске мәгънәсе, номинация мотивы онытылган. Бу үсемлекнең чәчәкләре төнгә таба ябылуы игътибар үзәгенә алынып, аңа «төнлә боек» була торган чәчәк мотивы салынган, югыйсә сүзнең төп нигезе *тӧмга- < тумға-*, *тумқа-* «чуму» булган, шуннан *тумғай* «төнбоек», *тумғай-ақ* (*тумғай* сүзенең иркәләү-кечерәйтү формасы) ясалган. Биредә баштан ук кайбер су үсемлекләренең төнгә суга яшеренүе күз уңында тотылган [Әхмәтьянов, т. II, б. 293].

Матур әдәбиятта еш кына халык этимологиясенә махсус мөрәҗәгать ителә. Аеруча көчле стилистик чара буларак реэтимологизация мөмкинлекләре көлке барлыкка китерү максаты белән кулланыла. Әлеге очракта нигездә рус телендәге берәр сүз татар телендә охшаш яңгырашлы сүзгә якынайтыла, нәтиҗәдә мәгънә үзгәрү сәбәпле көлке барлыкка килә.

Вәли. Тыңласаң, шул: менә без хәзер *театрга* китәбез...

Биби. Кая?

Вәли. *Театрга*!

Биби. Нәрсә *төятергә*?

Вәли. Баш *төятергә*.

Биби. Нинди баш?!

Вәли. Атаң башы! Мин сиңа *төятергә* димим, *театрга* дим, аңладыңмы, *театрга* дим! (Г. Камал);

Мин аны беркөннәрне Гарифәләргә җибәрдем: – Абыстай: – «Гарифәнең алдырган *кисла-тасы* юк микән. Бик күңелләрем болганып тора. Үзебездә судысы бар барын да, ирләр өйдә вакытта *кислата* алдырырга онытылган», – дип әйтте, дип сора, – дигән идем, барган да: «Абыстай, *киез каталарын* биреп торсыннар ла», – дип сорап, миңа *кислата* урынына *киез ката* күтәреп кайткан (Г. Камал).

Кайбер очракта мондый алым сүзнең бер өлешен алмаштыру, шуның белән яңа мәгънә барлыкка китерү өчен кулланыла:

Мөдир әйтә:
Ачтык әле
*Парикмахерская*.
Төзәтеп куя Шәвәли:
*Сарыкмахерская*! (Ш. Галиев).

Шулай итеп, халык этимологиясе татар лингвистикасында җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән дигән нәтиҗә ясарга туры килә. Күренеш буларак ул, башлыча, аталу мотивациясе аңлашылмаган алынма сүзләрдә күзәтелә. Күпчелек очракта халык этимологиясе нигезендә диалекталь сүзләр аңлатыла, моның төп сәбәбе – грамотасызлык, дип күрсәтелә. Сүзнең килеп чыгышын яки мәгънәсен аңлатканда, аның я фонетик тышчасы үзгәртелә, я аңлашылмаган элементы аңлашылган элементка алмаштырыла, я эчтәлеге таныш булган сүзгә охшатыла. Матур әдәбиятта реэтимологизацияне, стилистик чара буларак, махсус рәвештә көлке, каламбур барлыкка китерү максаты белән кулланалар.

**Әдәбият**

*Әхмәтьянов Р. Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. Т. I. 543 б.

*Әхмәтьянов Р. Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. Т. II. 567 б.

БТДҺ – Башҡорт теленең диалекттары һүҙлеге. Өфө: Китап, 2002. 432 б.

*Бузанова Т. В.* Реэтимологизация в русском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук : 10.02.01. Казань, 1992. 14 с.

*Введенская Л. Д., Колесников Н. П.* Этимология: учебное пособие. СПб: Питер. 2004. 221 с.

*Сафиуллина Ф. С.* Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары студентлары өчен). Казан: Хәтер, 1999. 288 б.

*Сәлимов Х. Х.* Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 143 б.

Татар лексикологиясе: өч томда / ред. Г. Р. Галиуллина. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. I. 352 б.

ТТЗДС – Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

***Сәфәров Ринат Таһир улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

***Р.М. Хөснетдинов***

# «ШУРА» (1908–1918) ЖУРНАЛЫНДА БАРГАН «ТЕЛ ЯРЫШЫ»НЫҢ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕ ТАРИХЫНДА ТОТКАН УРЫНЫ

Как известно, конец XIX – начало XX века считается сложным периодом, характеризующимся ростом национального самосознания татарского народа, развитием социально-философской и художественно-эстетической мысли. В этот период татарский письменно-литературный язык функционировал в религиозно-дидактическом, историко-научном, официально-деловом, художественно-литературном, эпистолярном стилях. Начало XX века характеризуется формированием и развитием периодической печати на татарском языке. После революции 1905 года, во многих областях России, в местах проживания татар, стали издаваться газеты и журналы на татарском языке. В статье вкратце излагается сущность и основные результаты «Языкового состязания – Кәлям мөсабәкасы», организованном на страницах журнала «Шура» (1909–1910), выходу первого номера которого в текущем году исполняется 110 лет.

**Ключевые слова:** журнал «Шура», «Языковое состязание», периодическая печать, стиль, литературный язык, объявление, вековая история.

XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар халкының милли үзаңы, иҗтимагый-фәлсәфи, сәнгати-эстетик фикер үсеше, әдәбияты-мәдәнияте күтәрелеше ягыннан катлаулы чорларның берсе булып санала. Гасырлар буена килә торган ныклы традиция, көчле яңарыш белән кушылып китү юнәлеше ала. Татар язма әдәби теле, үзенең барлык стильләрендә дә (матур әдәбият, дини-рухани дидактика, фәнни әдәбият, рәсми эш кәгазьләре, эпистоляр) киң даирәдә кулланылышта була, татар милләтенең яшәешен чагылдыра торган күренешкә әверелә. Әдәби тел гасырлар дәвамындагы язма традициянең нигезен тәшкил итә, шул ук вакытта, халыкчан-сөйләмә телнең байлыгы да, адресат һәм стильләр таләбенә туры килелеп, язма телнең вазифасын үтәрлек дәрәҗәдә файдаланыла. Нәтиҗәдә, татар әдәбияты һәм әдәби теленең алтын чоры дип атала торган гаҗәеп күренеш барлыкка килә. Бу вакытларда, төрки-татар теле өйрәнелә, фәнни хезмәтләр языла, русларга татар телен укыту максатын күздә тотып, төрле дәреслекләр эшләү активлаша. Иң мөһиме – татар халкы берләшеп яши торган барлык төбәкләрдә диярлек, татар телендә газета-журналлар басыла башлый.

1905 елның 2 сентябрендә Санкт-Петербургта «Нур» газетасының беренче саны дөнья күрә. Газетаның нашире һәм мөхәррире мөселман дөньясында танылган дин белгече, төрки телләр укытучысы һәм тәрҗемәче, «Дөнья яки мәгыйшәт» дәреслек-кулланмасының (1883), шулай ук рус телендә

язылган хезмәтләрнең авторы, җәмәгать эшлеклесе Гатаулла Баязитов (1846–1911) була. Ул «Нә делдә йазармыз?» дип, газетага дигән мәкаләне нинди «тел» белән язарга кирәклекне тәгаенләргә тырыша. Нәтиҗәдә, Казан теле дип атала торган язма телнең бер генә төрле булмавына игътибар ителеп, «Әдәби телебез нә делдер?», дип фикер алышу башлана [Баязитов, 1905]. Әлеге мәсьәләгә беренчеләрдән булып тарихчы-галим, җәмәгать эшлеклесе, ахун Хәсән-Гата Габәши хәзрәтләре («Нур» 1905, № 4), яшь язучы Гаяз Исхакый («Нур», 1905, № 8), «яшь фикерле галимнәрдән» Һади Максуди («Нур», 1905, № 13), мөхәррир Исмәгыйль Гаспралы («Тәрҗеман», 1905, 90–91 нче саннарда «Лисан мәсьәләсе») үзләренең мөнәсәбәтен белдерәләр, Г. Тукай «Тәрҗеман»ның татарларга галәкасы» дигән мәкаләсен яза («Фикер», 1906, № 44). Тарихчы, археограф Г. Әхмәрев Г. Исхакыйның фикерләрен куәтли («Казан мөхбире», 1905, № 5) [Мәрданов, 1999, б. 170–172]. Шулай итеп, газета мәкаләсе нинди тел белән язылырга тиеш дип күтәрелгән әлеге бәхәс «Фикер» (1905–1907), «Казан мөхбире» (1905–1911), «Бәянелхак» (1906–1914), «Вакыт» (1906–1918), «Йолдыз» (1906–1918), «Дин вә мәгыйшәт» (1906–1918) һәм башка басмаларда алып барыла. Танылган рухани-дин әһелләре, әдипләр, галимнәр, шәкертләр, укый-яза белүче зыялылар тарафыннан әдәби телнең вазифасы турында фикерләр әйтелә. Беренче мәртәбә, төрек-татар Казан теле (деле, шивәсе) дип таралган язма телнең берничә вариантта язылуына игътибар ителә. Күпләр, газета мәкаләсен «үзебез сөйләшә торган гавам теле» белән язарга кирәк, дип чыгалар. Газета мәкаләсенең теле турындагы бу фикер, гомуми язма телгә мөнәсәбәтле рәвештә, ягъни барлык төрдәге язмалар да халыкка бертигез дәрәҗәдә аңлаешлы булырга тиеш дигән юнәлеш ала. Шулай итеп, «Нур» газетасы битләрендә «Әдәби телебез нә делдер?» дип башланган фикер алышуда катнашучылар мәкаләләреннән чыгып, татар язма теле һәр укучы мәшәкатьсез аңларлык, «татар калыбына куелган», ягъни «Василий поп сөйли торган вәгазь» рухында («Нур», 1905, № 16) булырга тиеш, дигән нәтиҗә ясала [Татар әдәби теле тарихы, I т., б. 134–145].

Татар язма әдәби теле, үзенең барлык стильләрендә дә халыкның җанлы сөйләменә якынайтылган, гавамлашкан саф татар телендә язылырга тиеш, дигән карашны тәфсилләү максатыннан, басыла башлавына (01.10.1908) ел ярым гына узган «Шура» журналында, «Кәлям мөсабәкасы» исеме белән «Тел ярышы» ачыла. Игъланны, журналның мөхәррире итеп махсус чакырылган, тулаем мөселман дөньясына мәгълүм дини философ, тарихчы-галим, әдип һәм журналист Ризаэддин бине Фәхретдин яза: *«Ана телемезнең рәваҗ вә тәрәкъкыйына укучы вә язучыларның гайрәт вә һәвәсләре артуына сәбәб улсын өчен, ... 40 юлдан аз вә 60 юлдан күп улмас шарты илә, нә тугърыда*

*улса да улсын, һич бер чит сүз катыштырмай халис вә саф төркичә бер мәкалә язмакдан гыйбарәтдер...».* Ягъни ана теленең таралуы һәм үсеш алып алга китүендә укучы һәм язучыларның көч-тырышлыклары һәм дәрт-омтылышлары артуын теләп, «Кәлям мөсабәкәсе – Сүз/сөйләм ярышы» ачыла. Ягъни теләсә нәрсә турында һичбер чит сүз кулланмыйча, саф төркидә кыска бер мәкалә язуга өндәү яңгырый («Шура», игълан, 1909). Шулай итеп, «Нур» газетасы битләрендә татар халкының барлык зыялылары омтылган максатны тормышка ашыру өчен, дәрәҗәле матбугатта рәсми рәвештә мөмкинлек ачыла («Шура», 1909, № 15, август, б. 467).

«Кәлям мөсабәкасы» кысаларында язылган 72 мәкаләнең 55 е, тематик яктан чуар һәм төрле, ягъни авторлар үзләре нәрсә тели, шул турыда яза. «Ата-бабалардан сөйләнә килгән», «Берлекдә төрлек» кебек хезмәтләрдә үткән тарихка мөрәҗәгать итү яңгырый, яисә авыл тормышының төрле ягы – татар халкының гореф-гадәте, җыеннары турындагы язмалар, шулай ук авыз иҗатына тартым булган «Болгар кызы Айсылу», «Сакай баба тормышы» кебек хыялый-әкияти маҗаралы хикәятләр басыла, «Агыйделдә көймәдә» язмасындагы кебек елганың гүзәллегенә сокланып язылган күп темалар күтәрелә [Хөснетдинов, 2015, б. 62–63, 79–80, 94]. Авторлар үзләренең язмаларында гарәп-фарсы алынмаларын аз куллана, үз төбәкләренә хас булган һәм, гомумән, сөйләмә телгә хас булган сүз, сүзформа, тәгъбирләрен иркен файдалана. Аларга «саф төркичә» / «саф татарча», ягъни ана телебезнең сөйләмә формасына якын итеп язу өчен махсус тырышырга кирәкми. Бу мәкаләләрдә гасырлар буена килә торган халыкчан, сөйләмә телгә якын итеп язу дәвам ителә. Катнашучылар арасыннан бердәнбер авторга – язучы М. Гафурига, «Болгар кызы Айсылу» хикәяте өчен, беренче урын бирелә.

«Тел ярышы» кысаларында басылган 17 мәкаләдә төрки-татар теле, аның сөйләмә һәм язма формаларының үзенчәлеге, аларны ничек итеп кулланырга кирәклек турында, һәр авторга хас булган ысулда фикер әйтелә. Бу төрдәге мәкаләләр *төрек, төркичә* һәм *тел* дип башлана: «Бер төрекнең Тәңредән теләге», «Төркичә язу тугърысында», «Тел йөгертешү», «Тел чабыштыру», «Тел тугърысында», «Тел киңәше», «Миңлебайның тел тугърысында уйы», «Төркичә сөйләргә абдырадым», «Телсез төрек», «Тел ярышына» һ.б. [Хөснетдинов, 2015, б. 38–39, 45–46, 47–48, 53–54, 71–72, 85–88, 93–94, 116–117, 125–126, 139–140]. Авторларның берсе дә «Кәлям мөсабәкасы» дигән тәгъбирне кулланмый. Әлеге исемдәге язмаларны рәттән укып барганда, төрек, төрек-татар һәм төркичә-татарча төшенчә-атамаларының абсолют синоним-мәгънәдәш булып кулланылуы, чит сүзләр дигәндә, рус, гарәп һәм фарсы алынмаларының файдаланылуы истә тотыла. Бу нисбәттән Мөхәммәтрәхим

Кари Таҗетдин болай дип белдерә: «...Русча укыган белгечләремез, төрек теле арасына катышдырган рус сүзләрене без төрекләр, ...төрек теленә рус телене катыштырмак, шу илә килешмәс дисәк тә, үз белгечләребез бездән көләләр. Әй яхшы вә яманларны исергәүче! Без төрекләрне үзең исергә! Багланмыш телемезне, сукраймыш күземезне ач», – дип автор Тәңрегә ялвара («Шура», 1909, № 19).

Мәчетләрдә сөйләнә торган хөтбәнең дә ана телендә булырга тиешлегенә басым ясала. «Тел ярышы»нда катнашучылардан танылган дин белгече, әдип-журналист, имам-мөдәррис Г. Гафуров-Чыгтай (1867–1942), «Икътисад» журналының нашир-мөхәррире, педагог, репрессия корбаны Фатих Шиһабетдин улы Мортазин (1875–1937), мөгаллим, телче, фольклорчы галим Хәсән Гали (1878–1940) – өчесе дә, бик тырышканда, телә-сә нәрсә тугрысында, чит сүз катнаштырмыйча, татар теленең үз сүзләре белән дә язып була, әмма ул язма телне тарайта торган, көчәнеп язылган, тозсыз эш булып чыга, дигән уртак нәтиҗәгә киләләр. Аерым гарәп һәм фарсы сүзләре төрки-татар сүзләре белән алмаштырылып күрсәтелә: *шура – киңәш, саф төрек теле – таза төрек теле, мәкалә – бетү, халык – җорт, әдип (язучы) – телмәр, каләм – бетәү, вакыт – чак, лөгать – сүз* һ.б. Мәкаләләрдә кулланыла торган чит тел сүзләре саналып күрсәтелә бара. Әлеге тәртип сакланган хәлдә, 1909 елда «Тел ярышы»на тәгаенләнгән 8 мәкалә, 1910 елда 4 мәкалә басылгач, 1910 елның 5 нче санында Идарә тарафыннан бу мәкаләләрне «Рисалә рәвешендә берьюлы басып чыгарырга карар бирелде», – дигән игълан басыла. «Шура»ның 11 нче санында мөхәррир «Саф төрки теле белән йазмак тугърысында...» дип башлана торган мәкаләсендә әлеге эшчәнлеккә нәтиҗә ясый. Аны журналның 14 нче санында «Саф татарча» дигән баш астында яңадан кабатлый: «... Төркичә безгә йат телләрдән катышыб язганга, шикаять итүчеләр бик күб. Татарча гына язу кирәк иде диләр. «Шура» идарәсе татарча гына язуны тәҗрибә кыйлуб карар өчүн, «Тел ярышы» ачкан вә татарча гына язучыга мөкяфәт тәгаин иткән... Телемез өчүн мәкаләләр бергә җыйыб бастырылды» («Шура», 1910, № 14).

Шулай итеп, мәкаләләрнең журналда дөнья күргәннәре дә, анда басыла алмыйча калганнары да, кабул ителү тәртибе сакланганы хәлдә, бергә тупланып, аларга карата язылган тәнкыйть фикерләре белән бергә, «Шура»ның тел ярышы» дигән җыентыкта урын ала [Фәхретдин, 1910]. Әлеге җыентыкка карата Р. Фәхретдин, Россиядәге төрки халыкларның үзара язышкан хатларында чит сүзләр аз кулланыла, әмма башка төрле язу язганда, әллә ничә төрле ят сүзләр кыстыруга мәҗбүрият күреләдер, мәктәп вә мәдрәсәләребездә тел дәресләре укытылса, эш башкача булачак, дип йомгак ясый («Шура», 1911, № 17, б. 529). Димәк, тел турында язылган күпсанлы авторларның мәкаләләреннән һәм

мөхәррирнең йомгаклау сүзеннән аңлашылганча, «...нә тугърыда улса да улсын һич бер чит сүз катыштырмай, халис вә саф төрки телдә», ягъни халыкның саф сөйләмә телендә генә теләсә нәрсә турында язырга мөмкин булмавы, «татарча гына язуны тәҗрибә кыйлыб карау»ның тормышчан түгеллеге раслана.

Шулай итеп, журналның мөхәррире Р. Фәхретдин тарафыннан оештырылган «Кәлям мөсабәкасы» – «Тел ярышы» барышында татар филологиясендә XX гасырның 60–70 нче елларында гына, язма әдәби телнең тарихы-дәвамчанлыгы булуы, иҗтимагый тормышны алып бару юнәлешендә төрле вазифа/функцияләрне үтәргә тиешлеге, язма телнең диалектлардан өстенлеге кебек катлаулы проблемаларны объектив дәрәҗәдә аңлау һәм фәнни тикшерүнең нигезе салына [Бәширова, 2012, б. 75–78]. Әмма бу мәсьәләнең мөһимлеге, объектив һәм субъектив сәбәпләр аркасында, ни кызганыч, безнең көннәргә кадәр тәфсилләп аңлатылмый. Җыентык басылып чыккач та, аның Г. Тукай тарафыннан «“Тиле ярыш” кеби чүпләр» дип [Тукай, т. IV, 1956, б. 59] бәяләнүе һәм кире тәэсирнең үзен сиздерүе, шагыйрьнең «...һәр эшләребез үз арабызда “Шура” белән эшләнергә тиештер» [шунда ук, б. 63] дигән фикеренең бер вакытта да искә алынмавы мәгълүм.

XX гасырның 30 нчы елларыннан башлап, соңгы чирегенә кадәр «Вакыт», «Шура», «Йолдыз» кебек газета-журналларына: «...милләтче, татар буржуа иясе органы» дигән кара мөһерләр сугылуын беләбез [Мәрданов, 1999, б. 239]. Алга таба «татар халкы арасында үтә реакцион, панисламизм һәм пантюркизм идеалларын пропагандыйлар», – дигән фикернең тарих китапларында урын алуы һәм татар галимнәре тарафыннан кабатланып торуы билгеле [Татар әдәби теле тарихы, I т., б. 150–153].

«Шура» журналы ябылганнан соң (1918), ярты гасыр буена «...буржуаз милләтчелек агуын тараткан, әдәбияттагы реакцион идеяләрне яклаучы, расачыл, чуар журнал» дип бәяләнеп килә торган басмада «милләткүләм гомуми мәсьәләләр яктыртылуына» игътибар итеп, 1959–1962 елларда Казан дәүләт университеты студенты Миркасыйм Госманов «Шура» журналының тулы библиографик күрсәткечен төзи. Ун ел дәвамында тәртипле һәм эзлекле булып чыгып килә торган журналның 240 санындагы һәр мәкалә, язма тасвирланып, тематика буенча бүленә һәм 2 томлы хезмәт төсен ала. Әмма бу кыйммәтле хезмәт, 2000 елда (аның авторы академик булганнан соң) гына басылып чыга [Госманов, Мәрданов, 2000].

Югарыда әйтелгәннәргә нәтиҗә ясап, шул фикерне ассызыкларга кирәк: XIX гасыр ахыры – XX йөз башында, яңа сулыш алып, татар халкын мәгърифәтле, тәрбияле итү максатыннан дөнья күргән данлыклы газета-журналларыбыз – 1883 елдан Бакчасарайда үз эшчәнлеген алып барган «Тәрҗеман» (1883–1918) газетасы, Оренбургта бертуган Шакировлар акчасына,

Риза Фәхретдин мөхәррирлегендә бастырылган «Вакыт» газетасы (1906–1918), «Шура» журналы (1908–1918), Казанда нәшер ителгән «Йолдыз» газетасы (1906–1918) ябылуга быел 100 ел тулды. Әлеге исемлекне революция шаукымына кадәр ябылган «Нур» (1905–1914), «Казан мөхбире» (1905–1911) кебек газеталар тагын да тулыландыралар.

**Әдәбият**

*Баязитов Г.* Татарча мөхәррирдән берничә сүз // «Нур». 1905. № 4.

*Бәширова И.Б.* Татар әдәби теле тарихы. Гомумтеоретик мәсьәләләр: татар әдәби теленең билге-шартлары һәм аларның өйрәнелеше. Казан, 2012. 255 б.

*Госманов М.Г. Мәрданов Р.Ф.* «Шура» журналының библиографик күрсәткече. Казан: Милли китап, 2000. 264 б.

*Мәрданов Р.Ф.* «Шура» журналы // Гасырлар авазы = Эхо веков. 1999. № 1/2. Б. 227–247.

*Татар әдәби теле тарихы* (ХШ г. – ХХ йөз башы) 1 т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. Казан: ТӘҺСИ, 2015. 696 б.

*Тукай Г.*Фәлсәфи сүзләр // Габдулла Тукай Әсәрләр: дүрт томда. Т. IV. Казан: Таткнигоиздат, 1956. Б. 58–59.

*Фәхретдин Р.* «Кәлям мөсабәкасы» Игълан // «Шура». 1909. № 15.

*Фәхретдин Р.* «Шура»ның тел ярышы. Оренбург: Вактъ, 1910. 195 б.

*Хөснетдинов Р.М.* «Шура» журналында язма әдәби тел мәсьәләләре (1908–1917) / Россия мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан милли фәнни тикшеренү технология ун-ты. Казан: КМТТУ нәшрияты, 2015. 164 б.

*Хөснетдинов Р.М.* «Шура»ның тел ярышы. Транскрипция: хрестоматия / Россия мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан милли фәнни тикшеренү технология ун-ты. Казан: КМТТУ нәшрияты, 2015. 164 б.

***Хөснетдинов Радик Мәүлитҗан улы***,
*филология фәннәре кандидаты, Казан милли тикшеренү технология университеты доценты*

УДК 398.2

***Р.Ф. Мәрданов***

# ГЫЙЛЕМ БӘЙГЕСЕНӘ БАГЫШЛАНГАН ӘСӘР: «ДАСТАНЕ ҖАЙӘ»

Представленная статья посвящена древнему эпическому произведению «Дастани джайэ», сокращенный и изменённый вариант которого впоследствии стал известен под названием «Малика китабы» (Книга о Малике). Дастан основан на древневосточном сюжете о мудрой деве, всемирно известной под именем Турандот.

**Ключевые слова:** «Дастани джайэ», Турандот, эпос, рукопись.

Татарлар арасында «Мәликә китабы» исемендәге мәшһүр китапчык булуы мәгълүм. Аның кулъязма күчермәләре күп таралган, 1846 елдан башлап, XX гасыр башына хәтле дистәдән артык басмасы дөнья күргән. Археографик экспедицияләрдә «Мәликә китабы»ның язма һәм басма нөсхәләре еш очрый. Кулъязмалары, күбесенчә, XIX гасырга караса да, XVIII гасыр ахырына нисбәтлеләре дә фәнгә мәгълүм [Дмитриева, с. 468–469]. Эчтәлеге басма «Мәликә китабы»на туры килә торган кулъязмаларның Татарстан Милли китапханәсендәге иң әүвәлгесе («706 т» шифрлы) XIX гасыр уртасына нисбәтле.

Халкыбызның кулъязма мирасы шулкадәр бай ки, кызыклы ядкәрләр һаман табылып, елдан-ел ачыкланып тора. Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат Заһидуллин белән китапханә хезмәткәре Ирек Заһидуллин тарафыннан 2016 елның җәендә Арча районы авылларына оештырылган археографик экспедиция вакытында табылган XVII гасыр кулъязмаларының берсе игътибарыбызны аеруча җәлеп итте. Арча районының Югары Пошалым авылында яшәүче Нургали Зарипов тапшырган кулъязма җыентыкта «Мәликә китабы»ның борынгырак бер варианты теркәлгән булуын ачыкладык. Кулъязмада аның исеме «Дастане җайә» дип күрсәтелгән. Дастан дигән сүз үзе үк борынгы дәвер әсәрләренә хас булуы белән үзенчәлекле. Мәсәлән, Җөмҗөмә дастаны, Кисекбаш дастаны, Аксак Тимер дастаны, Түләк-Сусылу дастаны, Идегәй дастаны һ.б.

Милли китапханәдә «2221т» шифры белән саклана торган «Дастане җайә» тексты теркәлгән кулъязма җыентык барлыгы 58 кәгазьдән тора. Зурлыгы 15×19 см үлчәмле кәгазьләрнең берничә төрле су билгеләренә (филиграньнәренә) караганда, алар 1655–1671 елларда Голландиядә эшләнгән булса кирәк. Димәк, бу кулъязманы XVII гасырның соңгы чирегендә язылган дип билгеләп була. Җыентыкта «Дастане җайә»дән тыш, намаз-гыйбадәткә һәм дин

нигезләренә багышланган татарча, гарәпчә текстлар урын алган. Кульязманың сакланышы уртачадан түбән, чөнки шактый кәгазьләре дефектлы, табигый таушалу-тузу белән бергә, язу карасы үтәли тишкәнлектән битләре тетелгән.

Дастан тексты моңа хәтле тулы хәлендә билгесез булып, «Дастане җайә» дигән атамасы да мәгълүм түгел иде. Әлеге текстның сюжетына охшаш башка чәчмә һәм шигъри әсәрләр әдәбият тарихында мәгълүм, ә кыскартылган варианты «Мәликә китабы» буларак танылган. Һәрхәлдә, бу дастанның тексты бөтен килеш очраганы һәм өйрәнелеп, матбугатта чыгарылганы булмады.

Әсәр исемендәге «җайә» дигән сүз текстта бер мәртәбә дә кабатланмаган. Ләкин дастанның эчтәлегенә күрә аның мәгънәсен фаразларга мөмкин. Фарсы телендәге «җай» сүзе – «урын», гарәп телендәге «җәәә» сүзе «килү, кайту, башкару» кебек мәгънәләргә ия. Шунлыктан, әсәрнең исемендәге «җайә» сүзен «урнашу, җәмгыятьтәге урынга (дәрәҗәгә) ирешү-кайту» күздә тотылган дип аңлатырга мөмкин. Бәлки бу атамадагы «җайә» сүзендә берәр хәрефе (мәсәлән «р») төшеп калгандыр, һәм ул «җария» дип язылсы булгандыр дип тә гөманлап була. Әмма «җария» сүзе, гадәттә, хезмәтче кыз, кол кыз дигән мәгънәләрдә йөргәнгә күрә, аның әсәрдәге патша кызына карата кулланылган булуы бик шикле. Шулай ук «җайә» сүзе язылышында ниндидер хәреф төшеп калган булса, күчерүче яки кульязманы укучылар тарафыннан ул өстәлгән һәм төзәтелгән булыр иде. Әсәрнең төп текстына өстәмә һәм төзәтмәләр кертелгән булуы шундый нәтиҗәгә этәрә.

Татарстан Милли китапханәсе тарафыннан нәшер ителә торган «Татар археографиясе» сериясенең 10 нчы китабында «Мәликә китабы»на охшаш сюжетлы «Кыз хикәяте» исемле күләмле шигъри кыйсса тексты дөнья күрде. Аның XVI гасырның беренче яртысында иҗат ителгән нәзыйрә әсәр булганын ачыклап, авторы шагыйрь Мөхәммәдъяр булуы ихтимал дигән фаразыбызны белдергән идек [Кыз хикәяте]. «Кыз хикәяте» турындагы күләмле мәкалә «Татар әдәбияты тарихы» күптомлыгының соңгы басмасында да урын алды [Татар әдәбияты..., б. 123–139]. Әлеге хикәят Алтын Урда дәверендә – 1382 елда Ибраһим исемле шагыйрь иҗат иткән әсәрне үстереп, нәзыйрә рәвешендә язылган. «Дастане җайә»нең дә эчтәлеге Ибраһим әсәренә һәм «Кыз хикәяте»нә шактый якын. Бигрәк тә, дастанның башлам һәм бетем өлешләре шигъри текстларга аваздаш. Ә басма «Мәликә китабы» текстларында ул урыннар кыскача хикәяләнгән. Ә менә, дастанның сорау һәм җаваплардан торган үзәк өлеше басма «Мәликә китабы» текстларына якынрак.

«Дастане җайә» эчтәлегенең Ибраһим әсәре һәм «Кыз хикәяте»нә якын булуына карап, аларның кайсысы алданрак иҗат ителеп, кайсысы аның үрнәгендә язылган икән дигән сорау туа. Әлбәттә, бу сорауга җавап табу

шактый читен. «Дастане җайә»-дә кызның сораулары 130 булып, Ибраһим әсәрендә 33 һәм «Кыз хикәяте»ндә 21 генә сорау бирелүенә карап фикер йөрткәндә, дастан тексты соңгырактыр дип фаразлау мантыйкка яраклы кебек. Әмма, шигъри әсәрләрдә сюжетның авторлар ихтыярынча кыскартылган булуы да мөмкин бит. Әйткәнебезчә, бу катлаулы мәсьәләгә җиңел генә җавап табу бик кыен. Ләкин, шуңа карамастан, Ибраһим әсәре белән дастанның әүвәлгерәк чыганакка нигезләнеп, Алтын Урда дәверендә, төгәлрәге XIV гасырда иҗат ителгән булуы мөмкин. Дастанның теле Рабгузи тарафыннан XIV гасыр башында иҗат ителгән «Кыйсасел-әнбийа» әсәренә шактый якын булуы да бу фикерне куәтли.

Дастанның XVII гасыр кулъязмасында сакланып, безнең көннәргәчә килеп ирешүе бик мөһим. Бу факт – әлеге әсәрнең борынгырак чорда иҗат ителгәнлегенә бер дәлил. Аның XVII гасыр күчермәсендә саклану факты, «Мәликә китабы» XIX гасырда иҗат ителгән әсәр дип, фәндә урнашкан фикернең [Гайнуллин, б. 20; Хафизов, б. 22] дә ялгыш булуын ачык раслый. Андый карашның дөрес түгеллеге турында «Дастане җайә» кулъязмасы табылганчы ук, «Мәликә китабы»ның XVIII гасыр күчермәләре дә сакланганын әйтеп, аңлатып язган идек [Кыз хикәяте, б. 141].

«Дастане җайә»нең XVII гасырдан да элеккерәк күчермәсе булу-булмау ихтималына килгәндә, татар археографиясенә хас гомуми бер күренешне искә алырга кирәк. Татар кулъязма истәлекләренең XVIII гасырдан борынгырак чорларда иҗат ителгәннәре иҗтимагый, тарихи һәм табигый сәбәпләр (сугышлар, көчләп чукындыру, тузу, таушалу, янып юкка чыгу, дингә каршы көрәш, башка төрле бәлаләр) аркасында аз сакланып калган. XVI–XVII гасырларда иҗат ителгән әсәрләр аеруча сирәк нөсхәдә генә очрый. Әүвәлрәк язылган «Кыйссаи Йосыф» поэмасының да йөзләгән күчермәләре арасында XVII гасырга караганнары санаулы гына, барысы да диярлек XVIII һәм XIX гасырлардагы кулъязмаларда сакланган. Менә бу хәлгә бәйле рәвештә, галимнәр иске язма ядкәрләрнең иҗат ителү чорын билгеләгәндә, даталары күрсәтелгән кулъязма күчермәләренә нигезләнеп, кайбер әсәрләрнең язылу вакытын ялгыш билгелиләр.

Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исем. Фәнни китапханәсендә «Дастане җайә»нең тулы булмаган күчермәсе саклана. Ул XIX гасыр башына караган, хикәяләр һәм дини мәсьәләләр язылган җыентык эчендә. Катыргы тышлыклы, 7×11 см үлчәмле, «542 т» шифрлы әлеге кулъязма җыентык хәзерге Татарстанның Арча районындагы Мәмсә авылында табылган. Бу кулъязма 1920–1930 елларда күренекле татар археографы Сәед Вахиди милкенә кергән, кайбер битләрендә шуны раслый торган мөһер бар. Әлеге җыентыкта дастан тексты 62б–68б кәгазьләрдә язылган. Анда әсәрнең исеме күрсәтелмәгән, башын-

нан алып, тулы текстның якынча дүрттән бер өлеше теркәлгән. Ул дүрт изге китапның кемнәргә иңүе турындагы җавап язылганнан соң дәвам итмичә, өзелеп калган. Текст шактый хаталы, урыны-урыны белән җөмләләр, сүзләр, кайбер сорау-җаваплар төшеп калган. Шул ук вакытта Татарстан Милли китапханәсе нөсхәсендә булмаган кайбер өстәмәле урыннары да бар. Әлеге күчермә ачыклануның мөһим ягы шунда ки, Татарстан Милли китапханәсе күчермәсендәге 15 нче кәгазьнең түбәнге юллары ертылган булуы сәбәпле, өзеклек кергән өлешен университет кульязмасы ярдәмендә тулыландырдык. Ул күчермәдәге хаталарның шактый тупасларыннан кайберләрен әйтеп китик. Мәсәлән, Мәликә исеме Дәляк диелгән. Бәлки ул элекке протографында ук ялгыш язылган булгандыр. Шулай ук «кырык» сүзе «фәрикъ», «бигөнаһ» сүзе «бер генә» рәвешенә үзгәргән һәм шуларга охшаш башка хаталар да бар. Татарстан Милли китапханәсе нөсхәсе белән чагыштырганда, кайбер архаик сүзләрнең алмаштырылуы да күренә. Мәсәлән, «камуг» сүзе университет нөсхәсендә «җәмигъ» дип, «тигде» сүзе – «барды», «асыглыйг» сүзе – «асылмыш», «аты» сүзе – «исеме», «кичкәйсез» сүзе «кичәрсез» рәвешләрендә үзгәргән.

Татарстан Милли китапханәсенең 2017 елда Арча районына оештырылган археографик экспедициясендә «Дастане җайә»нең XVIII гасырга караган, тулы булмаган тагын бер күчермәсе табылды.

Әлеге дастан текстының башкачарак күчермәләре Россия Фәннәр академиясенең Санкт-Петербург шәһәрендәге Көнчыгыш кульязмалары институтында да саклана. Ул кульязмалар белән тулысынча танышу мөмкинлегебез чикләнгәнлектән, аларга кыскача гына тукталырга туры килә. Кульязмаларның 1864–65 елларда күчерелгән, «Кыйссаи Мәликә» дип исемләнгән һәм Идел буенда табылып, «D 433» шифры белән саклана торганының тексты «Дастане җайә»гә шактый якын. «B 348» шифрлы икенче кульязма да XIX гасырныкы һәм ул Көнчыгыш Төркестанда – Синьцзяньдә табылган. Монысының тексты «Дастане җайә»гә охшаш булса да, теле чыгтайча һәм эчтәлегендә дә аермалар күп. Әйтелгән кульязмаларда патшаның исеме Гасараһ диелгән. Бу кульязмаларның тасвирлары Л.В. Дмитриева каталогында басылган [Дмтриева, с. 201, 460, 469].

«Дастане җайә»нең без күреп танышкан тулы һәм фрагмент хәлендәге күчермәләре шушылар. Әлбәттә, аның нөсхәләре тагын да бардыр һәм табылып ачыкланырлар дип уйлыйбыз.

### Дастанның кыскача эчтәлеге

Рум шәһәренең патшасы Гасаран, балалары булмагач, Кәгъбәгә барып кырык корбан чалып, Аллаһы Тәгаләдән үзенә бала бирүне сорап ялвара. Аллаһы Тәгалә аның теләген кабул итә. Өенә кайтуына бер кызы дөньяга килә, аңа Мәликә дигән исем куя. Гаять акыллы, зирәк һәм чибәр бу кыз кебек белемле башка кеше булмый.

Атасы кызын җир астында яшереп, 20 яшенә хәтле гыйлем өйрәтә. Кияүгә бирү вакыты җиткәч, кыз үзе кебек белемле кешегә генә чыгачагын шарт итеп куя. Әтисе аның сүзенә каршы килми.

Әтисе вафат булганнан соң, кызы аның тәхетенә утыра. Бер көнне тәхеткә утырып, бәкләргә үзенең йөз соравына җавап биргән кеше белән генә никахланачагын белдерә һәм: «Патшамы, дәрвишме, гади кешеме – шартым үзгәрмәс», – ди. Бу хәбәр төрле шәһәрләргә һәм илләргә тарала. Бөтен галимнәр кызның соравына җавап бирү өчен җыела башлыйлар.

Кыз «җавап бирә алмасагыз һәлак ителәчәксез» дип кисәтә. Галимнәр, чынлап та, җаваплар таба алмыйча гаҗиз булалар һәм дарга асылалар. Кыз аларга: «Ник болай зур дәгъва кыласыз, үз-үзен белгән һәркем һәлак булмас», – дип, тәкәбберлекләрен шелтәли.

Мәликә күпмедер еллар патшалык иткәч, бу хәбәр Румнан Төркестанга ирешә. Анда үз байлыгының хисабын белмәс дәрәҗәдәге чиксез мөлкәт иясе яшәгән. Гомерендә дә мохтаҗлык күрмәгән ул байга, көтмәгәндә, Аллаһтан каза ирешеп, бөлгенлеккә төшкән, көн күрерлек бер нәрсәсе дә калмаган. Шул кешенең Габдулла исемле галим улы булган. Улы әтисен: «Дус-дошман арасында бу хәлдә үлгәнче, кая да булса китик», – дип өнди. «Аллаһы Тәгалә ни боерса, шуны күрербез», – дип тәвәккәлләп, алар юлга чыга. Чарасызлыктан, ач үлемгә дучар булу хәвефеннән саклану өчен, егет эти-әнисен берәр байга сатарга ниятләп, ризалыкларын ала. Базарда бер патша юлыгып, егет әтисен – бер ат, әнисен тун бәясенә сата.

Егет үзе Румга юл тота. Анда бер карчыкта төн кунарга тукталгач, дарга асылган кешеләрнең кемнәр булуын сорый. Карчык, патшабикәнең никах шартын әйтеп, аларның җавап таба алмыйча асарга дучар булган галимнәр икәнлеген әйтеп бирә. Фәкыйһ егет: «Аллаһы Тәгалә ни боерса – шул булыр», – дип, кызның сорауларына җавап бирергә ниятли. Мәликә аны: «Зур дәгъва белән гөнаһсыз җаныңны харап итәрсең» дип кисәтә. Егет исә Коръәндәге: «Аллаһы Тәгаләдән башка һәрнәрсә һәлак була...» – дигән сүзләрне искә алып, ниятенең какшамаслыгын белдерә. Кыз: «Йөз соравыма җавап тапсаң – никахыңда булырмын, юк икән – каның түгәрмен!» – дип, үз шартын кабатлагач, күпсанлы сорау-җавап бәйгесе тасвирлана. Сорауларның күбесе Ислам дине нигезләренә, Коръәнгә һәм пәйгамбәрләргә бәйле. Шулай ук дини һәм хорафи риваятьләргә, дөньяви мәсьәләләргә караган сораулар да бар. Кайбер җавапларга карата кыз өстәмә дәлилләр дә сорый. Егет дәлил итеп Коръән сүрәләреннән аятьләр әйтә. Текстта андый очраклар барлыгы 11 урында. Алардан башка да берничә мәртәбә Коръән аятьләре китерелгән. Кыз галим егетнең җавапларын ике урында тагын да яхшырак аңлатырга боера. Җаваплар аеруча камил булганда, кыз канәгатьләнеп, «Саддәка!» (дөрес, хуп, афәрин) дип, хуплау сүзләре әйтә.

Өч көн дәвамында кызның 130 соравына уңай җаваплар биргәннән соң, егет үзе бер соравын яңгырата. «Атасын – атка, анасын тунга сатып, үзе теләнче булып киткән кеше кем ул?» – дигән сорауны бирә. Кыз җавабын таба алмыйча, иртәгә килерсең, аңарчы фикерләп карыйм, дип вакытны чигерә.

Егет шатланып карчык өенә кайта. Мәликә төн уртасында ризык һәм шәраб алып, бер җариясен ияртеп, егет янына килә. Үзенең кем икәнен белдермичә: «Сиңа гашыйк булдым, хан кызына күркәм җаваплар бирүеңә бөтен халык гаҗәпләнде», – дип «сайрый». Ашап-эчеп, хуш мәҗлестә төн үткәрәләр. Кыз хәйлә белән егеттән соравының җавабын әйттерүгә ирешә. Ул киткәндә егет йоклап кала. Уянгач, төн кызының кем икәнен төшенеп, борчыла. Тик ятагында алтын йөзек күреп ала. Аның якут кашына кызның исеме язылган. Сөенеп, сарайга килә. Кыз исә төнлә алтын-көмеш остасына боерып, шундый ук йөзек ясатырга өлгергән була. Ул егет соравының дөрес җавабын әйтеп бирә.

Ләкин егет бикләргә һәм вәзирләргә: «Төнлә бер күгәрчен куеныма кергән иде, бер канат йоны өзелеп калды» – дип, йөзекне күрсәтә. Кыз йөзеге үзендә булуын әйтсә дә, икесен чагыштыргач, аларның берсе – яңа, икенчесе – иске икәнен ачыклыйлар. Остадан да сорап белешәләр, ул кызның төнлә мең алтын биреп эшләткәнен әйтә.

Ниһаять, Мәликәне бу егеткә никахлыйлар. Егет әти-әнисен үз янына алдыра. Аларны базарда сатып алган солтан да, үз гамәлен Аллаһ хакына кылганын әйтеп, иреккә җибәрә. Шулай итеп, зирәк егет патшабикәгә никахланып, әти-әнисе белән дә күрешү бәхетенә ирешә, хуш гомер кичерәләр. Әсәр шулай тәмамлана.

* * *

«Дастане җайә»нең эчтәлегеннән аңлашылганча, аның төп фикере гыйлем дәрәҗәсен олылаудан гыйбарәт. Диндарлык һәм белемнең куәте гадел хөкемдар мәсьәләсенә дә бәйләнгән. Егетнең ата-анасы бай сәүдәгәрлектән бөлгенлеккә төшүе мисалында гыйлемнең мәртәбәсе өстенрәк булуы күрсәтелгән. Фәкыйһ егет Коръәнне, Ислам дине тарихын һәм шәригать өйрәтмәләрен тирәнтен белгәнлеген дәлилли. Кыз һәм егет үз сорау-җавапларында чиксез хакыйкать һәм гаделлек чыганагы булган Коръәнгә таянганнар. Мохтаҗлык, ачлык һәм коллык сынауларын Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәлләп һәм сабырлык белән үтеп, әти-әнисе белән яңадан бергә булуга һәм элеккедән дә мулрак тормышка ирешүгә төп сәбәп – белем икәнлеге аңлатылган.

Дастанның бетем өлеше берникадәр Әюп пәйгамбәр кыйссасына аваздаш. Аның диндарлыгы һәм сабырлыгы Рабгузи китабында тәфсилләп сөйләнеп, ахырдан җәмәгате һәм балалары белән кавышуы тасвирланып, «хәлләре борынгыдан яхшырак булды» дип әйтелгән [Кыйсасел-әнбийаи..., б. 226].

## Әсәр калыбының тамырлары һәм тармаклары

Борынгы дәверләрдә Шәрыкта туып, соңрак Европаның әдәби мәйданында гасырлар дәвамында төрле вариантлары иҗат ителгән һәм камилләшкән мавыктыргыч сюжетның тамырлары һәм тармаклары турында «Татар археографиясе» сериясенең 10 нчы китабында киң мәгълүмат бирелгән [Кыз хикәяте, б. 3–46, 114–181]. Анда Сөләйман пәйгамбәр һәм Бәлкыйс кыйссасы, борынгы әрмән телендәге «Егет һәм кыз турындагы хикәят», Низами поэмасы, Борынгы Шәрык хикәятләре, «Мәликә китабы», «Мәҗмугыл-хикәят» җыентыгындагы Хәләф белән Чин кызы хикәяте, Гоцци әкияте, Фатыйх Халиди хикәятләре, Шиһабетдин Рәхмәтуллин әсәре, «Маһифәйрүзә» хикәясе, татар халык әкиятләре, Кәрим Тинчуринның Гоццидан тәрҗемәсе турында тәфсилләп язылды. Борынгы сюжетның бигрәк тә безнең татар җирлегендәге үрнәкләренә күзәтү ясап, эчтәлекләре белән кыскача рәвештә таныштырдык.

Бай тарихлы «Мең дә бер кичә» китабының 436–461 нче кичәләрендәге «Тәвәддүд турындагы хикәят»тә [Книга тысячи..., с. 9–74] «Дастане җайә»гә охшаш урыннар очрый. Хикәяттә бирелгән сораулар арасында Коръәндә телгә алынган 25 пәйгамбәр исеме, Коръәннең беренче һәм иң соңгы иңгән аятьләре, Адәм галәйһиссәламнең ни өчен шулай дип аталуы, күз-авыз һәм аяк-куллар; ут-су һәм туфрак, ярканат, «кяф»-«нун», җиде кат күк һәм җиде кат җир, атасыз-анасыз туган затлар турындагылары «Дастане җайә»дәге кебек.

«Мең дә бер кичә»дән тыш, борынгы Шәрык хикәятләренең «Мең дә бер көн» исемендәге җыентыгы да булган. Ул фарсы теленнән французчага, аннан исә төрек теленә һәм русчага тәрҗемә ителгән. Төрек телендәгесен Идел–Урал татарлары да укыган һәм татарчага тәрҗемә иткән. Андагы «Шаһзадә һәм Кытай патшасының кызы турында» дигән хикәят «Дастане җайә» сюжетына туры килә.

1382 елда Алтын Урда чоры шагыйре Ибраһим 420 бәйттән (840 шигъри юлдан) торган кызыклы бер әсәр иҗат иткән. Анда тасвирланган сорау-җавап бәйгесендә кыз барлыгы 33 сорау биргән. Аларның җидесе (ата-анасыз туган дүртәү; Муса пәйгамбәр таягы; агач һәм унике ботагы; төн һәм көн; ярканат; кошлар; кешедән үзгәртелгән җанвар-кошлар турындагы сораулар) һәм егетнең үзе турындагы соравы дастандагыларга туры килә.

Шагыйрь Ибраһим әсәренә назыйрә итеп язылган, XVI гасырның беренче яртысына нисбәтле «Кыз хикәяте» барлыгы 348 бәйттән гыйбарәт. Хикәяттә кызның 21 соравы һәм егетнең җаваплары тасвирланган. Шулардан бишесе (анасыз туган дүртәү; агач һәм унике ботагы; ярканат; кошлар; кешедән үзгәртелгән җанвар-кошлар турындагы сораулар) «Дастане җайә»дәге кебек үк. Ахырдан егетнең кызга үзе биргән соравы да дастандагыча.

Әүвәлрәк кульязма хәлендә таралган, кечкенә форматлы, 16 битле китапчык рәвешендә

XIX гасыр уртасыннан XX гасыр башына кадәр күп мәртәбә басылган һәм яратып укылган «Мәликә китабы» – «Дастане җайә»гә иң охшаш әсәрләрнең берсе. Аларның төп нигезе бер үк. «Мәликә китабы»ның элеккерәк чордагы «Дастане җайә»нең кыскартылган варианты икәнлеге дә аңлашыла.

«Мәликә китабы»ның Казан басмасыннан аермалырак тексты шәркыятьче галим, тюрколог И.Н. Березин җыентыгында дөнья күргән [Турецкая хрестоматия..., с. 114–126]. Ул әсәрнең өзеге дип урнаштырылган, ахыры юк. Анда Казан басмасындагы сораулардан аермалылары да бар. Шулай ук басмада булмаган, ләкин «Дастане җайә»дәге сорау-җавапларга туры килә торганнары да урын алган.

«Мәликә китабы»ның 1904 елда Ташкент шәһәренең В.М. Ильин матбагасында литография (ташбасма) ысулы белән басылган варианты шактый күләмле – 120 битне тәшкил итә. Аның «Китабе мәликәи данишмәнд һәзар сөали мәшһүр мәга сөали мөтәфәррика» атамасы, татарчага тәрҗемә иткәндә, «Укымышлы мәликәнең бик күп мәшһүр һәм төрле сораулары турындагы китап» дигәнне белдерә.

«Мәҗмугыл-хикәят»тәге «Шул хикәятдер кем, бер падишаһ Хәләф атлы угылы булып, Фәгъфур Чинның кызы белә берничә мәсьәлә араларында улып, күп вакыйгалар үткән хикәятләредер» дип исемләнгәне «Дастане җайә» сюжетына охшаш. Ул хикәяттә кыз Хәләфкә барлыгы 25 сорау биргән. Аларның алтысы (ут, су, туфрак; тере пәйгамбәрләр; ата-анасыз туган затлар; Муса пәйгамбәр таягы; Гозәер пәйгамбәр; агач һәм унике ботагы) һәм егетнең кызга биргән соравы «Дастане җайә»дәгеләргә охшаш.

Италия драматургы Карло Гоцциның бу сюжетка нигезләнгән һәм 1762 елда сәхнәләштерелгән «Турандот» исемле биш пәрдәлек әсәре искиткеч зур уңышка ирешкән [Гоцци, с. 208].

Гоцци әсәреннән бик тәэсирләнгән немец шагыйре һәм драматургы Иоһанн Шиллер аны алман теленә тәрҗемә иткән. Н. Исмәгыйлев язганга караганда, «Турандот» сюжетына нигезләнеп сигезләп опера иҗат ителгән [Исмәгыйлев, б, 182]. Шулар арасында иң уңышлысы итальян композиторы Джакомо Пуччини операсы булган.

Татар әдибе Мөхәммәтфатыйх Халидинең Казанда 1897 елда басылып чыккан «Хикәят: Болгарның солтане гадил *(гадел солтан)* Туктамыш хан кызы Хәлимәнең бәхәсе» исемле, сигез битле китапчыгы шул ук сюжетка нигезләнгән. Китапның тышлыгында: «Бу хикәятне иске китаплардан җыеп яздым», – дигән искәрмә бирелгән. Шул ук авторның Казанда Харитонов матбагасында 1904 елда сигез битле китапчык рәвешендә басылып чыккан «Кемгә тиеш?» исемле тагын бер хикәятенең сюжеты алдагысына охшаш.

Шиһабетдин Рәхмәтуллинның шундый сюжетка корылган «Каләф берлә Турандук хикәяте» төрек телендәге «Әлфе нәһар вә

нәһар» (Мең дә бер көн) исемле әсәргә нигезләнгән [Шиһабеддин бине...].

Әлеге сюжетка нигезләнгән әкият вариантлары халкыбыз арасында да таралган.

Татар драматургы Кәрим Тинчурин 1917 елда Карло Гоцци пьесасын иректе рәвештә тәрҗемә иткән һәм «Хан кызы Турандык» дип атаган. Бу әсәр беренче мәртәбә «Сәйяр» татар театр труппасы тарафыннан 1918 елның гыйнварында Казан шәһәренең Зур театрында сәхнәгә куелган.

Соңгы елларда «Турандот» әсәрен, татар һәм Кытай сәхнә осталары бергәләп, яңартылган рәвештә сәхнәгә чыгардылар. Сценарийга нигез итеп Гоццидан Кәрим Тинчурин тәрҗемә иткән текст алынган. «Хан кызы Турандык» спектакленең яңача премьерасы 2012 елда Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелды. (Бу әсәрнең һәм, гомумән, сюжетның «Кытай әкияте» дип билгеләнүе ялгыш булуын, кытайлашуының нигезсез икәнлеген дәлилләп язган идек [Кыз хикәте, б. 177–181]).

Уртак сюжет тамырына корылган әсәрләрдән югарыда санап үтелгәннәренең һәрберсе «Дастане җәйә» әсәре белән төрле күләмдә аваздаш булып тора. Төп сюжет сызыгы һәм вакыйгалар үсешенең уртаклыгы, тел-стиль охшашлыклары һәм башка төр үзенчәлекләр бу әсәрләрнең барысының да борынгы дәвер чыганагыннан башлангыч алып, шактый тармакланган булуын дәлилли.

* * *

Сюжетлары ягыннан уртак дип әйтерлек булмасалар да, «Дастане җәйә» текстындагы сорау һәм җавапларның шактый өлеше Ислам дине тарихына, шәригать хөкемнәренә һәм гыйбадәт нигезләренә багышланган күп төрле борынгы китапларда гасырлар дәвамында язылып килгән. Шундыйлардан Рабгузи әсәре турында әйтеп үттек. Гомумән, ул китап күп төрле сорау һәм җавапларның охшашлыгы белән һәм тел җәһәтеннән дә «Дастане җәйә»гә бик якын.

Элекке кайбер китап-әсәрләр сорау-җаваплардан гына торган. Мәсәлән, «Кырык сөаль», «Сиражел-колүб» һәм шуларның берничә төрле вариантлары безнең көннәргәчә (башлыча XVII һәм XVIII гасырда күчерелгән кулъязмаларда) килеп ирешкән.

«Сиражел-колүб» әсәрендә яһүдиләрнең Мөхәммәд пәйгамбәргә 38 сорау белән мөрәҗәгать итүе һәм хәзрәти Галидән дә ике сорауга төпле җаваплар алуы тасвирланган [Татар әдәбияты..., б. 152]. «Сиражел-колүб»нең басма нөсхәләрендә Галигә бирелгән сорауларның саны күбрәк [Сиражел-колүб, б. 79–86]. Андагы 15 сорау һәм җавап «Дастане җәйә»дәгеләргә туры килә. Ягъни, тәмугның исемнәре; күктәге кош; пәйгамбәрләрнең саны (мөрсәл һәм нәбиләр); күктән 104 китап иңүе; дүрт мәшһүр китап кемнәргә иңүе; Коръәннең кайчан иңүе; ата-анасыз туган биш зат; Хаваның исеме; Муса галәйһиссәлам таягы; дөньядагы иң биек бина; күктән тәгам иңүе; тере пәйгамбәрләр; Гозәер

галәйһиссәлам; Бәхтенасыйр; Шәддад «оҗмах»ы [Сиражел-колүб, б. 79–86].

Аднаш хафиз тарафыннан 1554 елда күчерелгән «Сиражел-колүб» кулъязмасының [Россия дәүләт...] теле «Дастане җайә»гә бик якын.

* * *

Бу урында төп мәсьәләдән бераз бүленеп, татар археографиясенең бер табышмагына тукталып китәргә тиешбез. Кызганыч ки, «Сиражел-колүб» әсәренең авторы Аднаш хафиз булган дигән, әдәбиятыбыз тарихында урын алган фикернең дәлилләре җитеп бетми. Гарәп теленнән фарсычага тәрҗемә ителгән бу әсәрнең 1554 елгы татарча вариантын тюрколог галим Әмир Нәҗип Мәскәүдәге дәүләт архивында табып, беренче буларак өйрәнгән [Наджип, с. 323–329]. Ул тасвирланмаган һәм фәнгә билгесез хәлдә табылган кулъязма Аднаш хафиз тарафыннан күчерелгән һәм шул ук зат аңа үзеннән дә өстәп язгандыр, дип билгеләгән.

Башка галимнәр «Сиражел-колүб»не Аднаш хафиз иҗат иткән дип язалар [Гайнетдинов, 1999, с. 141–147; Әхмәтҗанов, Гайнетдинов, 2014, б. 149–157]. (Әлеге әсәр текстының башында беренче зат исеменнән язылган гыйбарәләр шундый карашка нигез булгандыр.) Галимнәр бу әсәрнең кулъязма күчермәләре табылып торуын һәм XIX гасыр уртасыннан алып XX гасыр башына кадәр дистәгә якын басмасы дөнья күргәнлеген әйтеп, «Авторлык фәкать Мәскәүдә саклана торган автографлы кулъязмада гына бар. Казан басмаларында да язучының исеме куелмаган» [Әхмәтҗанов, Гайнетдинов, б. 150] – диләр. «Сиражел-колүб»не Аднаш хафиз 1554 елда иҗат иткән булса, ул татар халкы арасында ничек итеп башка күчермәләрдә таралыш алган икән соң? дигән мантыйкый һәм урынлы сорау туа. Чөнки тасвирланмаган хәлдәге кулъязманы Ә. Нәҗип XX гасыр уртасында гына тапкан бит. Кызганычка каршы, әлеге сорауга мәкаләләрдә җавап юк. Шуңа да карамастан, галимнәр бу әсәр «бик күп тапкырлар күчереп языла һәм басыла... Күп буыннар аны укып тәрбияләнгән. Әднәш Хафиздан соң иҗат иткән язучылар һәм шагыйрьләр дә үз әсәрләрен аныкына охшатып, аның идеяләрен кулланып һәм тулыландырып иҗат иткәннәр» [Әхмәтҗанов, Гайнетдинов, б. 157] – дип язалар. Бу өзектән күренүенчә, китапта Аднаш хафизның исеме үзгәртелгән. 1554 елгы кулъязмада ул үзен «Аднаш хафиз бине Мөхәммәдаднаш хафиз» дип күрсәткән. Монда ике мәртәбә кабатланган «хафиз» дигән сүз «мулла» мәгънәсендә, этисенең исеме ике өлештән: Мөхәммәд һәм Аднаш исемнәреннән торган кушма исем. Тик, ни сәбәптәндер, әйтелгән басмада ул «Әднәш Хафиз» дип басылган. Беренчедән, үз исеме урынына этисенең исеме (ул да йомшартылып) һәм, икенчедән, рухани титул булган «хафиз» сүзе кеше исеме рәвешен алган [Татар әдәбияты..., 2014, б. 9, 25, 149–157, 461].

«Сиражел-колүб»нең башка кульязма күчермәләренә килсәк, хәзерге вакытта Казандагы төрле китапханәләрдә һәм музейларда аның XVII–XIX гасырларга нисбәтле тулы һәм фрагмент хәлендәге уннан артык күчермәсе исәпләнә. Тик тасвирларда һәм каталогларда бөтенесенең дә исемнәре күрсәтелмәгән. Текстларының Аднаш хафиз күчермәсеннән аермалары бик аз. Мәсәлән, XIX гасырда Вятка губернасының төньягында сөргендә вакытта Әхмәди исемле мулла күчереп язган нөсхә шундыйлардан. Ул да, кульязмачылык традициясенә хас булганча, «Ошбу китап язылды 1879 нчы сәнәдә... Яздым бән – Әхмәди Гыйззәтулла мәрхүм угылы» дип исемен теркәгән [ТР ДМ]. Ягъни, бу нөсхәдәге «яздым» дигән сүз һич тә автор булуны белдермәгән кебек үк, Мәскәүдә сакланган кульязмадагы «Аднаш хафиз язды» дигән сүзләрнең дә авторлыкка ишарә итүе табигый шик тудыра. Һәрхәлдә, «Сиражел-колүб»нең авторы кем булганлыгы нигезле тикшерүгә мохтаҗ.

Әйтелгән сәбәпләрне истә тотып, «Сиражел-колүб» кульязмасының фоторәсемен бастырганда без Аднаш хафизны кульязманы күчерүче дип атадык [Татар китабы, б. 94]. (Аңарчы бу кульязма истәлекнең фотосы матбугатта чыкканы юк иде.)

Кызганыч ки, иске язма ядкәрләрнең иҗат ителгән вакытлары, даталары күрсәтелгән кульязма күчермәләренә нигезләнеп, галимнәребез тарафыннан ялгыш билгеләнү очраклары тагын да бар.

* * *

Инде төп мәсьәләгә кайтыйк. Казан шәһәрендә яшәүче Радик Хәкимовтан Татарстан Милли китапханәсенә 2016 елда алынган XVIII гасыр башына нисбәтле кульязманың бер өлеше «Дастане җайә»дәге сорау-җавапларга шактый охшаш. Ул – 10×15 см үлчәмдәге, 14 кәгазьдән торган һәм башы-ахыры булмаган җыентык. Аның баштагы 6 кәгазендә сорау-җаваплы төрле мәсьәләләр теркәлгән. Әлеге текстның башы һәм ахыры булмаганга күрә, аның исемен белү һәм эчтәлеген тулаем күзаллау мөмкин түгел. Һәрхәлдә, сакланган текст фрагментында «кыз сорады» һәм «фәкыйһ әйтте» кебек, әңгәмә үзенчәлегенә ишарәләр бөтенләй юклыгы аның дастан рәвешендә булмаганын белдерә. Бу кульязмадагы сораулар һәм җавапларның күпчелеге «Дастане җайә»некенә охшаш. Сорау-җаваплар, төп тексттан аермалы буларак, кызыл кара белән «мәсьәлә» һәм «җавап» дип язылган. Тексттагы 23 мәсьәлә һәм җавапның 17 се «Дастане җайә»дәгегә охшаш. «Охшаш» дибез, чөнки мәсьәләләр һәм җаваплар дастандагыга тулысынча тәңгәл килми. Куелган сорауның җаваплары башкачарак булуы белән бергә, дастанда аерым сорау итеп язылганнары әлеге кульязмада берләштерелгән очраклар да бар. Мәсәлән, бер үк мәсьәләсорауда: «Гакыл кайда торур, нәфес кайда торур, күңел кайда торур, иман кайда торур, көфер кайда торур», – дип язылып, җавабы да киңрәк аңлатылган. Җавапларның кайберләренә фарсы

телендәге гыйбарә һәм җөмләләр дә өстәлгән. «Дастане җайә»дә «бер – нә торур» рәвешле сораулар барлыгы унике санына хәтле дәвам иткән булса, Хәкимов тапшырган кулъязмада саннарга бәйле ун мәсьәлә язылган.

Сорау-җавап методикасына – мәгълүмат үзләштерүнең чагыштырмача җиңелрәк ысулына нигезләнгән дини дәреслекләр татар мәдрәсәләрендә электән киң кулланылган. XIX гасырда һәм XX гасыр башында бик күп басылган, сорау-җаваплардан торган татар телендәге дәреслекләр, нигездә, «Гыйльме халь» дип аталган. Шундый рухтагы китапларның берсендә (мәсәлән, «Иман рисаләсе»ндә) барлыгы 46 сорау һәм җавап язылган. Шул ук китапның «Имтихан сабыйлар өчен» өлешендә 87 сорау һәм аларның җаваплары бирелгән. Алар арасында: «Дастане җайә»дәге кебек, Аллаһы Тәгаләнең затына хас алты сыйфаты һәм шиксезлеген белдергән сигез сыйфаты; фәрештәләрнең сыйфатлары; Аллаһы Тәгаләдән 104 китап иңүе; дүрт мәшһүр китапның кайсы пәйгамбәрләргә иңгән булуы; Коръәндә бәян кылынган пәйгамбәрләрнең исемнәре; Адәм галәйһиссәламнең һәм Хаваның нәрсәдән яратылган булулары; шайтанның нәрсәдән яратылганлыгы; Мөхәммәд галәйһиссәламгә ничә яшьтә пәйгамбәрлек килүе, ничә ел пәйгамбәр булып торуы һәм ничә яшендә үлүе һ.б. [Иман рисаләсе...].

Күргәнебезчә, «Дастане җайә» әсәре үзеннән элгәреге китаплардагы сорау һәм җавапларга нигезләнгән булса, аңа охшаш китаплар соңгы дәвергәчә дәвам итеп, кулланылып килгән.

## «Дастане җайә»нең бүтән әсәрләр белән уртак һәм аермалы яклары

Әсәрнең сюжет тамырларына багышланган бүлектә «Дастане җайә»гә охшаш кайбер мәсьәләләр, бигрәк тә сорау һәм җаваплар турында әйтеп үттек. Алга таба дастанга аеруча якын берничә әсәргә чагыштырма күзәтү ясалачак.

Дастанның тексты Казанда 1883 елда нәшер ителгән «Мәликә китабы», Ташкентта литография ысулы белән 1904 елда басылган китап, шулай ук Березин 1857 елда бастырган текст өзеге белән җентекләп чагыштырылды. Бу мәсьәләне тәфсилләбрәк күздән кичерик.

«Дастане җайә»дә Мәликәнең «йөз сөалем» дию төп-төгәл 100 сорау дигәнне белдерми. Бу очракта «йөз» сүзе түгәрәк бер сан буларак әйтелгән һәм күп дигән мәгънәгә дә ия булган дип фаразларга кирәк. Дастанда кыз тарафыннан егеткә барлыгы 130 сорау бирелгән. Болардан «дәлил кирәк» дип, өстәмә аңлатмалар таләп итү рәвешендәгеләре – 11, ә «яхшырак тәвәҗҗеһ кыйл» (аңлатып бир) дип, тәфсилләп әйтүне сораганнары – 2. Шулай ук бер сорауга ияреп һәм аның дәвамы буларак бирелгән икешәр-өчәр сорауны төркемләп тә карарга мөмкин. Мәсәлән, кызның беренче соравы «Әүвәл ни яратты?» дигәнгә егет: «Кяф-нун яратты», – дип җавап бирә, икенче сорау исә

шуңа бәйле «Ул ни тигүсе булур?» рәвешендә. Менә шундый, үзара бәйләнешле сорауларны төркемләгәндә, чынлап та, төп сорауларның исәбен төгәл йөзгә калдырырга мөмкиндер. Тик, шулай да, әсәрдә андый катлаулы исәп күздә тотылган дип әйтеп булмый. Кыскасы, бер сорауга – бер җавап рәвешендә исәпләгәндә, барысы 130 сорау язылган.

Басма «Мәликә китабы»нда [Мәликә китабы] кыз барлыгы 106 сорау белән мөрәҗәгать иткән. Шулардан 58 сорау «Дастане җайә»дәгеләргә тулаем туры килә яисә шактый якын. Бу җәһәттән дастан белән басма китап текстларының бер-берсенә бик якын булуы күренә. Басмадагы сорауларның 42 се – дастандагы «тәмуг ничә һәм исемнәре ничек?» дигән (исәбе буенча 61 нче) сорауга хәтле, калган 16 сорау исә ахырга таба төрле урыннардагыларга туры килә. Ягъни, күпчелеге «Дастане җайә» текстының баштагы ярты өлешенә охшаш.

«Мәликә китабы»ның 1904 елгы Ташкент басмасының исемендә сорауларның «һәзар» (мең) дип аталуы һәм мәликәнең «мең мәсьәлә-сөалем бар» дигәне дә төгәл мең дигәнне аңлатмый, ә гипербола-арттыру сүзе буларак кулланылган. Чынлыкта, анда барлыгы 198 сорау һәм аларга җаваплар язылган. Шуларның 47 се «Дастане җайә»дәге сораулар кебек үк яки аларга аваздаш. Ташкент басмасындагылар да Казан басмасындагы кебегрәк, 42 сорау дастандагы 61 нче сорауга кадәр, ә калган бишесе шуннан соңгы төрле урыннарга туры килә.

1883 елгы һәм 1904 елгы басма китаплардагы кыз сорауларының зур күпчелеге «Дастане җайә»дәге тәмуг турында сораган урынга кадәр туры килә. Ә дастандагы «Бер – нә торур?» дигән сораудан алып, текстның ахырына кадәрге сорауларның санаулылары гына басма китаплардагыга тәңгәл килә.

Березин бастырган текст кызыклы, әмма ул тулы түгел, өзек кенә. Шулай да «Дастане җайә» белән икесендә генә булган уртаклыклар аны да тасвирларга җирлек бирә. Березин басмасында барлыгы 42 сорау һәм аларның җаваплары урын алган. Шулардан 41 сорау дастандагыларга, күпчелеге Казан (1883 ел) һәм Ташкент (1904 ел) басмаларына да туры килә. Ләкин басма китапларда булмаган кайбер сорау-җаваплар бары тик «Дастане җайә» белән Березин басмасында гына бар. Шунысын ачыклап китү зарур, Березин текстында кайбер сораулар һәм җаваплар берләштерелгән хәлдә. Мәсәлән, «Дастане җайә»дә аерым-аерым сораулар буларак язылган габидлык, шакирлык, галимлек, разыйлык, сабырлык Березин басмасында бер сорау итеп һәм, табигый, җавабы да уртак язылган [Турецкая хрестоматия..., с. 122].

«Дастане җайә»дә вакыйганың урыны итеп Рум шәһәре күрсәтелгән. Дәвере турында бер сүз дә юк. Рум шәһәренең патшасы (мәлиге) Гасаран исемле, аның кызы Мәликә, Төркестан егете Габдулла галим дип исемләнгән. Патшаның, кызының һәм егетнең исемнәре хикәят

башында гына әйтелгәннәр дә, аннан соң бөтен текстта «атасы», «кыз», «фәкыйһ» яки «егет» дип кенә аталганнар. Дөрес, кыз текст ахырында «хан кызы», «шаһ кызы» дип тә исемләнгән.

Болардан тыш, дастанда галимнәр (данишмәндләр), егетнең әтисе – бай (хуҗа) һәм анасы, аларны сатып алган падишаһ (әсәр ахырында ул «солтан» дип аталган), егет кунарга кергән карчык, Мәликәнең хезмәтче кызы (каравышы), алтын-көмеш остасы, бикләр һәм вәзирләр дә телгә алынган.

Дастанның университет китапханәсендә саклана торган күчермәсендә Рум патшасының исеме Гасайан (Гасабан) дип теркәлгән, ә Мәликә – хаталы рәвештә Дәляк дип язылган. Текст эчендә ул мәлик кызы дип кенә дә аталган. Фәкыйһ егет Габдулла әл-галим дип исемләнгән.

«Дастане җайә»дәге һәм аның кыскартылган басма вариантындагы Мәликә дигән исем – кыз исеме буларак язылса да, аның башлангычы Коръәндәге «Ән-Нәмел» сүрәсендә Сәба мәликәсе (патшабикәсе) дип аталуына һәм Рабгузи кыйссасында Бәлкыйснең «мәликә» дип язылуына турыдан-туры бәйле булса кирәк.

Әсәрдәге Төркестанлы фәкыйһнең исеме асылда Габдулла булып, «галим» дигәне аның эпитеты булып аңлашыла. «Мәликә китабы»ның басма вариантларында егетнең исеме Габделхәлим һәм Габделгалим дип аталган. Дастанның тексты борынгырак булганга, егетнең исеме башлангычта нәкъ шулай – Габдулла галим буларак кулланылгандыр, ә шул исем төрле күчермә нөсхәләрендә үзгәреп, Габделгалим һәм Габделхәлим рәвешләрен алгандыр дип фаразларга мөмкин. Шул ук сюжетка нигезләнгән башка әсәрләрдә (мәсәлән, шагыйрь Ибраһим иҗат иткән кыйссада һәм «Кыз хикәяте»ндә) егетнең исеме күрсәтелмәгән. Бүтән хикәятләрдә һәм китапларда ул Хәләф, Каләф, Кулаф исемнәре белән аталган.

Дастанда Гасаранның Кәгъбәгә барып кырык корбан чалуы әйтелсә дә, корбанлыкның нәрсә булганы билгеләнмәгән. Ә университет китапханәсе күчермәсендә, шулай ук Березин җыентыгында да, басма «Мәликә китабы»нда (Казан, 1883) кырык дөя корбан ителгәнлеге язылган.

Татарстан Милли китапханәсе кульязмасында кызны атасы җир астында тотып, гыйлем өйрәтте диелгән. Ә басма китапларда аның җир астында тотылуы турында әйтелмәгән. Бу бары тик Березин вариантында (1857) гына бар.

Шагыйрь Ибраһим әсәрендә һәм «Кыз хикәяте»ндә вакыйганың урыны аталмаган, кызның һәм аның әтисенең, галим егетнең исемнәре дә күрсәтелмәгән. Ә патша, солтан, шаһ, карчык, кызның каравышы, куйумчы (алтын-көмеш остасы), вәзирләр һәм бәкләр ул текстларда да бар.

Басма «Мәликә китабы»нда (Казан, 1883) «Рум шәһәрендә Мәлик дигән бер падишаһ», аның кызы Мәликә, Төркестан егете Габделхәлим исемнәре бар. Вакыйга Мөхәммәд (с.г.в.)

пәйгамбәр заманында барган дип язылган. Китапның сорау-җавап өлешендә Мәликә «кыз» дип кенә, ә егет «фәкыйһ» дип аталган.

Басма «Мәликә китабы»нда егетнең кызга шигырьләп җавап биргән:

Шөгъләи шәмгъ җәмалең бәхрене
күргәч рәван,
Җандин пәрванә йаңлыйг кем
кичдем һәман, –

дигән юллар «Дастане җайә» текстында да бар. Дөрес, кайбер сүзләре генә башкача. Ягъни, «шәм утыдай гүзәллегеңне күргәч тә, җанымнан күбәләк кебек тиз генә ваз кичтем» дип, Габделхәлим үзенең мондый гүзәл хакына һәлак булудан да курыкмавын белдергән. Борынгы Шәрык әдәбиятында, бигрәк тә суфичылык шигъриятендә шәм белән күбәләк символик образлары киң кулланылган. Яктылыкның гашыйгы утны яратуыннан үз-үзен корбан иткән. Сәгъди, Сәйф Сараилардан килгән бу шигъри символлар Габдулла Тукай һәм Дәрдемәнд иҗатларында да дәвам иткән [Сибгатуллина, б. 245–246].

Сорау-җавапларның охшашлары күп булса да, фәкыйһ егетнең «Дастане җайә» һәм Ибраһим әсәре белән «Кыз хикәяте»ндәгечә, бай сәүдәгәр улы булып, мохтаҗлыкта җәфа чигүләре һәм, әти-әнисен сатып, Румга килгәч, бер карчыкта төн кунарга тукталып, дарга асылганнар турында сорашкан вакыйгалары басма «Мәликә китабы»нда юк.

Басма китапның (Казан, 1883) ахырында кыз «Мин синең никахыңда булдым тиде. Габделхәлим Төркестани кабул кыйлды» рәвешендә төгәлләнә. Ә «Дастане җайә», шагыйрь Ибраһим һәм «Кыз хикәяте»ндәге кебек, егетнең кызга бер сорау бирүе, төнлә кызның егет янына килеп, хәйлә белән җавапны белүе һәм алтын йөзек вакыйгалары да басма «Мәликә китабы» текстында юк.

Ташкентта басылган китапта вакыйганың заманы һәм урыны «...Солтанел-гарифин Рум шәһәренең падишаһы ирде» [Китабе мәликәи..., б. 2–3] дип күрсәтелгән. Патша вафат булганда аның угылы юк, әмма бер кызы бар иде, ул атасы урынына тәхеткә утырды дип тасвирланган. Әлеге кыз «мең мәсьәләсөалем бар» дип, шуларга җавап бирүчегә никахланып, патшалыкны тапшырачагын белдергән. Бу патшабикә әсәрдә «Мәликә» дип исемләнгән. Ул Рум шәһәрендә 40 ел патшалык итсә дә, сорауларына җавап бирә алучы табылмый. Төркестаннан Имам Әгъзамның шәкертләреннән мулла Габделгалим исемле хәзрәт килеп, сорауларга җавапка керешә. Әсәрнең төп каһарманнары текстның башыннан ахырынача «мәликә» һәм «данишмәнд» дип язылганнар. Бу китапның ахырында мәликә галимнең кем нәселеннән булуын сорый. Данишмәнд үзен хәзрәти Гомәр разый Аллаһының унберенче оныгы дип атый һәм үзе дә мәликәнең кем нәселеннән булуын сорый. Мәликә Искәндәр Зөлкарнәйн токымыннан булуын әйтә. Шуннан соң мәликә «мин сиңа үземне багышладым» дип,

тәхеттән төшеп, данишмәнднең башына патшалык таҗын кигерә һәм тәхеткә утырта. Ташкент басмасы Рум патшалары шушылар нәселеннән, чын дөресен Аллаһ үзе белер, дигән сүзләр белән тәмамлана [Китабе мәликәи..., б. 120].

Укымышлы егетнең бай улы булып, мохтаҗлык нәтиҗәсендә эти-әнисен сатуы һәм Румда бер карчыкта кунуы, әсәр ахырында егетнең бер сорау биреп, кыз җавабын тапмыйча, төнлә килүе һәм хәйләле маҗаралары турындагы тасвирлар Ташкент басмасында да юк. Әйтелгән маҗаралы хәлләрнең басма «Мәликә» китапларында булмавы, аларның (ягъни, ата-ананы сату һәм кызның төнлә, шәраб белән килеп, гыйш-гошрәт кылуы) шәригатькә ярашмавы сәбәпле, төшереп калдырылган дип уйларга кирәк. Иң әүвәлге текстларда: «Дастане җайә», Ибраһим әсәрендә һәм «Кыз хикәяте»ндә аларның булуы, ә XIX гасыр һәм XX гасыр башы басмаларында булмавы шундый фикергә этәрә.

Бу сюжетка язылган башка әсәрләрдә сорау-җавап бәйгесендә кызның йөзе капланган, ә төнлә егет янына килгәндә ачык булуы әйтелгән. Ә «Дастане җайә»дә йөзе ачык яки каплаулы булуы турында бернәрсә дә язылмаган. Ихтимал, ул хактагы җөмлә яки сүзләр кулъязманы күчергәндә төшеп калгандыр.

Березин җыентыгында дөнья күргән «Мәликә китабы» тексты тулы булмаганлыктан, аны өлешчә генә күзаллый алсак та, дастан белән кызыклы уртаклыклары аз түгел. Әлеге өзектә Рум патшасының исеме Асара (Әсәрә), аның кызы Хәлилә исемле дип бирелгән. Мәликә дигән исеме болай аңлатылган: «атасы үлде, кыз атасының тәхетегә ултурды, мәликә булды, ягъни падишаһ булды». Текстта Төркестанлы галим егет Габделгалим дип аталган. Егетнең исеме, башка текстлардагы кебек үк, бер мәртәбә әйтелгәннән соң, «данишмәнд» дип кенә бирелгән. Бүтән текстлардан аермалы буларак, «шәм-чыраг» турында монда мәликә исеменнән әйтелгән. Ул: «Әй, данишмәнд! Сән – чыраг-сын, мән – пәрванәмен, әгәр көйсәм һич булмагай» дип эндәшкән. Алар арасындагы сорау-җавап бәйгесе дастанга һәм басма китапларга охшаш рәвештә дәвам иткән. Ләкин аның ахыры юк.

Данишмәнд егетнең бай улы булып, эти-әнисен сатуы турында Березин вариантында да язылмаган. Бу текстның ахыргы өлеше булмаганлыктан, аның бетемендә дә «Дастане җайә»дәге кебек, кызның төнлә егет янына килүе һәм йөзеккә бәйле вакыйгалар тасвирланганмы-юкмы – мәгълүм түгел. Тик, шулай да, башлангычы кыскача вариациядә тасвирлангач, ахыры да башка басма китаплардагыча булгандыр дип уйларга нигез бар.

«Дастане җайә» белән басма «Мәликә» китапларындагы охшаш сорау-җаваплар, өлешчә, тәңгәл киләләр, тик аермалыклары да шактый. Мәсәлән, дастанда «Әсмандан ничә китаб инде» (күктән ничә китап иңде) дигән сорауга фәкыйһ «йөз китаб» дип җавап биргән. Ә «2220 т» шифрлы кулъязмада

һәм Березин басмасында 114 дип, 1883 елгы «Мәликә китабы»нда бу сан 404 дип, Ташкент басмасында 104 дип бирелгән [ТР МК; Турецкая хрестоматия..., с. 120; Китабе мәликәи..., б. 22]. Дастанда 124 мең пәйгамбәр диелгән, Березин җыентыгында һәм 1883 елгы китапта да шулай ук, ә Ташкент басмасында 124 кенә. Аларның «мөрсәл» булганнары дастанда һәм Ташкент басмасында 313 дип, ә Березин басмасында 3100, 1883 елда басылган «Мәликә китабы»нда исә 3313 дип күрсәтелгән. Дастан текстында әйтелгән егерме пәйгамбәр арасында Гайса галәйһиссәлам дә булырга тиеш иде, ләкин ул юк. Шулай ук Ягъкуб пәйгамбәр исеме дә язылмаган. Басма «Мәликә китабы»нда егерме пәйгамбәр эчендә Ягъкуб бар, ә дастан текстында язылган Җирҗис галәйһиссәлам юк [Китабе мәликәи..., б. 5]. Гомумән, пәйгамбәрләр санын егерме дип кенә әйтү дөрес түгел. Күрәсең, кульязма күчергән кешеләрнең берәрсе тарафыннан егермедән соң тагын бер сан ялгышлык белән төшереп калдырылган булгандыр. Һәрхәлдә, сораулар белән тулы дастанның тексты үзе дә өстәмә табышмаклар тудыра.

Пәйгамбәрләрнең иң өстен дәрәҗәлеләре дип «Дастане җәйә»дә һәм Березин басмасында Ибраһим, Муса, Идрис, Гайса һәм Мөхәммәд галәйһиссәламнәр күрсәтелгән булса, 1883 елгы басмада дүрт исем аталган: Ибраһим, Муса, Гайса һәм Мөхәммәд (с.г.в.). «Дастане җәйә»дәге «Заһидлык кемдин калды?» соравының «Гайса галәйһиссәламдән» дигән җавабы Березин текстында һәм 1883 елгы басма китапта да шулай ук, ләкин Ташкент басмасында «Хәзрәти Идрис пәйгамбәрдән» диелгән. Җир йөзенең мәшрикътан мәгърибкә хәтле өлешендә патшалык кылган кешеләрнең исемнәре саналганнан соңгы – Бәхтенасыйр турындагы ахыргы җөмлә басма китапларда юк.

«Дастане җәйә» текстындагы Йосыф пәйгамбәрнең гәүдәсе җирдә черүе турындагы сорау һәм аның атасы белән ат өстеннән төшмичә күрешүе турындагы җавабы басма «Мәликә китабы»нда (1883) да бар. Ләкин дастандагы Йосыф-Зөләйха әңгәмәсен мисал итеп китергән тәфсилле аңлатма басма китапта юк. Ташкент басмасында исә бу мәсьәлә бөтенләй телгә алынмаган. Текстларда мондый аермалар тагын да бар.

Парлы нәрсәләр ничә булуы турындагы сорауга «Дастане җәйә»дә ун исем язылган, ә «2220т» шифрлы кульязма, Березин бастырган текст һәм Ташкент басмасындагы җавапларда андыйлар унике дип әйтелгән.

Дастанда тасвирланган күктәге кош турында дини эчтәлекле кайбер китапларда язылган булса да, аның бу текстагыча «канкус» дигән исем белән аталганын очратмадык. Бу хикмәтле кош образына, күрәсең, суфичылыкка хас символик һәм аллегорик мәгънә салынгандыр.

Төрле гөнаһлары өчен Аллаһы Тәгаләнең хөкеме белән кеше кыяфәтеннән бүтән төр җан ияләренә әверелдерелгән затлар турында «Дастане җәйә»дәге со-

рау һәм җаваплар, өлешчә, дини китапларга[1], калганнары халык риваятьләренә һәм ырымнарга нигезләнгән. Дастанда андыйлар сигезәү: җарийә (кирәф), бичин, сусмар, ташбака, кәлтә-кәляс, айыг (аю), төлке, мәймүн. Бу атамаларның нәрсәне белдергәнлекләрен төгәл генә аңлап булмый. Чөнки, бичин белән мәймүн – икесе дә маймыл, шулай ук сусмар һәм кәлтә-кәляс – икесе дә кәлтә мәгънәсендә. Дөрес, сусмар дигәне варан һәм крокодилны да белдергән. Ә кульязмадагы җарийә (кирәф) дигән атаманы ачыклап булмады. Мәгълүм булганча, җарийә – кол яки хезмәтче кыз дигәнне белдерә, әмма текстта ул мәгънә күздә тотылмаган.

Басма «Мәликә китабы»нда андыйлар 23 диелсә дә, дөреслектә унбишенең генә исемнәре язылган [Мәликә китабы, б. 11–12]. Шулардан «Дастане җайә»дәгеләргә туры килә торганнары: аю, мәймүн, төлке, ташбака. Ташкент басмасында (1904) сурәтләре үзгәртелгән «ун җан» турында язылган [Китабе мәликәи..., б. 118–119]. «Дастане җайә»дәгегә аваздашлары: «төлке, мәймүн, айык (аю)».

Ибраһим әсәрендә кыяфәтләре үзгәртелгән дип барлыгы 24 зат күрсәтелгән һәм шулардан «мәймүн» белән «аю» гына дастандагы кебек. «Кыз хикәяте»ндә андыйларның (мәнсухларның) саны 22 булып, дүртесе дастандагыча: «дуңуз, мәймүн, аю, яшел кәлтә».

Шуны искәртергә кирәк, төрле текстларда тасвирланган бер үк җан ияләренең гөнаһсәбәпләре тәңгәл килеп бетми.

Кыяфәтләре үзгәртелгән нәрсәләрнең «Мәликә китабы»нда телгә алынганнары мәсьәләсенә тукталып, Г. Рәхим һәм Г. Газиз болай дип язганнар: «Андагы бәгъзе хорафат халык гаммәсенең аңына да кереп өлгергән. Мәсәлән, төрле хайваннарның төрле гөнаһлы кешеләрдән азган булулары хакындагы, халык арасында бик таралган игътикад шушы китап тәэсирендә мәйданга килгән» [Рәхим, Газиз, б. 258]. Әмма монда күздә тотылган хорафатларның халык аңына сеңүенә бер «Мәликә китабы» гына сәбәпче булмыйча, Рабгузи кыйссасы, «Кыз хикәяте» һәм башка әсәрләр дә тәэсир иткән.

Нәтиҗә ясап әйтсәк, эчтәлекләре белән «Дастане җайә»гә иң якын булган текстлар арасында, уртаклыклар күп булуы белән бергә, аермалар да шактый. Мондый төрлелек, үз нәүбәтендә, бу әсәрләрнең борынгы чор ядкәрләре икәненә тагын бер дәлил булып тора.

* * *

Әсәрнең теле һәм кульязманың палеографик үзенчәлекләренә килсәк, «Дастане җайә» Урта гасырлардагы Идел буе төрки-татар язма теленнән аермалы түгел. Ул Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасына

[1] Мәсәлән, Коръәннең «Әл-Бәкарә» һәм «Әл-Маидә» сүрәләрендә, Коръән тәфсирләрендә [Тәсһилел-бәйан..., б. 22, 256, 431], Рабгузи әсәрендә [Кыйсасел-әнбийаи..., б. 405, 421, 494] маймыл һәм дуңгызга әверелдерелгәннәр генә телгә алынган.

(1233), Мәхмүд Болгарыйның «Нәһҗел-фәрадис»енә (1358), «Кисекбаш» дастанына (XIV гасыр), XVI гасырның беренче яртысында иҗат ителгән әсәрләрдән Мөхәммәтәминнең «Могҗизнамә» (1515 ел) һәм «Кыйссаи Мансур», Мөхәммәдъярның «Төхфәи мәрдан» (1540) һәм «Нуры содур» (1541) поэмаларына, шулай ук «Кәлилә вә Димнә» әсәренең татарчага тәрҗемәсенә, «Сиражел-колүб»нең 1554 елгы күчермәсенә һәм башка язма ядкәрләрнең теленә якын.

Борынгы чорда кулланылган «Дастане җайә» атамасы, әсәрнең эчтәлеге кыскаруга һәм мәгънәсе үзгәрүгә бәйле рәвештә булса кирәк, тора-бара онытылган. Аның кыскарган варианты XIX–XX гасырларда «Мәликә китабы» буларак танылган.

Мәкаләдә сүз барган «Дастане җайә»нең тексты һәм аның хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе, шулай ук кульязманың факсимилесы күптән түгел аерым китап рәвешендә басылып чыкты [Дастане җайә].

**Әдәбият**

*Әхмәтҗанов М., Гайнетдинов А.* Әднәш хафиз. «Сиражел-колүб» // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 2 т.: XV–XVIII гасырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. Б. 149–157.

*Гайнетдинов М.* «Сирадж ал-кулюб» (Светоч сердец) // Средневековая татарская литература: VIII–XVIII вв. Казань: Фэн, 1999. С. 141–147.

*Гайнуллин М.* Татар әдәбияты. XIX йөз: югары уку йортлары өчен. Казан: Таткнигоиздат, 1957.

*Гоцци К.* Сказки для театра: пер. с ит. / вступ. ст. Н. Томашевского; коммент. С. Мокульского; ил. Е. Катышева. М.: Правда, 1989.

Дастане җайә (Мәликә китабы) / төз. Р.Мәрданов. Казан: Милли китап, 2017. 148 б. («Татар археографиясе» сериясе; 19 нчы китап).

*Дмитриева Л.В.* Каталог тюркских рукописей Института востоковедения Российской академии наук. М: Вост. лит., 2002.

Иман рисаләсе: Аллаһы Тәгаләнең берлегенә иман килтермәк рәвеше вә һәм игътикад вә гыйбадәт кылуның рәвешләре. Казан: ун-т табыгханәсе, 1893. 60 б.

*Исмәгыйлев Н.* Гасырларны кичкән сюжет // Казан утлары. 1985. № 9. Б. 182.

Китабе мәликәи данишмәнд һәзар сөали мәшһүр мәга сөали мөтәфәррика. Ташкент: В.М. Ильин типо-лит-се, 1904.

Книга тысячи и одной ночи: в 8-ми томах / пер. с араб. М.А. Салье. Т. 5. М., 1959.

Кыз хикәяте / төз.-авт. Р.Мәрданов. Казан: Милли китап, 2012. 184 б.

Кыйсасел-әнбийаи Рабгузи. Казан: ун-т табыгханәсе, 1881.

Мәликә китабы. Казан: ун-т табыгханәсе, 1883. 16 б.

*Наджип Э.* Датированная тюркоязычная рукопись XVI в. «Сиражел-колүб» // Труды Двадцать пятого Международного конгресса востоковедов (Москва, 9–16 августа 1960). Т. III: заседания секций X, XI, XIII. М.: Изд-во Вост. лит., 1963. С. 323–329.

*Рәхим Г., Газиз Г.* Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере. Икенче басма. Казан: Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты, 1925.

Россия дәүләт борынгы актлар архивы (Мәскәү). 181 фонд, 16 тасв., 1468 сак. бер.

*Сибгатуллина Ә.* Суфичылык серләре (төрки-татар шигъриятендә динисуфичыл символлар, образлар, атамалар). Казан: Матбугат йорты, 1998.

Сиражел-колүб: һәркем дә, ягъни укучы да, тыңлап торучы да аңласын өчен ачык Казан теленә тәрҗемә итеп, бер сүзен арттырмый һәм киметми бастырылды. Әүвәлдә хаталык илә төшеп калган бәгъзе сүзләр дә куелды. Казан: Кәримевләр матбагасы, 1909.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 2 т.: XV–XVIII гасырлар / төз. Р. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014.

Татар китабы = Татарская книга: альбом / төз.-авт. Р. Мәрданов, И. Һадиев. – Казан: Татар. китап нәшр., 2013.

Тәсһилел-бәйан фи тәфсирел-Коръән: Казан мөселманнары телендә / тәрҗ. Мөхәммәдсадыйк әл-Иманколый. Әл-җөзъэ әүвәл. Казан: Үрнәк, 1911.

ТР ДМ – Татарстан Республикасының дәүләт музее. «ГОМРТ. 19011-2» шифрлы кулъязма, 137б кәгазь.

ТР МК – Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. «2220т» шифрлы кулъязма, 1а кәгазь.

Турецкая хрестоматия, составленная И. Березиным, профессором турецкого языка в Императорском Санктпетербургском университете. Т. I. Казань: Тип. ун-та, 1857.

*Хафизов С.* XIX йөз татар прозасы. Уфа, 1979.

*Шиһабеддин бине Габделгазиз бине Рәхмәтулла.* Каләф берлә Турандук хикайәте: «Әлфе нәһар»дан алынып тәртип ителде. Казан: Кәримевләр матб., 1903. 120 б.

***Мәрданов Раиф Фәтхелбәян улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең*
*редакция-нәшрият бүлеге хезмәткәре, археограф*

УДК 821.512.145

***Л.Р. Мортазина***

# ЮГАЛМАС МИРАС
## (танылган драматург Хәй Вахитның туауына 100 тулу уңаеннан)

В данной статье представлены некоторые материалы из фонда известного татарского драматурга Хай Вахита, хранящегося в Центре письменного и музыкального наследия Института языка, литературы и искусства имени Галимджана Ибрагимова АН РТ.

**Ключевые слова:** Центр письменного и музыкального наследия, Хай Вахит, татарская драматургия, спектакль, наследие, фотодокументы, письменные материалы.

Татар театр сәнгате үсешендә якты, сизелерлек эз калдырган шәхесләрнең берсе – драматург Хәй Вахит. Ул – җиңелчә лирик комедияләре, мәхәббәт, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтләүгә багышланган сентименталь характердагы драмалары белән татар театрына яңалык алып килгән, дистә еллар дәвамында тамашачы күңелен яулап торган авторларның берсе. Ул чорда Хәй Вахит исемен белмәгән, «Беренче мәхәббәт» спектаклен карамаган, яисә бу әсәрен укымаган, ишетмәгән татар кешесе, мөгаен, булмагандыр.

Театр дигән серле дөнья 1918 елның 2 декабрендә Казан губернасы Казан өязенең (хәзерге Биектау районы) Мәмдәл авылында дөньяга килгән Габделхәй Каюм улы Вахитовны кечкенәдән үк үзенә тарта, сихерли. Бик иртә ятим калган, туганнары тәрбиясендә үскән егет, авыл мәктәбен тәмамлагач, Казан театр техникумына юл ала. Театр ул, билгеле булганча, сүз сәнгатенә, хәрәкәтләргә генә корылмаган, музыка белән дә юлдаш. Бала чактан җыр, музыка белән кызыксынган Габделхәйнең Казан музыка училищесына, консерваториягә барып керүе дә, беренче чиратта, театр, музыкаль спектакльләр, опералар иҗат итү, аларның серенә төшенергә теләү максатыннан булса кирәк. Гомумән, музыкага, җыр сәнгатенә мәхәббәт, төрле уен коралларында уйнау Вахитовлар гаиләсенә хас сыйфатлар. Хәй Вахитның якын туганы, гомере буе Мәмдәл авылында яшәгән авылдашым һәм күршем Габдрахман абый Вахитов та соңгы көннәренә кадәр кулыннан скрипкасын төшермәде, татар халык көйләрен бик яратып, моңланып, эчке белән тәэсирләнү белән уйный иде. Хәй Вахитның иҗат юлын сайлауда аны үстергән гаиләнең роле, һичшиксез, зур булгандыр.

Бөек Ватан сугышында катнашкан Х. Вахит 1956–1958 елларда Мәскәүдә М. Горький исемендәге әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларда белемен арттыра. Инде



Хөснул Вәлиуллин һәм Хәй Вахит.
1941 елның 26 сентябре

сугышка кадәр үк (1937 елда) беренче пьесаларын – «Канлы куллар», «Сорыкортлар» әсәрләрен язган, моннан тыш «Дулкыннар» исемендәге шигырьләр җыентыгын бастырган автор, курслар тәмамлап кайтканнан соң, бөтен гомерен әдәби иҗатка багышлый. Тик музыкага булган олы мәхәббәте беркайчан да кимеми, ул аның иҗат җимешләрендә – җырларында, пьесаларында, либреттоларында чагылыш таба. Татар музыкасын, аның тарихын, үзенчәлекләрен бик яхшы белгәнгәдер, Х. Вахитның драма әсәрләре үзләренең аһәңлелеге, музыкальлеге белән башка авторлардан шактый аерылып тора.

Заманында Х. Вахитның иҗатына зур бәя бирелә – ул әдәби тәнкыйтьтә дә, шулай ук хөкүмәт тарафыннан бүләкләүләрдә дә чагылыш таба. «Беренче мәхәббәт» драмасы өчен, мәсәлән, ул республикабызның иң зур, иң мәртәбәле бүләгенә – Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Соңрак, 1968 һәм 1978 елларда Татарстан һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе дигән дәрәҗәле исемнәр яулый. Хезмәтләренә танылган тәнкыйтьчеләр Азат Әхмәдуллин, Баян Гыйззәт тарафыннан бәя бирелә, исеме «Татар энциклопедиясе»нә, татар театрына багышланган альбом, китапларга кертелә. Шулай да, фаразлавыбызча, Хәй Вахитның тормышы һәм иҗаты әлегәчә тикшеренүчеләр тарафыннан тулаем өйрәнелеп бетмәгән. Бу фикер Х. Вахитның ТР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты каршындагы Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә (ЯһММҮ) саклануче шактый зур архивы белән танышканнан соң туды. Чыганаклар арасында бик күп санда фотоматериаллар (күбесе киң җәмәгатьчелеккә таныш түгел), язма мәгълүматлар, автор һәм аның әсәрләре турында үзе исән вакытта матбугатта басылып чыккан газета һәм журнал мәкаләләре, бәяләмәләр, Х. Вахитның куен дәфтәрләре, хатлары, язылачак әсәрләренең план-конспектлары, каралamalары, башка төр документлар бар. Фотосурәтләрдә – аның иҗатташ дуслары (инде күбесе, кызганычка каршы, вафатлар), спектакльләрдән күренешләр, авторның халык, җәмәгатьчелек, укучылар белән очрашу мизгелләре... Шул заманның

сулышын, Хәй Вахит турында хатирәләр саклаган әлеге документлар татар театры, татар сәнгате сәхифәләрен һәм, гомумән, шул чорны өйрәнү өчен бай һәм мәгълүматлы чыганаклар була алалар.

Х. Вахит фонды 1991 елда И. Еникеев тарафыннан тасвирланган. Анда барлыгы 354 эш исәпкә алынган. Бу материаллар арасында әлегәчә укучыга таныш булмаганнары, драматургның тормыш юлы һәм иҗади эшчәнлегенә яңалыклар өстәрдәйләре дә бар. Архивтагы материаллардан аңлашылганча, Хәй Вахит әсәрләре татар сәхнәсендә генә түгел, илебезнең башка театрларында да куелган һәм зур уңыш белән барган. Әйтик, 1976 елда Дагстанда Авар музыка-драма театрында Х. Вахитның «Туй алдыннан» әсәре буенча спектакль куела, зур уңыш белән бара. Бу турыда шул елның 13 маенда «Советская Татария» газетасында мәкалә дә басылып чыга [ЯһММҮ, 103 ф., 2 тасв., 57 эш]. Мирасханәдә, шулай ук, авторның әсәрләренә, дөнья күргән спектакльләренә карата «Правда», «Социалистик Татарстан» газеталарында, «Азат хатын» журналында басылып чыккан күпсанлы бәяләмәләр белән дә танышырга мөмкин.

Фотолар арасында [ЯһММҮ, 103 ф., 2 тасв., 41 эш], әйтеп узылганча, авторның иҗат мизгелләре чагылыш тапкан сурәтләр күп. Аларның һәрберсе үзенчәлекле тарихка ия, драматург иҗатындагы теге яки бу сәхифәне яктырта. Фотоларда сурәтләнгән затлар арасында татар сәнгатендә зур урын тоткан шәхесләр – язучылар, композиторлар, режиссерлар, артистлар бар. Фотоларның барлыкка килү сәбәпләренә килгәндә, аларның күпчелеге әсәр яки аңа багышланган конкрет чара – спектакль, премьера, шулай ук язучылар җыелышлары, съездлар белән



«Самат» операсы авторлары:
М. Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театрының баш режиссеры Нияз Даутов, композитор Хөснул Вәлиуллин, либретто авторы Хәй Вахит



«Самат» операсының премьерасыннан соң. Нияз Даутов белән. 1977 ел, 6 ноябрь



Драматург Хәй Вахит һәм режиссер Марсель Сәлимҗанов: «Беренче уртак эшебез»

бәйле. Мисал өчен, бик кызыклы фотоларның берничәсе «Самат» операсы белән бәйле. Фотоларның берсендә әлеге операның авторлары – М. Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театрының баш режиссеры Нияз Даутов, танылган татар композиторы Хөснул Вәлиуллин, либретто авторы Хәй Вахит сурәтләнгән. Билгеле булганча, беренче тапкыр 1957 елда сәхнәләштерелгән әлеге әсәр татар опера сәнгате үсешендә шактый зур казаныш буларак кабул ителә, тәнкыйтьчеләр һәм музыка сөючеләр тарафыннан уңай бәяләнә. Драматургның Хөснул Вәлиуллин белән яшьлектә башланган иҗади дуслыгы озак еллар дәвам итә. Бу дуслык башка фотосурәтләрдә дә чагылыш таба.

Икенче бер уникаль сурәт, шулай ук, театраль премьера белән бәйле. Анда Г. Камал театрында куелган спектакль – «Соңгы хат»ның премьерасыннан соң төшкән авторлар – драматург Хәй Вахит һәм режиссер Марсель Сәлимҗанов сурәтләнгән. Фотоның арткы ягына «Беренче уртак эшебез» дип язылган. Бу әсәр 1966 елның 21 мартында беренче тапкыр Г. Камал театры сәхнәсендә уйнала [Галиәсгар Камал исемендәге..., б. 196]. «Соңгы хат» драмасы буенча куелган спектакльгә музыканы шулай ук композитор Хөснул Вәлиуллин яза. Бу эш әлеге иҗат төркеменең беренче, әмма бердәнбер уртак эше булып калмый. 1968 елның 23 мартында шул ук авторлар тарафыннан эшләнгән «Илһамия» комедиясенең премьерасы була [Галиәсгар Камал исемендәге, б. 197]. Моннан тыш, Х. Вахит Р. Гобәйдуллин, Ш. Шәрифуллин, С. Садыйкова, Ф. Әбүбәкеров кебек композиторлар белән дә иҗат иткән. Г. Камал театрында исә режиссерлардан П. Исәнбәт белән Р. Бикчәнтәев Х. Вахит әсәрләрен сәхнәләштергәннәр.

Мирасханәдә тупланган материаллар арасында аеруча кызыклыларын, мөгаен, Х. Вахитның шәхси кәгазьләре, язмалары, караламалары, куен дәфтәрләре тәшкил итәдер. Алар арасында язылачак әсәрләрнең планы, кыскача эчтәлеге, драматургның уй-фикерләрен чагылдырган сүзләре, афоризмнары бар. Аларга нигезләнеп, авторның уй-кызыксынуларын, нинди хыяллар белән янганын ачыкларга мөмкин. Араларында заманы өчен шактый кыю әйтелгәннәре дә бар. Алар, әлбәттә, бүгенге заман укучысы өчен дә гаять кызыклы.

Гомумән алганда, бүгенге көндә ТР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә сакланган Хәй Вахит фонды һәм андагы документлар

үзләренең шактый бай һәм үзенчәлекле булуы белән аерылып торалар, алар драматургның иҗади эшчәнлеген һәм тормышын өйрәнүчеләрдә зур кызыксыну уятыр дип уйларга тулы җирлек бар.

**_Хәй Вахитның куен дәфтәреннән:_**

*Җүнле атадан җүнсез бала туа. Мин үземнең җүнсез булганыма сөенеп тә куям. Балаларым җүнле булыр.*

* * *

*Дуңгызларга бүреләр һөҗүм итсә, дуңгызлар бер-берсенә артлары белән (берләшеп), бүреләргә каршы һәрберсе аллары белән каршы баралар.*

* * *

*Көнең өчен яшәмә, денең (иманың) өчен яшә.*

* * *

*Тәнкыйтчеләргә:*
*Берсе күреп өрә, калган биш-алтысы аңа ияреп өрә.*

* * *

*Алга бару өчен артка барып карау да кирәк.*

* * *

*Элек киленне алганда ашатып карап алганнар. Яхшы ашаса, алганнар. Яхшы эшли, дип. Хәзер, киресенчә, аз ашаса, алалар [ЯһММҮ, 103 фонд, 1 тасв, 295 сакл. бер.].*

**Әдәбият**

Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләр театрына йөз ел. Ике томда. Т. 2. Казан: Заман – Татар. кит. нәшр., 2009. – 368 б.
ЯһММҮ, 103 ф., 2 тасв., 41 эш
ЯһММҮ, 103 ф., 2 тасв., 57 эш.
ЯһММҮ, 103 ф., 2 тасв., 295 эш.

**_Мортазина Ләлә Рәис кызы,_**
*педагогика фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*А.А. Шәмсутова*

# М. ЮНЫС ШӘХЕСЕ ҺӘМ ИҖАТЫ

В статье рассматривается творчество известного татарского писателя Миргазияна Юнуса. На основе анализа двух новелл («Безнең өй өянкеләр астында иде...» и «Табу һәм югалту») нами определяются основные концепции творчества писателя – «туган җир», «туган нигез», «тугрылык», «милли яшәеш», «үзбилгеләнеш». Эти концепции, по мнению М. Юнуса, составляют основу мировоззрения татарского человека и помогают сохранить национальную идентичность, культуру и самоценность индивидуума.

**Ключевые слова:** татарская литература XX века, Миргазиян Юнус, новелла, «Безнең өй өянкеләр астында иде...», национальные концепты.

XX–XIX гасыр татар әдәбияты – иң кызыклы һәм иң хәрәкәтчән әдәбият. Әдәби процесс монда һәрчак үзгәреп-баеп тора: яңа темалар, актуаль проблемалар һәм боларның барысын да сүз сәнгатендә күтәргән, иҗади нигездә укучыларга җиткергән язучылар... Язучылар арасында классик әдипләребез дә аз түгел, алар инде совет чорында ук яза башлаган һәм чорлар алмашынуны үз башыннан кичергән. Ә бүген алар вазгыятькә яраклаштырып, яңача иҗат итәргә омтылалар.

Үзгәртеп корудан соң гына кулына каләмен алып, үзенең язучылык сәләтен сынап караучылар һәм саллы гына повесть, роман, хикәяләр иҗат итүчеләр дә бар. Мондый буын чагыштырмача яшь, аларның дөньяга карашы башка җирлектә – бүгенге җәмгыять шартларында формалашкан. Язучыларның әдәбият мәйданына килү рәвешен тикшергәндә, күбесенең филология яки журналистика белемле булуына һәм бу өлкәдә шактый тәҗрибәгә ия икәнлегенә игътибар итми мөмкин түгел. Бу дөрес тә, алар әдәбиятның үзен укып формалашалар, классик әдәбиятлар җирлегендә «үсәләр», «тәрбияләнәләр».

Ә менә Миргазыян Юныс, язучы буларак, мондый кысаларда «чарланмаган». Ул әдәбиятка күк йөзен һәм иксез-чиксез океан-диңгезләрне «гизеп» килеп керә. Һәм шунда ук үзенчәлекле стиле, үткен тәнкыйди карашы, турысын әйтә белүе һәм логик-интеллектуаль фикерләү өстенлек иткән язу рәвеше белән игътибарны җәлеп итә. Ә. Еники, Ф. Хөсни, Р. Мостафин, Т. Галиуллин, М. Мәһдиев кебек язучылар, тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият галимнәре М. Юнысның иҗатын XX гасырның 60 нчы елларында ук югары бәяли. Әдәбият галиме, профессор Т. Галиуллин аның иҗатының үзенчәлекле якларын күрсәтеп, болай ди: «М. Юныс геройларының эчке кичерешләрен, зиһен эшчәнлеген җентекләп, психологик нечкәлек һәм лирик моң белән

илһамланып сурәтли, рухи сфераны тасвирлауның киң мөмкинлекләрен эшкә җигә белә» [Гайнуллина, 2005, б. 6].

Миргазыян Юныс әдәбиятка күбрәк ерак сәфәрләрдән кайткач яки сәфәр барышында күңелен бушатасы килгәндә мөрәҗәгать итә. Сәяхәтче булу аңа дөньяның төрле илләрен, төрле халыкларын күрү мөмкинлеген бирә. Шуңа да аның язасы темаларының күплеген, әйтергә теләгән фикерләренең актуаль булуын тоймау мөмкин түгел. М. Юныс төрле жанрларда иҗат итә – мәкалә-притча, юлъязмалар, повесть, хикәя һ.б. Г. Гайнуллина аның иҗатының киңкырлы булуын күрсәтеп болай дип яза: «Мөһәҗирләр язмышына, диңгез хезмәтенә, чит илләрдә яшәүче халыкларның тормышкөнкүрешенә кагылышлы кызыклы һәм гыйбрәтле вакыйгаларны тасвирлаган «Безнең өй өянкеләр астында иде...», «Тимер фил», «Әти оҗмахка киткәч», «Йеменгә сәяхәт», «Бездән яшерен зәңгәр дөнья», «Диңгез чакыра» кебек хикәя, юлъязмалары һәм романтик рухлы «Занзибар зәңгәр болытлар артында» исемле повесте белән ул үз укучысын тапты, аның күңеленә үтеп керде» [Гайнуллина, 2005, б. 6].

Миргазыян Юныс иҗатының үзәген тәшкил итүче икенче тема һәм проблема – ул туган халкының яшәү рәвеше үзгәрү, милли яшәеш, үзбилгеләнеш һәм, кеше буларак, адәм баласының гуманистик кыйммәтләрне саклавы-югалтуы [Хәсни, 1981, б. 182–185]. М. Юнысның кайсы гына әсәрен алып карасак та, анда аның үз шәхесе чагыла, ягъни М. Юныс әсәрләре автобиографик характерда. Мәсәлән, «Безнең өй өянкеләр астында иде...» әсәрендә язучы үзе күргән-катнашкан вакыйганы хикәяли. Әсәрнең үзәгендә торган хикәләүче образы аша карчык сөйләгән сүзләр һәм диңгезче фикере документальлеккә якын, М. Юныс аларны бары тик иҗат аһәңе белән өреткән дә, сюжет сызыгын, проблеманы үзенчә хәл иткән – үзенчә формалаштырган. Әсәрнең төп идеясе Яшәү һәм Үлем кебек фәлсәфи төшенчәләрнең асылын ачуга нигезләнә. М. Юнысның әлеге әсәрендә автор-хикәяләүченең киң карашлы, эрудицияле һәм күпне күргән булуы күзгә ташлана. Менә шушы сыйфатлары белән М. Юныс башка язучылардан аерылып тора һәм укучылар игътибарын үзенә җәлеп итә. Ул татар авылы, татар мохите кысалары белән генә чикләнми, үз әсәрләренә Рим папасын да, Генуяда яшәгән карчыкны да, диңгезчеләрне дә китереп кертә һәм, иң кызыгы, барысын да әсәрнең идеясен ачу өчен оста куллана.

Гомумән алганда, М. Юныс иҗаты киңкырлы, үзенчәлекле. Ул милли, экологик, гомумкешелек проблемаларын күтәреп чыга һәм кыю, фәлсәфи чишелешләр тәкъдим итә. М. Юныс иҗаты тәнкыйтьче һәм галимнәр тарафыннан шактый гына өйрәнелгән. Аның әсәрләрен анализлаган авторлар әдип иҗатының тематикасына, проблематикасына, язу рәвешенә яки аерым әсәрләренә тукталалар. Әмма хикәяләренең идея эчтәлеген тудыручы

образлар системасына тулы анализ ясалганы юк әле. Әлеге мәкаләдә М. Юныснең дөньяга карашын, иҗади фикерләвенә хас сыйфатларын ачарга ярдәм иткән кечкенә күләмле хикәя жанрын («Безнең өй өянкеләр астында иде...», «Җәяүле философ») һәм шунда сурәтләнгән образлар системасын өйрәнү максаты куелды [Юныс, 2005, б. 271] .

А. Хәлим М. Юныс шәхесенә бәя биреп, «Совет басымының иң әшәке елларында урыс һәм дөнья әдәбиятының прогрессив витаминнары белән азыкланып торган М. Юныс татар әдәбиятында үзенең сирәк каләмдәшләре белән гыйсъянчылык агымын тудыруга йөз тота һәм аны саклап кала алды», – дип язган иде [Хәлим, 2005, б. 9]. Әлеге юллар М. Юныс иҗатының гомуми асылын, совет чоры әдәбиятыннан аерылып торган ягын күрсәтә. Ул – М. Юныснең «баш күтәрү»ен, яки идеология, өстән төшерелгән өйрәтмәләргә «баш бирмәү», «буйсынмавын» күрсәтә. Буйсынмау – үзе үк яшәп килгән тәртипләрне, формалаша барган гореф-гадәтләрне тәнкыйть итү дигән сүз. Язучы иҗатында тәнкыйть чалымнары исә аның әсәрләренә публицистик фикер, чигенешләр үтеп керүен дәлилли. Димәк, «тәнкыйди башлангыч» дигәндә нәкъ менә шушы моментлар күз алдында тотыла.

XX гасырның 60 нчы еллар башында илдә «Хрущев җепшеклеге» дигән сәяси этап башлангач, Октябрь революциясеннән соң татар халкының алган юлы дөрес түгеллеген күрсәтү мөмкинлеге туды. Бу уңайдан Ә. Еники («Саз чәчәге», «Рәшә»), А. Гыйләҗев («Язгы кәрваннар»), Ф. Шәфигуллин («Өй салуның ние бар?»), Н. Фәттах («Сезнеңчә ничек?»), М. Мәһдиев кебек мәшһүр язучыларыбыз, милли рухның имгәнүен буыннар арасындагы бәйләнеш өзелеп, киләчәк буын татар балаларының үз ана телен, гореф-гадәтләрен белми үсүенә, аларга битараф булган манкортлар барлыкка килүгә борчылып, чаң суга башлаганнар иде. Бу әдипләрне без гыйсъянчы әдипләр дип әйтә алабыз. Чөнки А. Гыйләҗев, Н. Фәттах, Ф. Шәфигуллиннар өчен милли мәнфәгатьләр һәрнәрсәдән өстен торды, алар үз әсәрләрендә һәрвакыт совет идеологиясенең тискәре якларын тәнкыйть итеп килделәр.

М. Юныс та, артык күзгә бәрелеп тормаса да, менә шундыйлар рәтендә иде. Ул үз әсәрләренә һәрвакыт тәнкыйть уты өсти. Нәрсәләрне, кемнәрне тәнкыйтьли соң ул? Әйтик, «Безнең өй өянкеләр астында иде...» новелласында язучы большевистик идеологиянең татарларны төрле илләргә-җирләргә сибелеп урнашырга мәҗбүр итүен, шул сәбәпле буыннар дәвамлылыгы, милли бергәлек җимерелүне тәнкыйтьли. Әби образының фаҗигале язмышына бәйләп, инкыйлабтан соң сәүдәгәрләрне, таза тормышлы игенчеләрне сөргенгә озату, туган илдән куу мәсьәләсен татар әдәбиятында беренче тапкыр күтәреп чыга [Юныс, 2005, б. 271]. «Җәяүле философ» исемле хикәясенең

нигезенә дә язучы тәнкыйди рухны салган. Әсәрнең идеясе дә кешенең табигатьне җимерүен, шуның белән бергә үз яшәү сферасын җимерүен фаш итүгә, ачуга кайтып кала. Өч биттән генә торган әлеге уйланулар сөземтәсенә әдипнең кешелекнең асылы һәм аның коточкыч киләчәге турындагы публицистик-тәнкыйди рухтагы фикерләре тупланган. Автор, иң элек, «җир өстен таш биналар» каплап алуын тәнкыйтьли. Моны кеше үзе башкарган. Үзен утыртып йөртүче, әмма үзенә буйсынмаучы машиналарны да кеше үзе төзегән. «Кояшны ясалма ут җиңгән», «Үзе өйгән ташлар эчендә адәм балаларына урын юк», «...һавада кислород калмаган, кислородны машиналар эчеп бетергән», «...күк йөзе күренмәде, аны кара болыт каплаган. Бәлки, инде хәзер биектә дә һава юктыр?», «Кояш нуры керерлек булмагач, нигә кирәк ул тәрәзә?», «Алар эштән кайту белән ашыйлар да, телевизор каршына утыралар», «Кешеләрнең бала сөяргә дә вакытлары калмый», «Адәм балалары бер-берсенең башы өстендә һәм аяк астында гомер итәләр», – менә болар барысы да кешеадәм баласы ашыгып-ашкынып башкарган техноген нәтиҗәләр, цивилизация казанышлары һәм аның афәте дә. Үзе тудырган техник-индустриаль монстрлар адәм баласына рәхәтләнеп яшәргә, туктап ял итеп, гаиләсен-балаларын, хатынын, ирен сөяргә, дуслар белән үчекмичә аралашырга мөмкинлек бирми.

М. Юныс әнә шуларны тәнкыйть итә. Тәнкыйди-публицистик бу уйланулар тирән фәлсәфә белән сугарылган: «Без җиргә шуның өчен килдекме? Без үз кадеребезне, бер-беребезнең, кеше дигән затның кадерен белмибез. Аңа эш аты, яки бер мәхлук итеп карыйбыз».

М. Юнысның «Табу һәм югалту» повестенең үзәгенә дә тәнкыйди рух салынган. Тәнкыйть монда татар милләтеннән булган Мәрьям белән Габдрахманның үзара бер-берсен аңламаулары гына түгел, ә татар рухының, татар моңының шәһәр кешеләрендә, киләчәк буын вәкиле булган Кәримәдә дәвам ителмәвен дә ачык күрсәтә. Әсәрнең төп проблемасы – буыннар арасында рухи бәйләнеш өзелү. Тәнкыйтьче Равил Рахмани М. Юнысның бу әсәрен анализлап, автор әлеге әсәрдә гаять четерекле проблемаларның берсенә туктала һәм милләт тормышындагы бу фаҗигане аның кечкенә өлеше булган гаилә тормышы аша сурәтли. Шул рәвешле язучы милли яшәешкә диагноз куя [Рахмани, 2003, б. 19].

«Табу һәм югалту» әсәрендә төп сюжет сызыгыннан түбәндәге элементларны аерып күрсәтә алабыз. Төенләнеш – Мәрьям иренең, кызын алып, туган ягына кайтып китүе. Вакыйгалар үстерелеше – поездда кайту, кызы белән сөйләшү. Кульминацион нокта – чишмә янына бару, чишелеш – әнисен күрү, аның янына кайту. Повестьта шулай ук ярдәмче сюжет сызыгын да билгели алабыз. Ул Мәрьям белән бәйле һәм төенләнеш монда хатынның ире белән кайтырга теләмәвендә. Вакыйгалар үстерелеше –

Мәрьямнең иренә хыйнәт итүе. Кульминацион нокта – аның авылга, ире янына кайтырга карар кылуы. Чишелеш исә авылга кайтып керүендә.

«Табу һәм югалту» әсәрендә тәнкыйди башлангычларның объектын түбәндәге эпизодларда күрсәтә алабыз. Беренчедән, Габдрахман – Мәрьям мисалындагы татар гаиләсендә, мөселман гореф-гадәтләре үрнәгендәгечә, ата – ир, баш кеше түгел, аңа ихтирам, аның сүзен олылау юк. Моны без Кәримәнең һәм Мәрьямнең Габдрахман белән сөйләшүендә үк тоябыз. Кәримә этисен олы итеп түгел, ә балаларча эгоизм белән сөйләшә. Мәрьям исә, замана хатын-кызларына хас булганча, ирен өстен күреп түгел, ә үзенең башкалада тууын һәм азат хатын-кыз булуын тоеп сөйләшә.

Икенчедән, автор Мәрьямнең Габдрахманның туганнарына кимсетеп каравын да тәнкыйтьли. «Мәрьям аларны нигәдер өнәмәде» [Юныс, 2005, б. 65]. Шул ук вакытта М. Юныс провинциядән килүче татар кешесенең мескенләнеп калуын, югалып калуын тәнкыйтьли дә сыман. Шәһәрдә татар рухының үзәген тәшкил иткән авыл кешеләренә мөнәсәбәт – негатив, аларга «авылча» дип карыйлар. «Габдрахманның туганнары чиксез юаш, үзләрен бер сәбәпсезгә кимсетеп күрсәтергә яраталар» [Юныс, 2005, б. 66]. Бу юлларда авыл һәм шәһәр мәдәниятләренең ике милли мәдәният кебек кабул итүлүе, ике менталитет булуы ассызыклана. «Ләкин алар – читләр. Гадәтләре, зәвыклары, культуралары белән читләр» [Юныс, 2005, б. 66].

Әсәрдә ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәт тәнкыйть ителә. Мондый мөнәсәбәтнең сәбәбе, алда әйтелгәнчә, аларның ике төрле мәдәни шартларда (гәрчә бер милләттән булсалар да) тәрбияләнеп үсүендә, икесенең ике төрле рухи кыйммәтләрне өстен күрүендә [Вәлиев, 1982, б. 98]. Мәрьям, шәһәр-башкала кызы булгач, цивилизацияле, матур итеп яшисе килә. Габдрахман күңелендә икенче төрле хис – туган ягының милли рухы, моңы. Ул авылга кайтуны, табигатькә якынрак булуны өстен күрә. Автор, шәһәр, цивилизация татарны моңыннан, рухыннан ерагайта, дип саный.

Автор «байлык» төшенчәсенең эчтәлеге аша нинди буын нәрсәгә табынуын, аларның рухи кыйммәтләрен күрсәтә. Габдрахманның кечкенә кызы өчен байлык – ул муллык, матур кием, машина булса, Габдрахман өчен байлык – ул милли музыка, китап-мәгърифәт, тынычлык, тату яшәү, үз туган җирендә рәхәтләнеп яланаяк басып йөрү [Юныс, 2005, б. 66]. «Китап байлык түгел, кәгазь генә... Сез минем туган көнемә генә курчак алып бирәсез. Әнинең институт кичәсенә киеп барырга юньле күлмәге дә юк. Без – ярлы, белдеңме?», – ди Кәримә. Аның сүзләрендә дә хаклык юк түгел.

Тәнкыйть уты шәһәр һәм авыл тормышын чагыштырып, шәһәрнең, «Җәяүле философ» хикәясендәгечә, техник-индустриаль «төрмә» икәнлеге, кешегә, бигрәк тә авыл кешесенә,

табигатьтә үскән саф җанлы кешегә начар тәэсир итүе тәнкыйть ителә. «Рәхәт яши авыл кешесе», «Мәскәүдә мин үземне бәйгедә чабышкан ат кебек тоям», ди автор [Юныс, 2005, б. 70]. Ул шәһәр кешесенең психологиясен, ягъни шәһәр кешесенең үзара дикъкатьсезлеген, туганнарына сүлпән каравын тәнкыйтьли [Юныс, 2005, б. 71].

Повестьта татар хатыннарының, гадәти булмаганча, ирләренә хыянәт итүләре тәнкыйтьләнә. Әсәрнең «Табу һәм югалту» дип аталуы да нигездә менә шул аспект белән бәйле. Авылга ялга киткән иренең уңай һәм тискәре якларын барлап чыккан Мәрьям образы аша, М. Юныс чит ир турында хәтта уйлау да, аның бүләген кабул итү дә хыянәт, дип билгели. Мәрьям исә татар хатыны югарылыгында менә шушы хыянәттән исән-имин калдырыла. Шуның белән автор татар хатын-кызлары өчен ныклы тыл булуның зарурлыгына, аның гаилә иминлеге, бөтенлеген тәшкил итүче төп вазифаны үтәргә тиешлегенә һәм андый сыйфатларның һәр татар кызында булырга тиешлегенә басым ясый [Мостафин, 1980, б. 165].

Повестьта җәмгыятьтәге икейөзлелек, кешеләрнең бер-берсен «сатулары» да тәнкыйтьләнә. Бу исә Мәрьямнең Таганка театрында Пугачев турындагы спектакльне каравы белән бәйләп ачыклана. «Чынбарлыкта бу көрәш һаман дәвам итә». «Заманалар үтү белән яшәешнең тышкы кабыгы гына үзгәрә икән», – дигән фикерне әйтә автор [Юныс, 2005, б. 85].

Бүгенге көндә милли этнографияне тәшкил итәргә тиешле чиккән сөлге, самовар, бәйләүчигү, чалгы, өстәл, урындык кебек әйберләрнең кешенең үз кулы белән ясамавын, үз иленнән дә түгел, хәтта чит илнекен алу модага керүен тәнкыйтьли автор. «Үз кулы белән ясалган бер нәрсәсе дә юк аның квартирында... Бәлки, шуңа күрә әйбергә ихтирам юктыр?.. Сатып алган әйбернең каян җаны булсын?» [Юныс, 2005, б. 88]. Димәк, үз кулы белән ясалган һәр нәрсә кешенең энергетикасын саклый, аңа яшәргә көч бирә.

М. Юнысның повестьларында күтәрелгән милли тема аның хикәяләрендә дә чагылыш таба. Шул ук вакытта ул, француз язучысы Жан-Жак Руссо кебек, цивилизация һәм аның кешелек дөньясына китергән афәтләре турында да уйлана. Бу яктан ул гуманистик язучы буларак чыгыш ясый.

**М. Юныс хикәяләрендә образлар бирелеше**

Тормыш-чынбарлыкны сурәтләгәндә язучы реаль яшәештәге һәрнәрсәне игътибар үзәгеннән үткәрә, аларны берләштерә, эшкәртә, үз фикерен җиткерү өчен мөһим булганнарын индивидуальләштерә, калганнарын җыйнап типиклаштыра. Шул рәвешле сюжет сызыгын формалаштыручы вакыйгалар һәм бу вакыйгаларның үзәген тәшкил итүче образлар барлыкка китерелә. Димәк, әдәби әсәр, образлардан башка була алмый. Образ – ул сәнгати иҗатның гомум категориясе, ул тормышны гәүдәләндерүнең, аңлатуның

һәм танып белүнең үзенчәлекле сәнгати-иҗади формасы [Литературная…, 2003, с. 669]. «Образ – самый способ существования произведения, взятого со стороны его выразительности, впечатляющей энергии и значимости... В онтологическом аспекте, образ есть факт идеального бытия, своего рода схематический объект, надстроенный над своим материальным субтратом. Образ не совпадает со своей вещественной основой, хотя узнается в ней и через нее» [Литературная…, 2003, с. 270].

Рус әдәбияты белемендә «образ» категориясен «күренеш итеп кенә түгел, «билге» итеп карау алга чыкты. «Знак это средство смысловой коммуникации в рамках данной культуры или родственных культур» [Литературная…, 2003, с. 271]. Образларны гомумиләштерергә һәм индивидуальләштерергә мөмкин. Ләкин һәрбер образ да ахырынача конкрет булып бетә алмый. Реаль тормыш ул барыбер күпмәгънәлелеккә ия. Шул сәбәпле, образ эчке формасы белән авторның идеясенә буйсынучан була, дип әйтә алабыз. М. Юныс әсәрләрен укыганда игътибарны тагын шул күренеш җәлеп итә – аның образлары башка язучыларныкына охшамаган. Аның әсәрендә сюжет композициясен нәкъ менә образлар тудыра.

**«Безнең өй өянкеләр астында иде...» хикәясендә образлар системасы.** Әдипнең бу әсәре милли мәсьәләне алгы планга чыгарып, аны тема дәрәҗәсенә күтәрә. Кыска-җыйнак сюжет, киеренкелек, гадәттән тыш вакыйга һәм көтелмәгән чишелеш бу әсәрне «новелла» дип атарга мөмкинлек бирә. Новелланың гадәттән тыш вакыйгасы дигәндә без хикәяләүченең чит илдә татар карчыгын очратуын истә тотабыз.

Әсәрдә хикәяләүче образы Габдрахман Рахманкулов булса да һәм ул беренче заттан сөйләсә дә, әсәрнең төп герое итеп татар карчыгын атарга кирәктер. Г. Рахманкулов образы автор образына якынайтыла һәм шул сәбәпле ул авторның лирик, фәлсәфи һәм публицистик фикерен җиткерүче булып тора. Ул – пароходта капитан ярдәмчесе, татар кешесе, формальлеккә һәм рухи кыйммәтләргә карата да үз карашлары бар.

Кочегар Трак – совет тәрбиясе алган һәм тормышка гадигадәти бер вакыйга итеп карый торган кеше, эш көче белән икмәк табучы образ. Ул сәнгать ядкарьләренә дә гадәти бер предмет итеп карый, ул яшәү фәлсәфәсе – Яшәеш һәм Үлем турында да тирәнтен уйлый белми. Бу аның Италия зиратында таш сыннарны карап йөргән чактагы сүзләре аша җиткерелә. «Нигә кирәк иде мондый кыйммәтле матурлык. Үлгән кешегә нинди кабер дә барыбер түгелмени» [Юныс, 2005, б. 18]. Тракка мөнәсәбәт, аңа характеристика Маркин фамилияле штурман образы аша җиткерелә: «Надан кеше син, Трак. Кабер бизәү – кеше заты үлгәч тә кадерен югалтмый дигән сүз ул» [Юныс, 2005, б. 18]. Әмма әсәрнең сюжет сызыгы дәвамында без Тракның Маркинга караганда хаклы

булуын аңлыйбыз. Чыннан да, исән чагында кадерен белмәгән кешегә үлгәч матур кабер кирәк түгеллеген ассызыклый кебек автор. Аның бу фикере Маркин әйткән сүзләр яктылыгында тагын да калкулана төшә. «Гуманизм кагыйдәсе җир йөзендә безгә кадәр яшәгән кешеләрне дә хөрмәтләргә куша. Адәм баласы исән чакта гына түгел, дөнья куйгач та бәясен югалтмый дигән сүз» [Юныс, 2005, б. 19]. Әмма әсәр сюжетында М. Юныс моның киресе булуын ача. Шушы ук фикер аның «Җәяүле философ» хикәясендә дә каршылыклы фикер итеп бирелә. Димәк, адәм баласы исән чагында да, үлгәч тә кадер-хөрмәттә булырга тиеш. Бу фикер татарның бер вәкиле булган карчыкка карата мөнәсәбәт белән каршылыкка керә. Бу каршылык идеологиянең рус солдаты каберенә булган мөнәсәбәте аша тагын да тирәнәйтелә. «Үзебез теләп түгел, мәҗбүри, пропаганда өчен куйдырталар иде чәчәкләрне. Урыс солдатының батырлыгын дөньяга таратыр өчен» [Юныс, 2005, б. 18].

Хикәянең үзәк вакыйгасын хәрәкәткә китерүче образ – ул татар карчыгы образы. Италиядә – үзе генә түгел, исеме дә телгә алынырга бернинди сәяси-патриотик сәбәп булмаган бер урында – татар карчыгын очрату әсәрнең гадәттән тыш хәл булуын күпертеп куя. Очрашу вакыйгасы татар морягын гына түгел, карчыкның үзен дә тирәнтен гаҗәпкә калдыра, карчык башта моны саташу дип кабул итә. Карчык өчен ул гомеренең соңгы елларында көткән якты очрашу була, чөнки ул туган җиренә кайтып җирләнү өметен йөртә. Әсәр ахырында карчыкның, шушы хыялын югалтмас өчен, пароходка кереп яшеренүе дә шуңа бәйле кебек.

Карчыкның хис-кичерешләрен психологизм алымы аша җиткерә М. Юныс. Әмма аның психологизмы тирән түгел, ул бары тик детальләргә игътибар юнәлтү аша гына герой кичергән халәтне бирә. Мәсәлән, «Карчык бөтенләй югалып калды. Ни әйтергә, нәрсә эшләргә белми, хәлсез куллары белән күлмәк итәген сыпыра: «И Ходаем... и Ходаем...» яки менә тагын бер өзек: «Карчыкның күзләреннән *ике бөртек яшь* тәгәрәп чыкты да җыерчык буйлап битенә таралды». «Учы белән тамак астын уа. *Иреннәре дерелди*. Нидер әйтергә тели, ләкин авызыннан сүзе чыкмый» (23 б.). М. Юныс иҗатын анализлап, әдәбият галиме Г. Гайнуллина «Автор карчыкның хис-кичерешләрен сурәтли һәм шуның аша туган туфракны юксыну, җирсенү проблемасын куя», – дип яза [Гайнуллина, 2005, б. 8]. Әлеге проблема әсәрдә карчыкның хис-кичерешләрен дәлилләгән сөйләмендә ачык чагыла.

Югарыда без М. Юныс кеше психологизмын детальләр аша җиткерә дигән идек. Язучы образларның психологиясен аерып тасвирламаса да, монолог-диалоглар аша геройларының күңел дөнгезен ачып сала белгән. Туган җирдән аерылган карчыкның сөйләмендә без аның нигезен, туган йортын, авылын, аның һавасын, кичләрен,

кешеләрен, ягъни атмосферасын һәм күңеленә якын булган изге гореф-гадәтләрен бик нык сагынуын, шуның белән милли асылын саклап калырга теләвен тоябыз. «*Язын сабан туена, җыенга, көзен каз өмәсенә җыела идек... Өй бүрәнәләрен эчке яктан кырып юа иек... Гәрәбә шикелле сап-сары булып китә иде...», «Безнең өй өянкеләр астында иде. Ык яры буенда... Өянкеләр төбендә иде өебез...*» [Юныс, 2005, б. 23].

Язмыш сынавы аркасында чит җирдә, Италиядә, торып калган татар карчыгы мисалында М. Юныс чит илләргә чәчелгән, күчеп китәргә мәҗбүр булган татар мөһаҗирләре проблемасын күтәрә. Әлеге проблема әсәрдә «туган туфрак» кебек милли мотивлашкан образ аша көчәйтелә. «Туган туфрак» образы югарыда китерелгән милли асыл төшенчәсен ныгытып, бербөтен итеп торган образ. Әмма татар карчыгы, хыялындагыча, кулына ничә еллар инде күрмәгән, toймаган туган туфракны тотып карау бәхетенә ирешә алмый. «Пароходта туган ил туфрагы юк икән, әби. Икенче килгәндә алып килермен» [Юныс, 2005, б. 22]. Дөрес, туган илдән аерылу максатын куймаган адәм баласы үзе белән туган туфракны йөртми.

Карчыкның туган илен сагынуы аның гамәлләре, сөйләве аша бирелә. Бу – нәкъ менә новелла жанрына хас сыйфатларның берсе. Психологизм монда тасвир рәвешендә түгел, ә геройларның эш-гамәлләре аша җиткерелә. М. Юныс карчыкның кичерешләрен чагылдырган диалогларны әсәрнең буеннан буена чәчкән. *«Бүген төне бу Карамалымны күреп саташтым», «Картайган саен ныграк җирсендерә», «И, Ходаем, ничек үлмәдем икән бу кадәр сагынуымнан»* [Юныс, 2005, б. 23].

Монда хиснең эволюциясен күрсәтеп булыр иде. Шушы куәтле сагыну хисен басар өчен кирәкле шартлар итеп автор *туган илгә кайту* яки *туган җир туфрагы*н тотып карауны атый. Болар да булмаса, туган илдән килгән ризык – *икмәк кисәге* дә кадерле нәрсәгә әверелә. Әмма әсәрнең ахырында без героиняның калган ике атрибутка ирешүен – туган иленә кайтуын һәм туган җир туфрагына күмелүен беләбез.

Шул рәвешле, М. Юныс үз иҗатында «миллилек» төшенчәсенең тулы бер эчтәлеген бирә. Моны ул, беренчедән, мөһаҗир карчык образы аша башкарса, икенчедән, миллилекнең югалуы белән бәйләп тасвирлый. Бу очракта ул инде татар карчыгыннан туып та, милли мохиттә тәрбияләнә алмаган, милли тәрбия бирергә чит илдә мөмкинлекләре булмаган, туган телне – ана телен иң кадерле дип саный белмәгән һәм, иң әһәмиятлесе, – туган җирләре Идел буе икәнен белмәгән балалар аша җиткерә. «Туган илне белмиләр бит алар» [Юныс, 2005, б. 23]. Әлеге сүзләр карчык авызыннан юкка гына әйтелмиләр. Әсәрнең тирән фәлсәфәсе шуннан гыйбарәт: «*Бары тик Туган иле булганда гына һәм туган илдә лаеклы кеше булып яшәгәндә генә туган тел, милли гореф-гадәтләр, милли тәрбия*

*була ала»*. Татарларның үз туган җирләреннән таратылуы әсәрдә «Сак-Сокларга» әйләнеп беттек», «Өермәгә эләккән тузганаклар шикелле таратып ташлады безне язмышлар» [Юныс, 2005, б. 24] дип ассызыклана.

Хикәянең фокусын карчык образы тәшкил итә, аның язмышын, кичерешләрен өянке образы төйнәп тора. *«Өянке образы»* – ул әсәрдә туган йорт, җир, татар җире символы булып яңгырый торган концепт.

Символик образларның иң кызыгы – ул кораб, пароход образы. Әлеге образ карчыкның туган җиргә кайту өметен символлаштыра «Алып кайт син мине, улым. Кая булса да, яшер... Нинди җәзага да риза. Алып кайт!». Карчыкның туган җирен сагыну хисенең соң дәрәҗәдәге киеренкелеген чагылдырган бу гыйбарәдә карчыкның өметен югалтасы килмәү дә тоемлана.

Кораб – карчык өчен туган илгә кайтуның бердәнбер мөмкинлеге. Менә шул сәбәпле ул пароходка кереп яшеренә. Диңгездәге кораб исә, татар шагыйре Дәрдемәндтәгечә, тормыш дулкыннары эчендәге хәят итеп тә, тулы бер Ил итеп тә «укыла» ала.

Новелла жанрына хас булганча, М. Юныс әлеге әсәрендә вакыйгаларны сурәтләүдә көтелмәгән борылыш тәкъдим итә. «Теге карчык тагын пароходка килгән иде, полисмен кертмәде, куып җибәрде, – дип каршы алды мине вахтада торучы матрос» [Юныс, 2005, б. 25], әлеге урында укучы да карчыкның моңсуланып кайтып китүен күз алдына китерә. Әмма автор көтелмәгән борылыш ясый – карчык пароходка керә. Аның теләге – «бабаларыбыз яшәгән туган ил туфрагына» күмелү. Әсәрнең ахырында кулланылган диңгез образы реаль тормышны символлаштыра. «..җил, көйчәйгәннән көчәеп, давылга әйләнде» дип характерланган юллар тормыштагы вакыйгаларга ишарә булып яңгырыйлар сыман.

Шул рәвешле, язучы М. Юныс үз әсәрләрендә күпне күргән, бик күпне белә торган, тирән һәм киң карашлы, гомумкешелек кыйммәтләрен һәм милли гореф-гадәтләрне туган иленә һәм кешелеккә чын тугрылык, бирелгәнлек белән саклый белүче әдип буларак чыгыш ясый. Аның кайсы гына әсәрен алып карама, аларда язучы яшәү мәгънәсен туган халкына, туган туфракка һәм милли традицияләргә бәйле рәвештә аңлата. Шәхеснең, ягъни үз әсәрләрендә гәүдәләндерелгән геройларның да (уңаймы алар, тискәреме) асылы черек яки нык булуын, киләчәк буыннарның милли яктан сау-сәламәт, милли үзаңлы, милли характерлы булуын шушы сыйфатлар аша үлчи әдип.

М. Юныс – әдәбиятка зур тормыш тәҗрибәсе туплап килгән язучы. Аның XX гасырның 60 нчы елларында иҗат ителгән әсәрләре һәм соңрак 70–80 нче елларда язылган «Тозлы җил», «Теләп алган давыл» повестьлары, хикәя, новеллалары да тема һәм проблематика ягыннан татар әдәбиятын баеттылар [Ганиева, 1975]. М. Юнысның соңгы елларда бүген дә укучылар яратып укый торган һәм тәнкыйди

рухта язылган «Табу һәм югалту» (1979), «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» (1983) повестьлары, «Юлда уйланулар» дип исемләнгән сәяхәтнамәсе басылып чыга. Бу әсәрләрендә М. Юныс чын художник буларак чыгыш ясый, чынбарлыкны заманның олы проблемалары, тарихи үсеш-үзгәреш юнәлешләре җирлегенә куеп яктыртырга омтыла, вакыйга-хәлләрне аңлатуда, кеше характерларын ачуда, тормыш конфликтларын чишүдә психологик, әхлакый-фәлсәфи анализга урын бирә, шуның белән Г.Ахунов, А. Гыйләҗев, М.Мәһдиев, Ә. Еники һәм башка чордашларыннан аерылып тора [Мәһдиев, 1977, б. 148] .

Әсәрләрне тикшерү түбәндәге нәтиҗәләргә этәрә:

1. М. Юныска хас сыйфатларның берсе – ул әйбер-күренешнең, кеше холкының асылын аңларга омтылу, алар хакында туктаусыз уйлану. Менә шушы уйланулар аны әсәрләренең лирик, публицистик һәм фәлсәфи чигенешләрен-җирлеген тудыралар.

2. Фәлсәфи-публицистик бу чигенешләр М. Юныс иҗатына хас икенче бер сыйфатны – тәнкыйди рухны тәэмин итәләр. М. Юныс үзенең тәнкыйди рухы белән классик язучылар М. Мәһдиев һәм А. Гыйләҗевкә якын тора. Әмма М. Юнысның тәнкыйди фикерләре саф, яшерен яки бормалы түгел (әйтик, М. Мәһдиевтәге кебек), аның җөмлә төзелеше дә «челтәрләрсез», ягъни беренче карашка коры, гади тоела.

3. М. Юныс үз әсәрләрендә, башлыча, татарның рухи кыйммәтләрне онытуын, милли үзаң, гореф-гадәтләр җимерелүне («Табу һәм югалту»), туган яктан китәргә мәҗбүр ителеп, телдән читләшүне («Безнең өй өянкеләр астында иде...»), табигать белән кеше арасындагы үзәк җеп өзелүне, кешенең техник-индустриаль «монстрлар» астында калып табигый яшәештән аерылуын, кешегә кадер-хөрмәт белән, Кеше итеп карау бетүен («Җәяүле философ») тәнкыйтьли.

4. 2004 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган «Альбатрос язмышы» исемле публицистик әсәрләр җыентыгында исә авторның тәнкыйди характердагы язмалары урын алган. Анда М. Юныс татар теленең дөнья аренасында урын яулый алмавы турында борчыла-уйлана. Татар теленең урынын рус теле яулап алуның сәбәпләрен атый. Шулар арасында тарихи катаклизм саналырга хаклы 1552 елгы канлы вакыйга, ялган идеология, хакимият башындагыларның татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрергә тырышмавы дәлилле фактлар белән исбатлана.

Әлеге китабында үзен чын милләтпәрвәр язучы итеп таныткан М. Юныс повесть һәм новеллаларында да туган тел мәсьәләсен туган туфракны олылау, гореф-гадәтләргә, гаиләгә мөнәсәбәт аша чагылдыра. Публицист буларак, әдип милли мәсьәләдә үз укучысында дөрес караш формалаштырырга, ялган сәясәтнең асылын ачарга омтыла. А. Хәлим әйткәнчә, М. Юныс үз әсәрләрендә чор идеологиясенә

баш бирмәс, буйсынмас гыйсъянчы буларак чыгыш ясый.

Йомгаклап әйткәндә, М. Юныс, идеологиягә буйсынмый торган һәм үз иҗаты белән бары тик туган халкына, аның үзаңын, милли горурлыгын үстерүгә хезмәт итүче талантлы, туры сүзле әдипләр сафын тулыландыра.

**Әдәбият**


*Вәлиев М.* Бер язучының ике повесте // Вәлиев М. Табарга һәм югалтмаска. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан, 1982. Б. 97–104.

*Гайнуллина Г.* Кереш сүз // Юныс М. Әсәрләр. Казан, 2005. Б. 5–17.

*Ганиева Ф.* Тормыш фәлсәфәсенә тугрылык («Тозлы җил» повесте турында) // Татарстан яшьләре. 1975. 27 сентябрь.

Литературная энциклопедия терминов и понятий / под ред. А. Николюкина. М.: Интелвак, 2003. 1080 с.

*Мәһдиев М.* Секстант белән йолдызлар үлчәргә: М. Юныска 50 яшь // Казан утлары. 1977. № 5. Б. 148–152.

*Мостафин Р.* Табышлар һәм югалтулар // Казан утлары. 1980. № 9. Б. 162–164.

*Рахмани Р.* Кыйблабызга тугрылык // Юныс М. Әсәрләр. 6 томда. Т. 1. Казан: Рухият, 2003. Б. 5–41.

*Хөсни Ф.* Сагыну лирикасы. Бер монолог // Казан утлары. 1981. № 7. Б. 182–184.

*Юныс М.* Әсәрләр. Казан: Мәгариф, 2005. 271 б.

*Юныс М.* Әсәрләр. 6 томда. Т. 1. Казан: Рухият, 2003. 405 б.



***Шәмсутова Алсу Атлас кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы,*
*«Татар мәдәнияте һәм сәнгате» оешмасы мөдире*

УДК 821.512.145

***А.М. Сафина***

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА МИЛЛИ ХАРАКТЕРНЫҢ ФОРМАЛАШУЫ

В данной статье исследуются отражение национального характера в татарской прозе до второй половины XX века. Прослеживается формирование национального характера в древнетюркской и средневековой литературе, а также в произведениях XIX – начала XX в., военного и послевоенного периодов.

**Ключевые слова:** татарская литература, национальный характер, произведения, писатель, средневековая литература, первая половина XX века.

Матур әдәбият кешене чолгап алган реаль чынбарлыкны, аның эчке дөньясын, рухи халәтен чагылдыра, тормышны төрле яктан җентекләп сурәтли. Аның үзәгендә – кеше, аның рухи дөньясы, эш-гамәле, табигать һәм җәмгыять белән үзара мөнәсәбәтләре тора. Шул ук вакытта ул кеше тормышын, чынбарлыкны билгеле бер дәрәҗәдә милли традицияләр аша гәүдәләндерә, халыкның уй-кичерешләрен, теләк-омтылышларын, мәнфәгатьләрен, милләтнең тарихи язмышын тасвирлый.

Әдәбиятта милли характер гасырлар дәвамында формалашкан милли-мәдәни җирлектә барлыкка килеп, күп баскычларны, дәвер һәм этапларны үтә. Аның формалашу юлын халык авыз иҗаты әсәрләрендә, Орхон-Енисей язмаларында, рун язулы истәлекләрдә, С. Тудунгның «Алтын йарук», Баласагунлының «Котадгу белек», М. Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрек», Ә. Йүгнәкинең «Һибәтел-хәкаик» кебек борынгы чыганакларда очратырга була. Әдипләр билгеле бер тарихи чорда халык тормышын һәм язмышын халык авыз иҗаты әсәрләренең милли-мәдәни һәм сәнгати традицияләренә таянып сурәтләргә тырышалар. Әсәрләрендә тасвирланган тарихи вакыйгаларны аңлатуны үз өсләренә алып, үзәккә шул чорның милли характерын чагылдыручы мәрхәмәтлелек, кешелеклелек һәм башкаларны ярату идеясе тәрбияләү мәсьәләләрен алгы планга чыгаралар. Тарихи проза әсәрләрен иҗат иткәндә халык авыз иҗатының әһәмиятенә тукталып, әдәбият галиме Ф. Мусин болай ди: «[…] тарихны миф, легенда яки риваять ярдәмендә дөрес күзалларга мөмкин, тарихи үткәнне яктыртканда мифологик материалга кайчак документаль чыганаклар бик аз булу яисә бөтенләй булмау сәбәпле мөрәҗәгать ителә. [...] Чөнки билгесез чорны аңлау һәм күрсәтү мәсьәләсен автор җитлеккән тарихи-социаль фикерләргә ия булганда гына уңышлы хәл итәргә мөмкин» [Мусин, б. 97]. Әлеге әсәрләргә дөньяны яхшылык һәм явызлык, яшәү һәм үлем, бердәмлек һәм таркаулык тигезлеге белән күзал-

лау, батырлыкка соклану, кыюлыкны мактау, киләчәк буыннарга нәсыйхәт, табигать көче алдында баш ию кебек милли характердагы сыйфатлар хас.

Урта гасыр әдәбиятында милли характерның үсеш-үзгәрешен төрле жанрдагы язма чыганакларда күрергә була. Урта гасыр әдәби әсәрләрендә, эш-гамәлләрендә, холык-фигыльләрендә милли характер сыйфатлары чагылыш тапкан затлы кеше идеалы, дини (Аллаһыга мәхәббәт) һәм дөньяви (гадел идарәче, кеше кадере, дөньяның фанилеге, җәмгыятьтә кешенең урыны кебек темалар) мотивларның тоташуы аша, кешенең үз мәнфәгатьләре өчен генә түгел, җәмгыять, халык, кешелек дөньясы гаме белән дә яшәве гәүдәләндерелә. Шул ук вакытта милли характер кеше тормышындагы, табигатьтәге үзгәрешләрне, тарихи вакыйгаларны, Илаһ һәм язмыш белән бәйле хәлләр барышын яктыртканда чагыла. Урта гасыр әдәбиятында кеше гомумирәк, абстракт планда тасвирлана. Аның асылын, эш-гамәлләрен Аллага, илаһи көчкә мөнәсәбәттә тикшерү, бәяләү өстенлек итә. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Мөхәммәдъярның «Нуры содур», М. Болгариның «Нәһҗел-фәрадис», Х. Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» һ.б. әсәрләр моның ачык мисалы булып тора.

Татар әдәбияты, урта гасыр әдәбияты традицияләрен дәвам итеп, XIX йөз яңару омтылышы көчәя барган дәвергә килеп керә. Шуңа да XIX йөз татар әдәбияты милли уяну, ягъни мәгърифәтчелек дәвере чоры буларак характерлана. XIX йөз прозасында милли характер милләтне агарту, әхлакый тәрбияләү, халыкны белемле, мәгърифәтле итү кебек милли тормышның актуаль мәсьәләләрен яктырткан темаларда урын таба. Милли характерны сурәтләгәндә язучылар кешене реаль тормыш белән тыгыз мөнәсәбәттә бирү, милләтнең бүгенгесен һәм киләчәген кайгырту, аны бербөтен итеп карау, халык тормышын яхшыртуны гыйлемгә, әхлакый сыйфатларга, тәрбиягә һәм әйләнә-тирәгә мөнәсәбәттә карау, идеал кеше образы тудыру кебек иҗат принципларын кулланалар. Г. Утыз Имәни, М. Акмулла, Һ. Салихов, Ә. Каргалый, Г. Кандалый, Ш. Зәки, К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, М. Акъегет, З. Бигиев кебек язучыларның әсәрләрендә ул аеруча калку чагылыш таба. Борынгы әдәбият кешеләрне тату яшәтер өчен тырышса, XIX гасыр әдәбияты милләт язмышы өчен борчыла. Элек татулыкка ирешү чарасы кешеләрнең Аллаһыга тугрылыгы һәм сабырлыгы белән аңлатылса, яңа чор әдәбияты милләтне уяту юлын мәгърифәттә күрә. Борынгы әдәбиятның үрнәк герое, Йосыф кебек, Аллаһыга тугрылыклы, сабыр, тәүбә итә белүче пәйгамбәр булса, ул еллардагы әдипләр, үрнәк герой итеп, Ш. Мәрҗани кебек укымышлы, белемен гамәлдә файдаланучы һәм һөнәрле җир кешесен сайлыйлар.

XIX гасыр татар әдәбиятының үткән юлын игътибар белән күзәткәч, аның халык тормышының көзгесе икәнлеген күрәбез.

Баштагы чорда анда наданлыкны бетерүгә, тәнкыйтьләүгә юнәлтелгән әсәрләр урын алса, чор ахырында ул халкыбызның әхлагын яхшырту юнәлешенә йөз тота. Бу күренеш язучылар тарафыннан кешенең гыйбрәтле язмышын тасвирлау, югары әхлак нормаларын раслау һәм язучының мәгърифәтчелек идеяләрен үзендә туплаган уңай герой образы тудыру аша яктыртыла.

XX йөз башы әдәбияты кыска гына вакыт эчендә әдәби-эстетик яктан зур үзгәреш кичерә. Европа фикер ияләренең гуманистик һәм фәлсәфи идеяләре, рус җәмгыятендәге демократик үзгәрешләр, татар иҗтимагый фикеренең Ш. Мәрҗани, Ш. Күлтәси, Ә. Каргалый, Г. Курсави, Г. Утыз Имәниләрдән килгән тамырлары XX йөз башы әдәбиятына зур йогынты ясый. Тормышка йөз белән борыла баручы, реаль образларны, реаль вакыйгаларны сурәтләү объекты итеп алып, ситуацияләр һәм детальләр дөреслегенә омтылучы яңа төр татар прозасына нигез салына. Чөнки XX йөз башындагы икътисади, иҗтимагый, мәдәни тормыш дөнья сәнгатендәге яңалыкларны татар әдәбиятына алып керер дәрәҗәгә ирешә. XX йөз башында тарихилык идеясе тагын да үстерелә һәм әдипләрнең дөньяга карашында күренекле урын ала. Бу дәвердә әдипләр, милли әдәбиятның күпгасырлык бай традицияләренә таянып һәм аларны дәвам иттереп, сүз сәнгатенең халык тормышындагы ролен тагын да югарырак күтәрергә һәм үстерергә омтылалар. «Үз милләтеңне сөяргә теләсәң, – ди Ф. Әмирхан, – башлап аның тарихын белергә, аның бу көнге тормышының нинди сәбәпләр белән вөҗүдкә килгәнлеген аңларга кирәк» [Әмирхан, б. 396].

Геройларда милли характер сыйфатларының заман белән бәйләнешен сурәтләгәндә Ф. Әмирхан иҗатында шәһәрдә яшәүче татар югары катлаулары арасыннан чыккан милли интеллигенция вәкилләре үзәктә торса, Ш. Камал әсәрләрендә Россиянең төрле почмакларында бәхет эзләп йөргән гади кешеләрне күрсәтүгә зур урын бирелә. М. Гафури прозасы шәһәр һәм авыл ярлыларының, хатын-кызларның көндәлек авыр тормышын, кызганыч язмышын тасвирласа, Г. Ибраһимов әсәрләрендә авылның өстен катлаулары белән бәйле интеллигенция, урта һәм түбән катлау крестьян образларына игътибар ителә.

XX йөз башы прозасы милли характерны гәүдәләндерүдә мәгърифәт, тәрбия, әхлак мәсьәләләренә һәм иҗтимагый, сәяси, милли проблемаларга йөз белән борылу, кеше, аның яшәешен тасвирлауның яңа принципларын, алымнарын үзләштерә башлау белән характерлы. Бу дәвердәге әсәрләрнең йөзен халык тормышындагы искелекне, кимчелекле якларны тәнкыйтьләү, гади кешенең тормышын сурәтләү, милли тарих, зыялы яшьләр, хатын-кыз һ.б. темалар билгеләп. XX йөз башында күтәрелгән темалар һәм образларда милли характерның ничек чагылганын шул чор әдипләре Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан,

Ш. Камал, Ә. Тангатаров, Г. Рәхим, Н. Думави, М. Гафури һ.б.ның әсәрләрендә ачык күренергә була.

Милли әдәбиятның күп гасырларга сузылган үсеш юлында егерменче-утызынчы еллар үзенчәлекле бер чор буларак аерылып тора. Моңа Февраль һәм Октябрь революцияләре, гражданнар сугышы, илне индустрияләштерү һәм күмәк хуҗалыклар оештыру кебек вакыйгалар сәбәп була. Шушы тарихи вакыйгалар белән бәйле ул чорны, үткән һәм бүгенге белән чагыштыру аша, тулырак күрсәтү омтылышы көчәя. «Бу елларда әсәрләрдә сугыш эпизодларын җанлы итеп, чынбарлыктагыча сурәтләү, вакыйгаларның үзгәрешен бирә белү, каһарманнарның эчке дөньясына үтеп керү сәләте әсир итә» [Галиуллин, б. 28]. Милли характер сыйфатлары чынбарлыктагы яңа күренешләргә, вакыйгаларга һәм шул вакыйгаларда актив роль уйнаучы геройларда сурәтләнә. Колхоз алдынгысы, сыйнфый дошманнар белән аяусыз көрәшүче, түбәннән күтәрелгән әлеге каһарман әдәбиятның умыртка баганасына әйләнә. Ш. Усманов, К. Нәҗми, М. Максуд, А. Шамов һ.б. язучыларның һәрберсе үзенчә итеп тормыштагы яңа кешеләрне, аларның азатлык һәм бәхет өчен көрәшен, иҗтимагый һәм әхлакый мөнәсәбәтләрен тасвирлыйлар.

Кайбер язучылар милли характер сыйфатларын тарихи вакыйгалар белән бәйләнештә күрсәтүче әсәрләрендә вакыйгаларны киң планда алып, сюжет үсешендә төрле социаль катлау вәкилләренең, күп персонажларның язмышын үзара тыгыз бәйләнешкә кертеп сурәтләсә, икенчеләре аерым бер геройның характеры формалашуын күрсәтүне максат итеп ала.

Егерменче-утызынчы еллар әсәрләре үзләренең революцион-героик пафослары, искелек белән килешмәүчән сугышчан рухлы геройлары, әдипләрнең гражданлык позицияләренең ачыклыгы һәм принципиальлеге, идеалларына тугрылыгы белән җәлеп итәләр. Ул елларда татар тарихи прозасында революция һәм гражданнар сугышы героикасы төп тема булган әсәрләр зур урын ала. Моны Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» (1920), К. Нәҗминең «Иң соңгысы» (1925), «Боерык» (1927), «Үзебезнекеләр» (1928), Ш. Усмановның «Легион юлы» (1923), Г. Кутуйның «Кайнар көннәр» (1924), А. Шамовның «Днепр буенда» (1927), М. Галәүнең «Болганчык еллар» (1929), «Мөһаҗирләр» (1934), Г. Бәшировның «Сиваш» (1937) әсәрләрендә ачык күренергә була.

Егерменче-утызынчы елларда милли характерны тасвирлау татар халкының иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади яшәү шартларында һәм рухи дөньясында туган үзгәрешләр белән үзенчәлекле. Моңа Февраль һәм Октябрь революцияләре, гражданнар сугышы, илне индустриальләштерү һәм күмәк хуҗалыклар оештыру кебек вакыйгалар сәбәп булып тора. Г. Бәширов, А. Шамов, К. Нәҗми, М. Әмир, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, М. Галәү, Ш. Усманов, Г. Гали,

Г. Толымбай һ.б. язучыларның әсәрләрендә милли характерны сурәтләү яңа кеше, яңа әхлакый сыйфатлар, шәхси теләкләр һәм иҗтимагый кызыксынулар берлеге проблемалары, тормышны революцион үзгәртеп коруга җанын-тәнен багышлаган аңлы көрәшче образы аша ачыла. Милли характер чагылышы гади тормыш-көнкүреш эпизодларында гына ачылып калмыйча, катлаулы иҗтимагый-сәяси вакыйгалар эчендә сурәтләнеп, аерым шәхесләрнең язмышы халык язмышы белән бәйләп күрсәтелә.

Бу чорда милли характер чагылышы, этнографик тасвирлаулардан киң эпик гомумиләштерүләргә күчү, характерларны гади тормыш-көнкүреш эпизодларында гына ачу белән чикләнеп калмыйча, аерым шәхесләрнең язмышын катлаулы иҗтимагый-сәяси вакыйгалар эчендә, халык язмышы белән бәйләп сурәтләүдә күзәтелә. Татар әдипләре үз иҗатларында, конкрет җирлектәге милли темалар күтәрүдән тыш, совет әдәбиятына хас уртак проблемаларны да яктырталар. Бу татар әдәбиятының үз милли йөзен югалтуга, аны ярлыландыруга китерми, ә рухи милли традицияләрне яңа җирлектә үстерүгә, аларны баетырга ярдәм итә.

Татар совет әдәбиятында Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар тарихы илебез тормышындагы зур вакыйгалар белән аерылгысыз бәйләнә. Сугыш елларындагы әдәбият совет халкының әхлакый-сәяси бердәмлеген ныгытуга, аны патриотик рухта тәрбияләүгә, Бөек Җиңүгә өндәүгә хезмәт итә [Татар әдәбияты..., б. 118]. Әлеге чорда сурәтләнгән герой – утларсулар кичкән совет солдаты – Ватан язмышы өчен соңгы тамчы канын да кызганмаган каһарман. Бу еллар әсәрләрендә тыныч хезмәттән фронтка җибәрелгән совет кешесенең батырлыгы һәм патриотизмы, аның гуманистик сыйфатлары нәкъ шундый герой образларында сурәтләнә.

Сугыштан соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләрдә халыкның милли характер сыйфатлары Бөек Ватан сугышы елларындагы каһарманлыгы, ил хуҗалыгын аякка бастыру, тыныч тормыш чорындагы фидакарь хезмәте кебек гамәлләре аша ачыла [Татар әдәбияты..., б. 297]. Ул чор әдипләре Бөек Ватан сугышына икенчерәк биеклектән күз ташлап, аның дөньякүләм тарихи әһәмиятен тагын да тирәнрәк ачып, совет халкының фидакарьлеген, совет сугышчысының батырлыгын киңрәк яктыртып, кешеләрдә сугыш фаҗигаләрен оныттырмау максатын алга куеп иҗат итәләр. Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы елларда язылган әсәрләрдә милли характер сурәтләнеше халыкның әхлакый-сәяси бердәмлеген ныгытуга, аны патриотик рухта тәрбияләүгә хезмәт итә, гуманлылык, кешелеклелек, батырлык, горурлык, туган илгә, Ватанга мәхәббәт кебек милли сыйфатлар аша яктыртыла.

Бөек Ватан сугышының зур җиңү белән тәмамлануы совет халкының патриотик һәм милли горурлык хисләренең яңа күтәрелешенә китерә. Милли характер сыйфатлары К. Нәҗминең «Язгы

җилләр» (1948), И. Газинең «Онытылмас еллар» (1949–1966), Ә. Фәйзинең «Тукай» (1952), Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы» (1958) кебек революцион хәрәкәтләр чорына, революцион көрәш тарихына һәм тарихи шәхескә багышланган әсәрләрдә сурәтләнә. Милли характер сыйфатларын заманча һәм тарихи вакыйгаларга бәйләнешле ачу язучыларның ул елларда тарихи темага, тарихи шәхесләрне гәүдәләндерүгә игътибары арту, аларның тарихны тагын да тирәнрәк аңлауга булган омтылышлары, тарихи үткәнгә хөрмәт белән караулары һәм тарихны бүгенге көнгә якынайтырга, хәзерге әхлакый-иҗтимагый бурычларны чишәргә хезмәт итәргә тырышуларында күренә.

Татар әдәбиятында милли характер чагылышы борынгы төрки чыганакларда, урта гасыр әдәбиятында, төрле характердагы язма чыганакларда һәм фольклор әсәрләрдә, XIX йөз дини-әхлакый, суфичыл, мәгърифәтче әдипләр әсәрләрендә, XX йөзнең беренче яртысында милләт яшәеше өчен әһәмиятле мәсьәләләрне күтәргән язучылар хезмәтләрендә яңгыраш таба. Язучыларның бу чор-дәверләрдә тарихи прозага мөрәҗәгать итүләре милли характер сыйфатларының чагылышында булган үзгәрешләрне, заман куйган мәсьәләләрне сәнгатьчә актырту максаты белән билгеләнә.

**Әдәбият**

*Әмирхан Ф.* Сайланма әсәрләр: 2 томда. Т. 2. Казан: Таткнигоиздат, 1958. 614 б.

*Галиуллин Т.* Шәхесләрне гасырлар тудыра: әдәби тәнкыйть, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 192 б.

*Мусин Ф.* Чор белән аваздаш: әдәбият фәне һәм тәнкыйть мәкаләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 240 б.

Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. V т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 544 б.

***Сафина Алия Мәгъсүм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге*
*фәнни хезмәткәре*

2018 елда әдәби җәмәгатьчелек күренекле кыргыз һәм рус язучысы, Кыргызстан ССРның халык язучысы, Кыргызстан Фәннәр академиясе хакыйкый әгъзасы Чыңгыз Төрекул улы Айтматовның (1928–2008) тууына 90 еллык юбилей датасын билгеләп үтте.

Әлеге уңайдан 2018 елның 12 декабрендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан «XX гасырның икенче яртысында милли әдәбиятлар яңарышы һәм Чыңгыз Айтматов» темасына Халыкара фәнни-гамәли конференция оештырылды. Конференциядә Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстаннан һәм Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа, Чебоксар, Казан, Саранск, Йошкар-Ола, Ижевск, Яр Чаллы һ.б. шәһәрләрдән килгән галимнәр катнашты.

Конференциядә катнашучыларга сәламләү сүзләрен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Атлас кызы Ратникова, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең вице-президенты, филология фәннәре докторы, профессор Дания Фатих кызы Заһидуллина, шагыйрь, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Әймәт җиткерде.

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы Ким Мөгаллим улы Миңнуллин үзенең чыгышында әлеге конференциянең Казанда уздырылуның очраклы булмавын ассызыклады. Чөнки Чыңгыз Айтматов – ике тугандаш халык улы, аны Татарстан җире белән нәсел җепләре, шәҗәрәсе, ата-бабаларының язмышы һәм эшләре бәйли.

Конференциянең озак еллар бер ил эчендә яшәгән төрки халыкларның чикләр, төрле әлифбалар белән бүленгән, шул ук вакытта уртак тарихи һәм мәдәни тамырларын аңлаган бер чорда үтүе игътибарга лаек. Соңгы елларда татарлар, кыргызлар, казакълар, азәрбайҗаннар һәм башка төрки халыклар арасындагы багланышлар ныгыды, тагын да алга китте, бүгенге чара да галимнәр алдында яңа мөмкинлекләр ачар дип ышаныч белдерде Ким Миңнуллин.

Конференциядә укылган докладларда XX гасырның икенче яртысында милли әдәбиятларда чынбарлыкны чагылдыру юлларын эзләү, XX гасырның икенче яртысында милли әдәбиятлар тарихы: гомумилек һәм үзенчәлекләр, Ч. Айтматов иҗатының Россиянең милли әдәбиятларында чагылышы, Ч. Айтматовның Идел–Урал әдәби җирлегендә Ч. Айтматов иҗаты, Ч. Айтматов һәм милли сәнгать, Ч. Айтматов иҗатын мәктәптә һәм югары уку йортында өйрәнүнең актуаль мәсьәләләре кебек сораулар чагылыш тапты.

Секция утырышларында «Чыңгыз Айтматовның әдәби, публицистик һәм эпистоляр мирасының социаль-фәлсәфи, иҗтимагый-сәяси, эстетик һәм тел аспектлары» һәм «Россиянең мәдәни киңлегендә милли әдәбиятлар» темаларына фикер алышу оештырылды. Конференция кысаларында «Нәрсә ул милли әдәбият?» дигән темага панель дискуссия узды.

Чарага әзерлек барышында җитмешкә якын мәкаләне туплаган конференция җыентыгы нәшер ителде. Шулай ук «Фәнни Татарстан» журналының әлеге санында махсус сәхифә булдырып, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К.М. Миңнуллинның конференциядәге чыгышын тәкъдим итүне максатка ярашлы дип санадык.

УДК 821.512.145

***К.М. Миңнуллин***

# XX ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫН ӨЙРӘНҮ КОНТЕКСТЫНДА ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВ ИҖАТЫ

Деятельность Чингиза Айтматова является неотъемлемой частью культуры тюркоязычных народов, а значит, и культуры татарского народа. Творчество классика позволяет взглянуть на татарскую литературу с новых позиций, в контексте глубоких и масштабных изменений в мировой литературе.

**Ключевые слова:** Ч. Айтматов, татарская литература, гуманизм, русскоязычная литература, художественный образ.

Күренекле язучы, дипломат, философ-гуманист Чыңгыз Айтматовның тууына 90 ел тулды. Ул – бүгенге укучылар тарафыннан иң күп укыла торган язучыларның берсе. Аның әсәрләре дөньяның 176 теленә тәрҗемә ителеп, 100 млн. данәдә 650 мәртәбә басылып чыккан. Ч. Айтматов, иҗади эшчәнлеген дәүләти вазифалары белән уңышлы аралаштырып, дипломат буларак Бенилюкс илләрендә СССР һәм Россия мәнфәгатьләрен яклый. 14 ел дәвамында Франциядә, Бельгиядә, Люксембург һәм Нидерланд илләрендә Кыргызстанның илчесе була. Ул – күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче булу белән бергә, дөнья халыклары һәм континентлар арасындагы илче вазифасын да үтәгән шәхес.

Әмма Чыңгыз Айтматов, барыннан да бигрәк, язучы, дөнья әдәбияты классигы, аның иҗаты һәм милли, һәм гомумкешелек проблемаларын, кешеләр язмышын һәм дәүләтләр тарихын, җирдәге киңлекне һәм галәмне колачлый. Ул рус һәм кыргыз телләрендә яза, мәдәниятләр, халыклар, илләр һәм цивилизацияләр бердәмлеген пропагандалый, иҗади юлында гомере буена кешеләрне игелекле булырга, табигать һәм галәм белән гармониядә яшәргә, бердәмлеккә һәм гуманизмга өнди.

Ул безгә тугандаш татар һәм кыргыз халыклары улы буларак та кадерле. Аның иҗаты төрки телле халыклар мәдәниятенең, димәк, татар халкының да, аерылгысыз бер өлешен тәшкил итә. Әдипнең әсәрләрендә төрки халыкларның көнкүреше һәм милли проблемалар аеруча тирән яктыртыла. Ул гәүдәләндергән кабатланмас әдәби образлар төрки халыкларның тормышын һәм яшәешен генә түгел, дөньяга карашын, менталитетын, тиңдәшсез мәдәниятен дә чагылдыра.

Казанда, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Чыңгыз Айтматовның 90 еллыгына багышланган конференция уздыру тирән символик мәгънәгә ия, чөнки ул нәсел тамырлары, шәҗәрәсе, бабаларының күп буыннары, аларның каберләре,

аларның язмышына бәйле хатирәләр белән дә Татарстан җиренә килеп тоташа. Конференциянең әһәмияте тагын шунда, ул озак еллар дәвамында бер ил булып яшәгән төрки телле халыкларның чикләре, алфавитлары аерымлануга карамастан, үзләренең тарихи һәм мәдәни тамырларын әле хәзер дә уртак дип танулары шартларында уза. Татарлар, кыргызлар, казакълар, азәрбайҗаннар һәм башка төрки халыклар арасындагы үзара мөнәсәбәтләр соңгы елларда тагын да җылына төште, тарихи язмышларыбыз һәм бүгенге мәдәни казанышларыбыз уртаклыгын тирәнрәк аңлый башладык, дип зур ышаныч белән әйтә алабыз.

Ч. Айтматов иҗаты шушы бердәмлекне тагын да көчәйтүче бер күренеш буларак кабул ителә, ул безгә данлы төрки эпосның, төрки мифологиянең мәңгелеген, табигать белән гармониядә яшәү зарурлыгы хакындагы әхлакый кануннарны чагылдырган Найман-Ана, Ак бүре яки кола бия Гөлсарыны бүген дә хәтердә яңарта, рухи ныклыгыбыз һәм безгә кадәрге буыннар нигезләгән кыйммәтләребез һәм традицияләребез сагында тора.

Ч.Айтматов тарафыннан тудырылган дөнья сурәте татарларга үзләренең хайваннар дөньясы белән бердәмлектә яшәгән дәверләрен хәтерләтә. Мәсәлән «Бәхил бул, Гөлсары» повестенда Танабай Бакасов белән аның юргасы Гөлсары, «Гасырдан да озын көн» романында Идегәй Жангельдин белән Каранар-дөя, «Ахырзаман» да Авдий белән Акбар образлары аша кеше белән хайван арасында параллельлекләр уздырып, язучы кешенең асылы, аның психологиясе, киләчәк язмышы турында уйланырга мәҗбүр итә. «Ахырзаман», «Гасырдан да озын көн» әсәрләрендә кеше гармонияле һәм бербөтен табигый дөньяга, гомумән галәмгә каршы баручы җимергеч көч итеп тасвирлана.

Ч. Айтматовның фикер һәм концепцияләрен, кичерешләрен без күңелебезгә якын кабул итәбез, алар безнең уй-карашларыбызга аваздаш. Шул ук вакытта аның күп кенә мотивлары татар әдәбиятына, бигрәк тә тарихи ядкарьләребез проблемасына кагылган әсәрләргә, аеруча якын тора. «Гасырдан да озын көн» романында вакыйга чиксезлеккә җәелгән «Сары Үзәк» даласында тимер юл магистрале буена урнашкан авылда бара. Дала уртасында калган кешелек һәм мөселман кардәшлеге утравы, аз кешеле һәм сусыз бер карыш җир – туган җир, туган ил, йөрәккә иң кадерле урын. Биредә кешеләр бер-берсенә ышаналар һәм теләсә кайчан үзара ярдәмгә әзерләр. Идегәй дә мәрхүмнең соңгы ихтыярын үтәргә – аны үз ыруглары зираты – Ана-Бәйиткә җирләргә карар кыла. Язучы кеч-кенә Боранлыдагы яшәеш белән бөтен ил тормышын янәшә куеп чагыштыра.

Мондый чагыштыру романның төп проблемасын – хәтер проблемасын ил масштабына күчерергә мөмкинлек бирә. Маңкортлар турындагы риваять татар аңында Гаяз Исхакыйның «Локман Хәким» хикәясенең

нигезен тәшкил иткән гыйбрәтле хәл белән ассоциацияләшә. Г. Исхакый Аллаһ тарафыннан кешеләрне акылдан яздыра торган агулы яңгыр яудырып, котычкыч кичерешләргә дучар ителгән бер халыкның үткәне хакында бәян итә. Айтматовтагы дөя тиресе кебек, агулы су да бу очракта бөтен халыкны тарихи хәтерен югалткан, шуның нәтиҗәсендә әхлакый юнәлешләрен җуйган кешеләргә әверелдерә. Г. Исхакыйда проблема тоталитар системаның төп механизмнары рухындагы социаль-сәяси яссылыкта күтәрелсә, Ч. Айтматовта ул милли тәңгәллекне, телне һәм мәдәниятне югалту куркынычы тудырган фәлсәфи кануннар сферасында яктыртыла.

Ч. Айтматовның баштагы чор иҗатындагы сюжет һәм образлары Ә. Еники, М. Мәһдиев, Г. Бәширов һәм башка татар язучыларыныкына якын корылган. Чыңгыз Айтматов та, Әмирхан Еники кебек үк, милли проблемаларны кискен күтәрә; үз туган җирен һәм халкын Мөхәммәт Мәһдиев кебек мифлаштыра; Гомәр Бәширов кебек үз ыруының, милләтенең үткәнен шигъри аһәңгә сала.

1960–1980 елларда татар әдәбиятында прозада гына түгел, драматургиядә дә яшь буынны игелеккә өйрәтүче Дюйшенны хәтерләткән укытучы образы еш гәүдәләндерелә. Моңа охшаш мотивлар бүгенге язучыларыбыз әсәрләрендә дә кабатлана. Мәсәлән, Ч. Айтматовның «Бәхил бул, Гөлсары» повестындагы (1966) ат – Гөлсары Танабай өчен якын дус һәм йөгәнсезлек, иреккә омтылучы символын тәшкил итә, һәм бу сыйфатлар совет идеологиясенең гомум буйсындырылуына корылган төп механизмына каршы юнәлдерелә. В. Имамовның «Могикан» повестенда исә бу мотив соңгы дәвергә күчерелә, әсәр герое Вәлит белән ат – Могикан да бер-берсенең азатлыкка, иреккә омтылышларын куәтлиләр, әмма аларның икесенең дә үлеме ул өметләрнең тормышка ашмавын чагылдыра.

Төрки мәдәнияттә хөкем сөргән тәңречелек идеяләре белән бүгенге татар язучылары да мавыга, ә Ч. Айтматов иҗатында бу тема намус, гаделлелек, игелеклелек аспектында чагылыш таба. Ул кеше белән табигатьнең бердәмлеге, Җирдәге һәр тереклек иясенең үзара мөнәсәбәтләре хакындагы уртак кануннарны, алар бозылган очракта кешеләрнең нәсел тамырлары, милли тәңгәллеге генә югалып калмыйча, ә бөтен Җир йөзендә тәртип тармар ителәчәген тавсвирлый. Бу хакта бүгенге татар прозаиклары да язалар. Найман-Ана, Идегәй һәм Нуриәсма (Фоат Садриевның «Таң җиле» романы) арасындагы параллельлекләр дә шуны раслый. Мондый янәшәлекләрне Ана образы, туган җир, туганлык бәйләнешләре калку бирелгән Ч. Айтматов әсәрләре һәм татар шагыйрьләре иҗаты үрнәгендә күпләп уздырырга мөмкин.

Ч. Айтматов иҗатына хас төп үзенчәлекләрнең берсе – 1960–1980 еллар татар прозасындагы кебек үк, лиризм, хикәяләүнең музыкаль-хисси аһәңлелеге. Ул тышкы дөньяны тасвирлауда күзәтелә. Прозаны лиризм,

шигъри рух белән сугару әсәрне ритмлаштыру, халык җырлары һәм музыка кораллары яңгырашын оста сурәтләү, символлаштыру һәм ассоциативлыкка ирешү ысуллары ярдәмендә гамәлгә ашырыла. Мондый типтагы уртаклык шул чор төрки телле әдәбиятларда барган процессларның охшашлыгын дәлилли.

Ч. Айтматов иҗатының тагын бер үзенчәлеге – аның һәр әсәрендә диярлек мифологизм чагылыш таба. Әдипнең башлангыч чор иҗатында төрки фольклор өстенлек алса да, ул алар белән генә чикләнми. Мәсәлән, «Бәхил бул, Гөлсары» повестындагы «Ана дөя елавы», «Ак пароход»та мөгезле Ана-болан турындагы әкият кебек кыргыз фольклорына, «Гасырдан да озын көн» романындагы манкорт турында риваять казакъ халык иҗатына нигезләнгән. Ә соңгырак романнарындагы мифологик күренешләр Көнчыгыш һәм Көнбатыштагы уртак этник тамырлары булмаган халыклар мәдәнияте кисешкән чорга карый. 1980 еллар ахырыннан башлап, төрле халыклар мифологик системасының мондый синтезы татар әдәбиятында да чагылыш таба.

Димәк, Ч. Айтматов иҗаты белән татар әдәбияты киңкырлы уртаклыкларга ия. Классик язучы иҗаты татар әдәбиятына яңа позициядән, дөнья әдәбиятындагы тирән һәм киң масштаблы үзгәрешләр контекстыннан карарга ярдәм итә. Казанда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан әдипне зурлап халыкара фәнни-гамәли конференция уздыру шуның белән аңлатыла. Ч. Айтматовның иҗади индивидуальлеге гомум татар әдәбиятының сәнгати-эстетик табигатенә төшенүдә дә зур роль уйный. Нәкъ менә хәзер, төрки халыкларның уртак мәдәни-тарихи тамырларын эзләү аеруча актуальләшкән, татар әдәбиятының тарихи үсешен дөнья әдәбияты контекстыннан чыгып бәяләгән заманда Ч. Айтматов үзебезнең әдәби мирасыбызны саклау зарурлыгы, аны дөньякүләм һәм гомумтөрки казанышлар белән бәйләп баету хакында искәртеп тора.

***Миңнуллин Ким Мөгаллим улы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры*

УДК 398.34

*Г.М. Сөнгатов*

# ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕНДӘ ЙОРТ ХАЙВАННАРЫ ОБРАЗЛАРЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ

Статья посвящена изучению употребления образов домашних животных в татарских народных сказках. Выявлено, что образы домашних животных используются во всех видах сказок и играют существенную роль в формировании идейно-художественных и эстетических особенностей произведений. Животным придаются присущие людям положительные и отрицательные качества добра или зла. В статье также приводятся примеры употребления диалектных лексических и фонетических вариантов названий домашних животных.

**Ключевые слова.** Народная сказка, образы животных, эстетическая функция.

Галимнәр әкиятләрне борынгы кешеләрнең дөньяны мифологик күзаллауларга нигезләнеп аңлаулары кимү һәм акрынлап җуела бару чорында туа башлаган дип күрсәтәләр. Шулай да борынгы ыруглык җәмгыятеннән бирле килгән мондый ышануларның эзләре тылсымлы әкиятләрдә чагылыш табып, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән [Бакиров, б.26]

Татар халык әкиятләре составында хайваннар турындагы әкиятләрнең саны бик аз, аларның да шактый өлешенең төп персонажлары кыргый җәнлекләр яки кошлар була. Әмма йорт хайваннары башка төр әкиятләрдә дә әсәрләр сюжетында тулаем яки эпизодик рәвештә шактый зур роль уйныйлар. Хайваннар турындагы әкиятләргә конкрет якын килсәк, алар кешелек тарихының башлангыч чорына, әле кеше табигатьтән аерылгысыз яшәгән борынгы ыруглык җәмгыятенә үк барып тоташа. «Хайваннар турындагы әкиятләр әкият жанрының гына түгел, бәлки гомумән фольклорның иң борынгы күренешләренән санала» [Ярми, Җамалетдинов, б. 14].

Борынгы кеше тормышяшәешен әйләнә-тирә мохитнең аерылгысыз өлеше итеп санаган, үзен хайваннар белән тыгыз бәйләнештә күргән. Билгеле булганча, күп кенә ыруглар үзләрен билгеле бер җәнлектән килеп чыккан дип ышанганнар, аны изгеләштергәннәр, ул кагылгысыз саналган. Тотемизм дип атала торган әлеге ышану-йолалар төрки халыкларның рухи тормышында һәм көндәлек эшчәнлегендә зур урын алып торган. Шул ук вакытта, тотемны (йорт хайваннарыннан – ат, үгез, сарык тәкәсе һәм кошларыннан – каз, үрдәк, тавык) корбан итеп чалу, аның итен авыз итеп карау төрки халыкларның традицион мәдәниятенә хас күренеш булган. Атның яки кошларның баш сөякләрен йорт түбәләренә куя торган булганнар. Кешенең хайваннар белән тыгыз мөнәсәбәте башта

төрле хикәяләр тууына китергән, соңрак шулар нигезендә әкиятләр барлыкка килгән [Ярми, Җамалетдинов, б. 15]. Кешенең үзенә хас сыйфатларны хайваннарга күчерүе «Аю улы Атыләхмәтгәрәй», «Аю белән хатын» кебек әкиятләрдә сакланып калган [Бакиров, б. 127].

Без әлеге мәкаләдә татар халык әкиятләрендә йорт хайваннары персонажларының кулланылышын һәм аларның әсәрләрдәге ролен, башкарган функцияләрен, һәрберсенә хас сыйфатларны күзәтеп чыгарбыз. Мисаллар «Татар халык иҗаты» китабының 1 нче, 2 нче, 3 нче томнарыннан алынды [Татар халык иҗаты. Әкиятләр...].

Хайваннар турындагы әкиятләрнең исемнәрендә йорт хайваннары атамалары «Кәҗә белән Бүре» һәм «Кәҗә белән Сарык» әкиятләрендә чагылыш таба. Тылсымлы әкиятләрнең шулай ук икесендә генә йорт хайваннарының исемнәре баш исемдә кулланылган. Болар – «Йөз куйга сатып алынган төш» һәм «Сыер булган» исемле әкиятләр.

Ат (айгыр, бия), сыер, үгез, кәҗә, сарык, тәкә персонажлары хайваннар турындагы әкиятләрдә шактый киң урын алган. «Татар халык иҗаты» җыентыгының беренче китабында «Салам-Торхан» исемле әкиятнең ике варианты китерелгән. Беренчесендә патша кызына өйләнергә килешкәндә Салам-Торхан мәһәргә биш айгыр, ике йөз салам шәһәре бирергә була, ат та, башка хайваннар да анда телгә алынмый. Икенче әкияттә, киресенчә, кәләшнең бай атасы «миңа берни дә кирәкми» дип, мәһәрдән баш тарта. Салам-Торханның дусты – төлке, атларының бик зур, арбаларының бик авыр булуын сәбәп итеп, үзләре үтәсе күперләрне ныгытырга куша. Туйлар үтеп, кызның бай аталары кунакка килгәндә, аларга, алдан төлке сөйләшеп куйганча, ат, сыер һәм сарык көтүләренең барысын да Салам-Торханныкы дип әйтәләр. Шулай итеп, әлеге әкиятләрдә йорт хайваннары персонаж буларак катнашмыйлар, төп геройның байлык дәрәҗәсен күрсәтү кирәк булганда гына телгә алыналар.

«Шәрә Бүре» әкиятендә бүре белән аралашкан хайваннарның берсе – айгыр образы. Айгыр көчле генә түгел, аңлы, хәйләкәр һәм тәвәккәл хайван булып күз алдына килеп баса. Ул бүрегә койрыгындагы алтын кылны алырга куша. Әкият эчтәлегендәге нәтиҗә мондый: «*Айгыр кушаяклап Бүрегә тибеп җибәргән. Бүре әйләнә-әйләнә барып төшкән, ә Айгыр авылга торып чапкан».*

Тылсымлы әкиятләргә килсәк, «Алтын кош» исемле әкияттә татар халкы элек-электән асраган өч йорт хайваны – ат, сыер һәм кәҗә төп геройның кылган гамәлләрендә эш башкару объекты буларак урын алганнар. Уңган-булган кече кияүне хурлыкка калдыру өчен, олы кияүләре патшага аның тылсымлы эш башкара алуын әйтә. Ул йөз баш атны алтын тояклы, көмеш йонлыга, йөз баш сыерны алтын мөгезле, чылбыр койрыклыга һәм йөз баш кәҗәне алтын мөгезле, көмеш йонлыга әйләндерә ала, дип

ялганлый. Әсәр герое боларның барысын да бер-бер артлы җиңел генә башкарып чыга, нәтиҗәдә зур дәрәҗәләргә ирешә. Хайваннар турындагы әкиятләрдәге кебек үк, биредә дә йорт хайваннары үзләре турыдан-туры персонажролендә катнашмыйлар.

«Незнай» исемле әкияттә атлар токымнары һәм төсләре буенча аерымлана: малаена әтисе беренче көнне тимер күк атның койрыгы белән ялын бирә, икенче көнне – акбүз атныкын, соңыннан кара атның койрыгы белән ялын биреп җибәрә. «Алтын кош» әкиятендә атлар дирбияләре белән дә (*көмеш йөгәнле, алтын иярле бер бик сылу акбүз ат; алтын йөгәнле, җәүһәр-якут ташлар белән бизәлгән иярле*), гәүдә зурлыклары белән дә аерылып торалар. Патша үзенең киявенә кызы аша болай дип әйттерә: «*Син кияүгә әйт, ди, әнә минем абзардан алты колачлы ала бияга атланып, иртәгә ул да сугышка чыгып карасын әле, ди, берәр файдасы тимәсме икән, ди*».

Тылсымлы әкиятләрнең төп үзенчәлекләреннән берсе буларак, аларда хайваннар кеше телендә сөйләшә ала. Мәсәлән, «Көтүче малай» әкиятендә патша малае бик күп яхшы тайлар арасыннан сайлап алган корчаңгы, бетле тай, яхшылап тәрбияләгәч, бик затлы хайванга әверелә һәм малай белән кешечә сөйләшә дә башлый. Җитмәсә, үзе кешеләрнең ни уйлаганын һәм нәрсә эшләргә җыенганнарын да белеп тора. Малайга башта патша кияве, аннан соң үзе патша булганчы, инде үзе дә айгыр булып үсеп җиткән хайван һәрвакыт ярдәм итеп тора, авыр чакларында тылсым көче белән килеп җитеп, бәладән йолып ала. «Кучер малае»енда егет үзе бик матур атка әйләнә. Билгеле булганча, тылсымлы әкиятләргә бер җан иясеннән икенчесенә яки җансыз предметка әверелү хас. Шундый очракларның берсе «Дию патша» исемле әкияттә сурәтләнә: биредә патша, егетне үтерү өчен, өермәләр күтәреп, давыл кубарып чаба торган айгырга әверелә. Сөйләшә торган ат «Яшьлек суы» исемле әкияттә дә бар, әмма ул биредә хуҗа көтүендә йөри торган йорт хайваны гына түгел, «кыр аты», ягъни кыргый ат. «Алтынбай» әкиятендә айгыр телгә дә килә, егет аны суйдыра, әмма өстенә зәмзәм суы сипкәч, яңадан терелә дә.

Галимнәр билгеләвенчә, көнкүреш әкиятләре реаль чынбарлыкка бик якын торулары белән характерланалар [Җамалетдинов, б. 5]. «Зирәк карт» исемле әкияттә атларның халык күзәткән холкы-фигыле сурәтләнә: яшь айгыр ерактан ук тузгып, уйнаклап килә, карт айгыр исә башын иеп, юл биреп кала. «Фикерле кыз» әкиятендә бия колынлагач, колынның кемнеке булуы хакында өч хәерче арасында бәхәс чыгу очрагы сурәтләнә. Арба белән капчыкның да канга буялуын күреп, аларның хуҗалары да колынга дәгъва кылалар. Инде патша хатыны булган фикерле кыз үзенең зирәк акылы белән әлеге бәхәсне бия хуҗасы файдасына хәл итә.

«Өч икмәк» исемле әкияттә патшаның очып йөри торган дип саналган кара байталының начар

ат икәнлеген зирәк карт фаш итә. Ул алтыннар белән бизәлгән атны суга кертергә куша һәм патшага *«ишәктән дә начар ат бу»,* – ди. *«Нигә начар минем ат»?* – дип сорагач, *«Атың суга кергәч, суны эчүдән элек хаҗәтен үтәде... Яхшы ат булса, алай итми ул»,* – дип җаваплый. Яхшы чаба торган айгыр «Яшь чак, таза чак» исемле юмористик әкияттә *яхшы айгыр* дип кенә сурәтләнсә, «Хезмәтче һәм бай» әкиятендә *җилле* сыйфаты белән бәяләнә: «Бу байның *бик җилле кара айгыры* булган». «Күке кычкыргач, көтүче хезмәт хакы ала» исемле сатирик әкияттә атлар түбәндәгечә сурәтләнә:» «*Атсабар кич белән атларын күрсәткән, ди. Алар бары да симезләр, усаллар, кап-каралар икән, үзләре һаман бер-берсе белән тибешеп кенә торалар икән, ди*». «Ике әйттермә» исемле юмористик әкияттә начар ат исә түбәндәгечә бәяләнә: «*Хатипның бары-югы бер бик арык, бик карт аты була».*

Юмористик әкиятләрдә *кашка ат* [«Юаш кияү»] кебек сүзтезмәләр белән атларны төс буенча сыйфатлау да урын алган. Шул ук әкияттә халык теленә хас булган җор сүзләр дә кулланыла: *«Ат итеннән аш пешереп, өстәл янына ашарга утырылар болар. Бабай кияүдән көлеп:*

*– Аша картасын, чанасын үзең тартасың, – ди.*

*Аңа каршы кияү:*

*– Бабай, аша итен, атсыз калуы читен, – ди».*

Әкиятләрдә *ат* һәм *тай* сүзләренең шул ук мәгънәдә кулланылган төрдәшләре дә очрый. Әйтик, «Өч бәңхур» әкиятендә персонаж телендә түбәндәге өзек бар: «*...елкы* алырмын, ул *елкы колыннар* табар».

Хайваннар турындагы «Дус киекләр» исемле әкияттә Сыер образы бирелә. Аннан *«Яхшылыкка усаллык кирәкме?»* – дип сорагач, Сыер *«Усаллык кирәк»,* – дигән. Фикеренә ул шундый дәлил китергән: «*Мине хуҗам алганга ундүрт ел, дигән, унике бозау бозауладым, дигән. Быел бозаудан калдым, мине кырга җибәрде, дигән. Симерсә суярмын, симермәсә сатармын, диеп әйткән. Мине сатты, бер атнадан мал суючы килеп ала».* Нәтиҗәдә сыер, гомер буе туендырган кешеләрнең яхшылыкка яманлык белән җавап биргәннәрен үз башыннан кичергәннән соң, усаллык белән үч алырга әзер торучы образ буларак гәүдәләнә. «Таз – патша кияве» исемле тылсымлы әкияттә алты имчәкле сыер телгә алына. Ул Тазның атасыннан калган көтүендә булган икән. Патша авырый башлагач, профессорлар аңа: «*Алты имчәкле сыер сөтен имсәң, терелерсең»,* – диләр. Чыннан да, шуны табып алып кайтып эчергәч, патша савыга.

Татар фольклорында кара сыерны, кара тавыкны корбанга чалу очраклары ят күренеш түгел. «Саран белән юмарт» әкиятендә Юмарт яшеренеп кенә сукыр җен сөйләгәнне тыңлап тора: өч ел кысыр калган кара сыерны суеп, бар халыкны сыйласалар гына җен сихерләгән хан кызы тереләчәк икән. Моны патшага сөйләгәч, шулай эшлиләр һәм хан кызы бик тиз савыга да. «Мулла белән мужик» исемле

әкияттә сыер хуҗалыкның төп азык чыганакларының берсе генә түгел, ул әле авыл кешесенең мөлкәтен ун тапкыр арттырырга да ярдәм итә – мулланың ун сыерын үз йортына ияртеп кайта. Ә аларны сыер хуҗасы, мулла *«кем дә кем ил имамына нәрсә дә булса сәдака итеп бирсә, ходай аңа ун итеп кайтарыр»,* – дип вәгазь сөйләгәч, аңа илтеп биргән була. Хәйлә һәм зирәклек нәтиҗәсендә казыйны да эшкә җигеп, мужик сыерларны үзендә калдыруга ирешә.

Халык «*сыйлы көнең – сыер*» дип, бу хайванның туклык, бәрәкәт чыганагы булуына зур бәя бирә. Ә бит сыер да хуҗасыннан яхшы тәрбия һәм игътибар көтә. «Мактанчык бай» әкиятендә сыеры картайгач, бай аны ашатмый башлый һәм сыер сөт бирүне туктата. Бай аны чыгарып җибәрә. Кырда үзенә-үзе азык табып ашап йөргән малны авылның бер ярлы карты тотып алып кайта һәм яхшылап ашата, тәрбияли һәм сыер чиләк-чиләк сөт бирә башлый. Моны ишеткән бай яңадан хайванның хуҗасы булуына дәгъва кылса да, бәхәстә җиңеп чыга алмый.

Сатирик әкитләр арасыннан «Кемгә читенрәк?» исемле әкияттә бозау нәрсә күрсә, кайда барса да, аударып-җимереп йөри торган хайван итеп сурәтләнә: «*Ир тышта арлы-бирле маташканн арада, өйгә бозау керә дә камыр кисмәген аудара. Камыр түгелә, бозау ялый бирә. Төяргә хәзерләнгән ярма да буш калмый, бозау аңар да җитешә»*.

Әкиятләрдә Үгез образы да күптөрле сыйфатлары белән гәүдәләндерелә. «Шәрә Бүре» әкиятендәге төп геройларның берсе булган үгез, бүре «*мин сине ашыйм*» дип килгәч, һич тә каушап калмый, бары колагындагы алтын сәгатьне генә, әрәм булмасын дип, алып куярга куша. Бүре якын килә башлуга, мөгезләре белән эләктереп, аны баш аркылы чөеп кенә җибәрә. Бу вакыйгадан үгезнең шактый зиһенле, хәйләли белә торган хайван булуы күренә. «Дүрт дус» исемле әкияттә исә үгез – тупас, дуамал холыклы, хәтта усал җан иясе. Дусты мачы: «*Салкыннар җитә, әйдә өй салыйк*», – дигәч, ул: *«Мин капка төбеннән капка төбенә йөрим, нигә ул өй»,* – дип кенә җаваплаган. Инде салкыннар башлангач, үзен җылы өйгә кертмәгәннәренә ачу итеп: *«Алайса, өеңне төртеп аударам»,* – дип куркыткан.

«Шәрә Бүре» әкиятендәге кәҗә персонажына акыл һәм хәйләкәрлек хас. Ул юаш булып кылана, бүрегә *«ашасаң ашарсың»,* – ди, мескенгә салыша. Үзе, мәзин буларак азан әйтәм, дигән сәбәп белән, Муллагали исемле хуҗасына хәбәр сала һәм Бүре авызыннан исән кала. «Батыр Әтәч» исемле әкияттә исә кәҗә гел тискәре яктан гына тасвирлана: ул ялганчы – көне буе ашап йөрсә дә, бер яфрак кына ашадым, дип, кыз баланың өстенә нахак бәла яга, хәтта хуҗа үз күзләре белән күргәндә тукланганын да кире кага; куянның өенә басып кереп, анда хуҗа булып яши башлый. Аның куркыныч кыяфәте бүрене дә, аюны да куркыта, төлкенең дә өнен ала. Батыр әтәч кәҗәнең мөгезләре

арасына кунып, күзләрен чукый башлагач кына ул чыгып качарга мәҗбүр була.

«Җүләр Бүре» экиятендә исә кәҗә тәкәсе – хәйләкәр хайван. Ул «*тау өстеннән чабып төшеп, авызыңа үзем керермен*», – дип, бүрене алдый һәм бик каты сөзеп җибәрә.

Мәшһүр шагыйребез Г. Тукайның иҗаты аша бөтен татар халкында киң таралыш алган, «Татар халык иҗаты» китабында өч варианты бирелгән «Кәҗә белән Сарык» экиятенең икесендә төп персонажлар аңлы, кыенлыклар алдында югалып калмаучы хайваннар ролендә сурәтләнәләр: алар бүреләрне хәйләләп, алдап, куркытуга ирешәләр һәм аларны качарга мәҗбүр итәләр. Өченче экият башка сюжетка корылган. Кәҗә, үзенә кышын сыенып ятарга җылы кирәк булганда, сарыкка «дус булыйк» дип тәкъдим ясый, җәй көне исә аны янына да яткырмый, *«Синнән ис килә, косам мин»,* – ди. Шулай итеп, бу экияттә кәҗә – яхшылыкның кадерен белмәүче тискәре образ. Сарык исә аннан үчен ала – тагын кышлар җиткәч, Кәҗәне якын да китермичә, кар өстенә чыгып ята.

«Кәҗә белән Бүре» экиятендә исә кәҗә – акыллы, балалары турында кайгыртучы батыр җанвар. Сөйләүче аны экиятнең беренче җөмләсендә үк «дәү сакаллы, бик акыллы» дип, уңай яктан тасвирлый. Кәҗә яраткан бәтиләрен Бүре алып киткәч, ике дә уйлап тормыйча, чабып барып дошманына ташлана һәм, аның корсагын ярып җибәреп, балаларын йолып ала.

«Хәйләкәр Әтәч» экиятендә беренче карашка юаш хайван булган сарыкларны ерткыч сыйфатында – әтәчне таптап үтерү өчен файдалану омтылышы күрсәтелгән: *«Болай да булмагач, өченче көнне Әтәчне сарыклар, тәкәләр абзарына ябалар... Бүре, Әтәч эченнән чыгып, бөтен сарыкларны буып үтерә дә Әтәч эченә керә».*

«Фикерле кыз» исемле көнкүреш экиятендә сарык тәкәсе образы урын ала. Биредә патша картка мондый катлаулы бурыч йөкли: «*Ач та килмә, тук та килмә; ялангач та килмә, кием белән дә килмә; атка атланып та килмә, җәяү дә килмә*». Кызының киңәше белән карт ятьмәдән тегелгән кием кия, көнбагыш чиртә-чиртә кәҗә тәкәсенә атланып килә. Патша, бу фәкыйрь кешенең кызының бик зиһенле икәнлеген белеп, аңа бик аз гына җептән киндер сугып, күлмәк-ыштан тегәргә куша, аннан соң җиде яшьлек сарык тәкәсен биреп, *«иртәгә сәгать уникегә мин барган төшкә сарык тәкәсе бәрәнләсен»,* – дип боера. Фикерле кыз бу мәгънәсез боерыкны юкка чыгару җаен да таба: патша килгән вакытка әтисен мунчага кертә һәм патша аның кайдалыгын сорагач, *«Әткәй мунчада бәбәйләп ята»,* – дип җавап бирә. Патша җиңелүен танып кайтып китәргә мәҗбүр була.

*Сарык* белән бергә, экиятләрдә *куй* атамасы да очрый Мәсәлән, сатирик экиятләр арасыннан «Алдар», «Өч бәңхур» исемле экиятләрдә *куй* сүзе кулланыла. «Өч бәңхур» экиятендә

*бәрән* сүзенең *кузы* дигән диалекталь синонимы бар.

Йомгаклап әйткәндә, татар халык әкиятләрендә йорт хайваннары күптөрле сыйфатлары белән биреләләр, эш-гамәлләрдә күрсәтеләләр. Аларның холык-фигыльләре төрле ситуацияләрдә ачыла. Әкият осталары хайваннарны кешегә хас сыйфатлар белән дә тулыландырганнар (мәсәлән, кеше телендә сөйләшү), аларга тылсымчы функцияләрен дә йөкләгәннәр. Нәтиҗәдә, хайваннар безнең күз алдыбызга җанлы, тормышчан образлар булып килеп баса. Мисаллардан күренгәнчә, әкиятләрдә йорт хайваннары берьяклы гына сурәтләнми, алар төрле әсәрләрдә яхшы һәм тискәре яктан ачылалар. Кешегә хас булган яхшылык яки явызлык сыйфатлары – гаделлек, игелеклелек, мәрхәмәтлелек, икейөзлелек, ялагайлык, көнчелек һ.б. хайваннарга күчерелеп, әкиятнең әхлакый мәгънәсен формалаштырырга ярдәм итәләр, аңа эстетик вазифа өстиләр.

**Әдәбият**

*Бакиров М.Х.* Татарский фольклор. Казань: Ихлас. 2012. 400 с.

*Җамалетдинов Л.* Көнкүреш әкиятләре // Татар халык иҗаты. Әкиятләр, 3 нче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. Б. 5–18.

Татар халык иҗаты. Әкиятләр, 1 нче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 408 б.; 2 нче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 448 б.; 3 нче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 360 б.

*Ярми Х., Җамалетдинов Л.* Татар халык әкиятләре // Татар халык иҗаты. Әкиятләр. 1 нче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. Б. 7–26.

*Публикация осуществлена при финансовой поддержки РФФИ и Правительства Республики Татарстан в рамках научного проекта «Фольклор в системе скотоводческих традиций татар» № 17-14-16021*

*Мәкалә Россия фундаменталь тикшеренүләр фондының һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтенең финанс ярдәме белән 17-14-16021 номерлы «Татар халкының терлекчелек системасында фольклор» фәнни проекты кысаларында әзерләнде*

***Сөнгатов Гафур Мәсгуть улы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәгенең*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 398

*Г.Р. Хөсәенова*

# «ТАҺИР БЕЛӘН ЗӨҺРӘ» СЮЖЕТЛЫ ДАСТАННАР: ӨЙРӘНЕЛҮ ДӘРӘҖӘСЕ, КУЛЪЯЗМАЛАРЫ ҺӘМ СӨЙЛӘМӘ ВАРИАНТЛАРЫ

Дастан «Тахир и Зухра» является одним из прекрасных эпических памятников, многочисленные татароязычные варианты которого распространены в народе. Автор статьи поднимает вопрос об актуальности дальнейшего изучения татарской версии дастана, дает информацию о вновь найденных текстах, хранящихся в архивах научных центров Казани, обобщает задачи по изучению татарского романического эпоса.

**Ключевые слова:** дастан, «Тахир и Зухра», рукопись, татарский фольклор.

«Таһир – Зөһрә» сюжеты урта гасырлардан ук килә, аңа төрки халыклардан азәрбәйҗан, төрек, үзбәк, уйгыр, балкар, казакъ, төрекмән, башкорт, татар һ.б. халыклар, бик яратып, әллә ничә вариантта төрле күләмдәге әсәрләр иҗат иткәннәр.

Дастанның татар версиясе күп вариантлы булуы белән игътибарны җәлеп итә. Шунысы кызыклы: моннан биш-алты гасыр элек халыкның күңел кылларын тибрәткән «Таһир – Зөһрә» вакыйгасы белән бәйле дастан кулъязмалары татарлар яши торган төбәкләрдә әле безнең көннәрдә дә табылып тора. Кулъязмалар Казан фәнни үзәкләреннән Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә [Татарстан Республикасы Милли китапханәсе], Казан федераль университеты Н. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәнең сирәк китаплар һәп кулъязмалар бүлегендә [Казан федераль университеты...] һәм иң зур күпчелеге Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана [Татарстан Фәннәр академиясе..., колл. 39]. Дастанның татар телле вариантлары Идел буенда да, Себер киңлекләрендә дә киң таралган, берничә гасыр буена халыкка рухи азык ролен үтәп килгән.

Әдәбиятта һәм фольклорда әлеге дастанга аз игътибар ителгән дип әйтеп булмый. Татар версиясе турында Х. Хисмәтуллинның [Хисмәтуллин, б. 147–148], Ф. Әхмәтованың [Әхмәтова, б. 312–321] һ.б.ның аерым мәкаләләре бар. Дастанның археографик экспедицияләр вакытында табылган кайбер вариантларын галим М. Әхмәтҗанов текстологик эшкәртеп, матбугатта чыгаруга иреште [Әхмәтҗанов, 1987; 1989]. «Татар кулъязма китабы» монографиясендә дә ул дастанга шактый урын бирә, аның Сәйдинекеннән тыш вариантларын барлый, кулъязма нөсхәләрдә дастанның милли үзенчәлекләрен ачыклый,

«Таһир белән Зөһрә» хакындагы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана торган кульъязмаларга аеруча киң туктала, аларны башка халык версияләре белән чагыштырып, татар кульъязма вариантларына күзәтү ясый [Әхмәтҗанов, 2000, б. 169–179].

Филология фәннәре докторы, профессор Ф. Урманчеевның «Героический эпос татарского народа» хезмәтендә «Таһир белән Зөһрә»гә Көнчыгыш әдәбияты аша килеп кергән китаби чыгышлы дастан буларак аерым әһәмият бирелгән [Урманчеев, с. 189–194].

Филология фәннәре докторы, профессор Ф. Яхин үзенең «Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология» исемле монографиясендә Сәйяди иҗатына һәм аның «Дастаны Бабахан» әсәренә аерым бүлекчә багышлаган, әсәрдәге мифологик вакыйгалар һәм алымнарга мөнәсәбәттә Сәйяди һәм Кормаши вариантларына чагыштырма характерда махсус тукталган [Яхин, б. 185–199].

Филология фәннәре докторы Р. Исламов, дастанның балкар версиясен табып, аны матбугатка чыгарды [Исламов, б. 193–204]. Текст алдыннан бирелгән кереш сүздә галим «Таһир белән Зөһрә» сюжетлы әлеге әсәрнең төрле халыкларда таралган кульъязмалары турында бик күп чыганакларны күрсәтә, дастан версияләре хакында гаять бай мәгълүмат бирә.

Болардан тыш, филология фәннәре докторы Лилия Мөхәмәтҗанова тарафыннан дастанның күп кенә вариантлары, текстларда фольклор башлангычы һәм индивидуаль башлангыч чагылышына фәнни-теоретик якын килеп, анализланды, яңача бәяләнде [Мухаметзянова, с. 318–352].

Димәк, башка халыкларның «Таһир – Зөһрә» сюжетлы романик дастаннары янәшәсендә татар халкының да милли үзенчәлекләргә ия үз версиясе бар һәм бу һич тә бәхәс уятмый. Хәлбуки татар версиясенең барлык вариантлары да әлегәчә билгеле бер эзлеклелек белән анализланмаган, алар хакында фикер гомумиләштерелмәгән, кульъязма нөсхәләрнең барысына да тиешле теоретик игътибар бирелмәгән, әле аларның гарәп графикасында гына билгеләләре дә, кириллицада язып алынып, чагыштырма характерда өйрәнелми калган нөсхәләре дә шактый. Дастанның татар фольклорына һәм әдәбиятына йогынтысы хакында теоретик гомумиләштерүләр ясау мөһим. Татар дастаннары классификациясендә мәхәббәт дастаны буларак та «Таһир – Зөһрә» сюжетлы истәлекләр аерым әһәмияткә ия. Татар эпосы, аерым алганда мәхәббәт дастаннары дип билгеләнә торган ядкәрләр өлкәсенә кагылышлы терминнар («мәхәббәт дастаны», «романик дастан», «романик эпос» һ.б.) җәһәтеннән дә мәсьәләгә фәнни ачыклык кертү ихтыяҗы бар. Болар барысы да романик характердагы «Таһир белән Зөһрә» дастанының татар версиясе вариантларын җентекле өйрәнү өчен

мәйданның шактый киң булуын күрсәтә. Милли эпос һәм, гомумән, дөнья эпосы яссылыгында татар версиясенең үз урыны, һичшиксез, бар.

Яшь Таһир белән Зөһрәнең илаһи мәхәббәтенә багышланган сюжетның төгәл кайсы чорда барлыкка килүе билгеле түгел. Халык арасында популяр сюжетка нигезләнеп, дастанның татар-төрки телендә әүвәлге язма версиясен иҗат итүче – Сәйяди исемле шагыйрь. Сәйядигә мөнәсәбәтле әсәр борынгы гомумтөрки телдә язылган. Әмма аның кайчан иҗат ителгән булуы турында да мәгълүмат юк дәрәҗәсендә. Текстта күрсәтелгән датага нигезләнеп, күпчелек галимнәр аны урта гасырларга – 1414 елга карый дип саный. Әмма бу дата шактый бәхәсле. «Бабахан дастаны» XV йөз башына түгел, ә күпкә соңрак чорга – XVI яисә XVII йөзгә карый дигән фикерне алга сөргән фәнни караш та бар. Бу әсәр – Таһир белән Зөһрәнең мәхәббәт вакыйгаларына багышланган гаҗәеп шигъри роман, Сәйяди исемле авторның фәнгә билгеле бердәнбер әсәре. Дастанның тәүге табылган нөсхәсе Санкт-Петербургның Көнчыгышны өйрәнү институты кульязмалар бүлегендә саклана. Әсәрнең Ф. Яхин тарафыннан хәзерге әдәби телгә якынайтып эшләнгән бай эчтәлектәге тулы тексты галимнең кереш сүзе белән аерым китап булып дөнья күрде [Яхин, б. 191].

Сәйядидән соң Таһир белән Зөһрә сюжетына мөрәҗәгать итүчеләр бик күп булган, бу тема күп кенә төрки халыкларның уртак мирасына әверелгән. Әйтик, төрекмән поэзиясе классигы Молланепес (1810–1862) әлеге сюжетка классик дәрәҗәдә күләмле әсәр язган. Молланепес «Таһир белән Зөһрә»сенең рус һ.б. телләргә тәрҗемәләре дә бар [Молла-Непес].

Әлеге сюжетка әдәби вариантлар белән параллель рәвештә «Таһир белән Зөһрә»нең фольклор вариантлары да яшәгән. Алары дастанның Сәйяди версиясеннән үзгә, чорына хас халык теленә якын торалар. Татарларда мондый дастаннар шактый күп. «Таһир белән Зөһрә» дастаны халык арасында иң күп укыла, иң киң таралган әсәр булган. Бу сюжетка халыкның үз арасыннан чыккан шагыйрьләр дә мөрәҗәгать иткән. Әйтик, Казанда Әхмәт Уразаев-Кормаши (Әхмәт мелла Мөхәммәтзариф углы Уразаев-Әлкызылҗарый Әлкормаши, туган елы билгесез – 1883 елда вафат) төзегән һәм бастырып чыгарган «Таһир илә Зөһрә» дастаны – фольклор белән әдәбият арасында торган шундый әсәрләрдән. Алга таба 1872 елда шушы ук сюжетның икенче бер татар варианты текстын Санкт-Петербургта В. Радлов бастырып чыгарган, галим дастанны Себер татарларыннан язып алган [Радлов, с. 274–286].

Таһир – Зөһрә сюжетына багышланган текстлар татар халкында болар белән генә чикләнми. Халыкта кульязмалар рәвешендә йөргән, әле бүгенге көндә дә табыла торган вариантлар үзенең күләме белән дә, шигъри эшләнеше ягыннан да

Сәйяди, Кормаши, Радлов вариантларыннан күпкә үзгә. Сюжетының мөстәкыйльлеге, традицияләренең борынгылыгы һәм халыкта гаять популярлыгы җәһәтеннән алар шактый әһәмиятле чыганак булып саналалар.

Таһир – Зөһрә сюжетлы татар дастаннарының халык теленнән язып алынган бер вариантына тукталыйк. Дастан «Таһир белән Зөһрә» исеме белән теркәлгән. Бу истәлекне татар шагыйре Ш. Маннур 1940 елда Татарстанның Мамадыш районына керә торган Тулбай авылында Мәгърифә Хәмидуллинадан язып алган. Текстның оригиналы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана [Татарстан Фәннәр академиясе..., колл. 7]. Ш. Маннур әлеге вариантны фольклорчы Х. Ярми, язучы Г. Бәширов составындагы фольклор экспедициясе вакытында язып алган. Текст хәзерге татар әдәби телендә. Ул, Ф. Әхмәтова тарафыннан әзерләнеп, «Татар эпосы. Дастаннар» китабында [Татар эпосы, б. 129–132] беренче мәртәбә дөнья күрә. Тексттан мисаллар шушы чыганактан алынды.

«Борын заманда...» дип башланып китүе белән үк бу әсәр экиятне хәтерләртә. Бу вариантта Таһирның ятим бала булуы, апасы белән генә яшәве, җиде яшьтән мәктәпкә йөри башлавы һәм шул ук мәктәптә укучы Зөһрә белән туганнар кебек дуслашуы турында мәгълүмат бирелә, Зөһрәнең гади генә кыз булмыйча, шушы ил патшасының кызы булуы да әйтелә. Таһир «бик матур, бик гүзәл, бик уңган» һәм, өстәвенә, оста гармунчы икән. Патша вәзирләре моннан бик көнләшә. Көннәрдән бер көнне Таһирның Зөһрә тәрәзәсе каршына гармун уйнап килеп басуын, ә Зөһрәнең исә аста басып торган Таһирга тәрәзәдән бау төшереп, шул бау белән Таһирны үз янына алдыруын көнче гарәп күреп тора һәм моны патшага җиткерә. Таһирны сандыкка салып суга агызалар. Зөһрә елый. Гөл патшасы кызлары тарафыннан суга батудан коткарылган Таһир, үзенә бер күрүдә гашыйк булган чибәр кызларга күз дә салмыйча, «Зөһрәҗан белән вәгъдәм бар», дип, тегеләр йоклаган вакытны туры китереп, бер ак атка атланып, үз иленә кача. Кайтса, Зөһрәне икенче бер патша улына кияүгә бирергә җыенып яталар. Таһир туйга кызлар киемендәге уенчы сыйфатында керә. Зөһрә моны уйнавыннан танып ала, алар бергә качып китәләр. Боларның чыгып киткәннәрен күргән гарәп тагын барып әләкли. Таһир белән Зөһрәнең артларыннан куа чыгып, Таһирны тотып алып кайталар, бармакларын кисеп җәзалыйлар. Таһир, рәшәткәләрне җимереп чыгып кача, ерак ком сәхрәсенә китә, шунда каны агып бетеп, сусап, тилмереп үлә. Аны эзләп чыгып йөгергән Зөһрә дә, Таһирны табып, аны кочаклап үлә.

Әсәрнең ахыры бер-берсен сөйгән ике яшь кешенең үлеме белән тәмамлануга карамастан, сөйләнгән эчтәлеге, стиле, кыскалыгы, вакыйгаларның экияткә хас җыйнаклыгы, тулысынча

диярлек прозаик характерда булуы, чынбарлыкны эпик сурәтләүдән бигрәк, күбрәк уйдырмага тартым булуы белән, Ш. Маннур варианты дастан кысаларыннан чыгып, әкияткә якыная кебек. Уртак дастани сюжеттан биредә Кормаши вариантында да очрый торган сандыкка салып суга агызу мотивы, Таһирның апасы, гарәп образы, тәрәзә астына килеп җырлау эпизоды бар. Тезмә юллар ике урында гына китерелгән. Аның беренчесе – Таһирның тәрәзә төбенә килеп әйткән ике юллык җыры:

Таһирҗаның килгәндер,
Уян, Зөһрә солтаным.

Ә икенчесе исә, Таһирның үлеме турындагы хәбәрне ишеткәч, Зөһрәнең җырлаган җыры:

И татарсыз, татарсыз,
Бер-берегезгә ук атарсыз,
Базарларда ит беткәч,
Таһир итен ашарсыз.

Юлларның һәр икесе бераз гына үзгә рәвештә Кормаши вариантында да бар. Кормаши вариантында Таһирның башын чапкач акылын югалткан Зөһрәгә, сөйгәненең итен кисеп алып, аны кыздырып, алдына куялар. Моның нинди ит икәнен белеп алган Зөһрә югарыдагы мисалда китерелгән сүзләрне әйтеп җырлый. Ф. Яхин, Кормаши вариантында да очраган әлеге юллардагы «татар» сүзенә бәя биреп, бу сүзнең, Ә. Ясәви һәм С. Бакыргани шигырьләрендәгечә, динсезлекне белдерүдә кулланыла торган сүзләрнең синонимы буларак («яһүд, христиан белән беррәттән, ислам диненең дошманнары буларак») кулланылган булуы турындагы фикер әйткән иде [Яхин, б. 188]. Галимнең хаклы фикеренә кушылабыз. Бу – «татар» сүзенең этноним буларак кулланыла башлавы һәм, гомумән, аның халыкта үзэтноним булып китүе бик соң башлануга барып тоташа торган четерекле сорауларның берсе. Бәхәскә кереп тормый гына шуны төгәл әйтә алабыз: «татар» терминының бүгенге укучы аңлаганнан күпкә борынгырак мәгънәсе әсәрнең тарихи чынбарлыкны чагылдыруы, димәк, әсәр генезисының да борынгылыгы хакында сөйли, гәрчә сюжет үзе тарихилыктан читләшкән кебек кабул ителсә дә. Ш.Маннур вариантына Кормашидан шушы юлларның килеп керүе әлеге истәлекне телдән бәян итүченең элек Кормаши әсәре белән таныш булуын күрсәтә. Сөйләүче, исендә калганнарны файдаланып, сюжетны өр-яңа вариантта үзенчәлекле рәвештә әкиятләштереп сөйләп биргән. Әсәр ахырында Таһир белән Зөһрәнең каберләре читтә булып, алар арасына көнче гарәпне күмүләре, күмгәч, ике гашыйк каберенә матур гөлләр үсеп чыгуы, ә гарәп кабере өстендә үсә торган чәнечкеле таякның аларга һаман комачаулап торуы да Кормаши вариантының бетем өлешенә бик якын.

Бу варианттан тыш та «Таһир белән Зөһрә» сюжетына халыкта таралган кульязмалар шактый. Аларның күбесе әдәбиятчы-текстологлар тарафыннан эшләнеп, башка вариантлары белән чагыштырылып, матбугатта басыла килә. Әйтик, Татар-

станның хәзерге Әтнә районы Бәрәскә авылында Бикчәнтәй бине мелла Ибраһим мәдрәсәсе шәкертләре тарафыннан 1776–1801 елларда күчерелгән өч кулъязма, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фондына Марат Кильдиев тапшырган яисә Гали Рәхим кулы белән күчерелгән булуы ихтимал кулъязмалар, Яңа Мәңгәр, Ишнарат, Куакбаш, Хәсәншәех авылларында язылган кулъязмалар һ.б. күпләгән вариантлар һәркайсы – үз үзенчәлекләре булган мөстәкыйль ядкәрләр. Аларның һәркайсы XVIII йөз ахырларына нисбәт ителә, күләмнәре – 1 биттән башлап, 6–7 биткәчә. Боларның булу факты сюжетның Казан татарларында популярлыгын гына раслап калмый, ә XVIII йөздән соң фольклор әсәренең биредә тәмам әдәби әсәр тексты функциясен үтәүгә күчкән булуын да күрсәтә. «Таһир белән Зөһрә» дастанының татар халкындагы яшәеше фольклордан килә торган мотивларның бик уңышлы төстә язмада чагылыш табуын, кулъязмалар булып таралып, халыкның уку-язуга ихтыяҗын канәгатьләндерү чыганагына әверелеп китү фактын искәртә.

Шул ук вакытта дастанның Омск, Төмән, Курган, Чиләбе өлкәсендә, Пермь краенда, Татарстанның Тәтеш районы Олы Тархан авылында, Мордовия Республикасында татар кешеләреннән татар телендә язып алынган сөйләмә характердагы истәлекләр дә бар. Болар – дастаннан кыска фрагментлар, күпчелек очракта – дастанда Таһирның җырлап әйткән сүзләре. Җыр өлешләре гадәттә көйләп әйтелгән, алар дастанның мәгълүм язма вариантларындагы шигъри монологлар белән туры килә яисә шул монологлардан бер өзекне тәшкил итә. Кайбер очракларда информант язмадан укыганның кыскача эчтәлеген сөйли, дастаннан берничә шигырьне телдән әйтә. Арада шактый тулы вариантлар да очрый. Мәсәлән, 1957 елда Мордовия республикасы Темников районында И. Надиров Фатыйма Акбулатовадан, 1966 елда Курган өлкәсендә Ф. Йосыпов Сабира Шәфикъ кызы Гайнетдиновадан (1907 елгы), 1978 елда Р. Ягъфәров Сабира Гайнетдиновадан (1907) әлеге дастанның фабула характерындагы берәр вариантын язып алганнар. Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Асия Садыйкова тарафыннан Фаизә Гобәйдуллинадан язып алынган язма саклана [Таһир белән Зөһрә]. 1969 елда Ф. Йосыпов тарафыннан Курган өлкәсе Сафакүл татарларыннан язып алган, 1972 елда Р. Ягъфәровның Пермь крае Барда районында Тәлгыя Буранголовадан, 1980 елда Ф.Әхмәтованың Төмән өлкәсе Тубыл районында Сәрбәр Бәхтиевадан язып алынган текстлар шулай ук махсус тикшерүгә алынырга лаек вариантлар. З. Сәйдәшеваның Татарстанның Тәтеш районында Рәхимә Андаевадан «Таһир белән Зөһрә» дастаныннан кыска гына җыр өлешләре язып алган булуы хакында да кызыклы мәгълүматлар бар [Татар халык иҗаты, б. 371–372]. 1978 елда Р. Ягъфәров Чиләбе

өлкәсендә Сабира Гайнетдиновадан (1907 елгы), 1980 елда Ф. Әхмәтова Мәскәү шәһәрендә яшәүче Мөхәммәтша Кәримовтан (1911 елгы) әсәрнең кыскача эчтәлеген һәм берничә шигырен язып алган, дастанның татар версиясен гомуми планда караганда, боларның һәркайсының әһәмияте бик зур. Болардан тыш, Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә безнең тарафтан дастанның янә бер яңа варианты табылды. «Гашыйк Гариб хикәясе вә Таһир илә Зөһрә хикәясе вә Фәрхад илә Ширин хикәясе» дигән исем белән теркәлгән гарәп язулы бу басма 48 битне тәшкил итә, «Таһир белән Зөһрә» варианты үзе генә 21 битне алып тора [Гашыйк Гариб хикәясе вә Таһир илә Зөһрә хикәясе...]. Дастаннар бар да татар телендә, китап үзе 1886 елда Төркиядә басылган, Әхмәтһади Максуди автографы куелган.

Югарыда искә алынган вариантлар арасында халык теленнән язып алганнары да, кулъязмада сакланып, архивка тапшырылганнары да, авторлар иҗат иткәннәре дә, XIX йөз ахырыннан китап булып басылып чыкканнары да очрый. Дастанның татар халкында нинди формада саклануына игътибар итсәк, язма вариантлары белән янәшә XX йөзнең ахырларына кадәр «Таһир белән Зөһрә»не телдән башкару да өлешчә саклана килгәнлеге мәгълүм. Бу – әлеге сюжетка мөнәсәбәттә татарларда фольклор традицияләренең югалып бетмәве дигән сүз. Бу – «Таһир белән Зөһрә» сюжетының фольклор белән кире бәйләнеш тотуын тәэмин итә килгән әһәмиятле күренеш. Дастанның язма вариантларында, фольклор мотивларының күпләп очравы белән бергә, кайбер очракларда дастанны телдән башкару традицияләренең онытылып бетмәгән булуы да «Таһир белән Зөһрә»нең татар версиясен үзенчәлекле итә.

«Таһир белән Зөһрә»нең татар вариантларына югарыда ясалган күзәтүләргә нигезләнеп, мондый гомуми нәтиҗә ясыйбыз: дастан жанры дигәндә, татар халкында аның һәм сөйләмә, һәм китаби формада яшәгәнлеген истә тотарга кирәк. Халкыбызның «Таһир-Зөһрә» сюжетына корылган дастаннарның төрле вариантлары шуны раслый. Төрки эпосында сөйләмә һәм язма дастаннар сюжет-мотивлары, идеяләре, шигъри эшләнеше һ. б. яклары белән бер-берсенә тирән керешкән, әмма гасырлардан ук килә торган традиция булып формалашкан ике юнәлешне тәшкил итәләр. «Таһир белән Зөһрә» сюжетлы дастан татарларда төрле формада таралган. Казан татарлары иҗатында сөйләмә формада сакланган очракта әлеге сюжетның әкиятләшүгә йөз тотканлыгы, яисә әсәрнең фрагментар характерда булуы ачыклана

Барлыкка килгән тарихи алшартлар йогынтысында башка эпик әсәрләр рәтендә «Таһир белән Зөһрә» дастаны да татарларда әдәби әсәр үрнәге кебек кабул ителгән, кулдан-кулга күчерелеп укылган. «Таһир белән Зөһрә» дастанының татар халкындагы күпләгән вариантлары – халык иҗатының дастан жанрын

баета торган, аның һәм язма һәм телдән иҗат итеGлә килгән эпик традицияләргә таянган ядкәр булуын ассызыклый торган гүзәл мисаллар. Мәхәббәт дастаны «Таһир белән Зөһрә»нең төрле формада таралган, бүгенге көндә дә табыла торган вариантларының һәркайсы татар версиясен үзенчәлекле төсмерләргә баета. Халык иҗатында җитди урын алып торган әлеге дастанны махсус җентекле өйрәнү – көн кадагындагы мәсьәлә.

**Әдәбият**


*Әхмәтҗанов М.* «Таһир белән Зөһрә» дастаны // Казан утлары. 1987. № 4. Б. 179–186.

*Әхмәтҗанов М.* «Таһир белән Зөһрә»нең тагы бер билгесез кулъязмасы // Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. Казан, 1989. Б. 67–72.

*Әхмәтҗанов М.* Татар кулъязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 270 б.

*Әхмәтова Ф.В.* Дастаны Бабахан // Татар әдәбияты: 6 томда. Т. 1. Урта гасырлар дәвере. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 312–321.

Гашыйк Гариб хикәясе вә Таһир илә Зөһрә хикәясе вә Фәрхад илә Ширин хикәясе // Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. Фәридә Гаффарова коллекциясе, № 132.

*Исламов Р.Ф.* Еще об одном варианте дастана «Таһир и Зухра» // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2005. № 2. С. 193–204.

Казан федераль университеты Н. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәнең сирәк китаплар һәп кульязмалар бүлеге. Т-493, Т-497 һ.б.

*Молла-Непес.* Сказание о Зохре и Тахире. М: Гос. изд-во худ. лит-ры, 1960. 252 с.

Мухаметзянова Л.Х. Татарский эпос: книжные дастаны. Казань, ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. 380 с.

*Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. Ч.IV. Наречие барабинских, татарских, тобольских и тюменских татар. СПб., 1872. 412 с.

*Сайади.* Таһир – Зөһрә (Бабахан дастаны). Казан: Раннур, 1998. 192 б.

Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 384 б.

Татар эпосы. Дастаннар / төзүче, кереш сүз һәм искәрмәләр язучы, сүзлекне әзерләүче Ф.В. Әхмәтова-Урманче. Казан: Раннур, 2004. 640 б.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. Фәридә Гаффарова коллекциясе, № 132.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. Колл. 39, сакл. бер. № 4896, 1861, 2811, 2016; ф. 41, оп. 1, сакл. бер., № 6, 63 һ.б.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 1940, колл. 7, п. 1, сак. бер. 3.

Таһир белән Зөһрә // Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, фольклор фонды, колл. 93, папка 1, сак. бер. 21, кассета № 1.

*Урманчеев Ф.* Героический эпос татарского народа. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. 312 с.

*Хисмәтуллин Х.* Гаделлек һәм мәхәббәт поэзиясе («Дастан Бабахан» әсәренә 550 ел тулу уңае белән). Совет әдәбияты. 1965. № 7. Б. 147–148.

*Яхин Ф*. Татар шигърияте ндә дини мистика һәм мифология. Казан: Татар дәүләт гуманитар институты нәшрияты, 2000. 286 б.

***Хөсәенова Гөлнира Рәзиф кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге аспиранты*

УДК 91(с146):9(с)13-7

*И.А. Гыйләҗев*

# РОССИЯ ИМПЕРИЯСЕНДӘ ТАТАРЛАРНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ҮСЕШЕНДӘ ТӨРКИЧЕЛЕК ИДЕОЛОГИЯСЕНЕҢ УРЫНЫ (XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы)

В статье рассматривается место идеологии тюркизма в общественно-политическом и культурном развитии татар Российской империи в конце XIX – начале XX века. В настоящее время в национально-региональном аспекте особое место занимает изучение самобытной истории и культуры тюркских народов России, процесса формирования и развития тюркизма, взглядов видных представителей этой идеологии. Татары, являясь тюркским народом, сыграли большую роль в распространении, изучении и пропаганде идей тюркизма в России. Особенно остро это проявилось во время татарского национального движения конца XIX – начала XX века.

**Ключевые слова:** тюркизм, татары, тюркские народы, татарское национальное движение, идеология.

Төркичелек – төрки бердәмлек идеологиясе, барлык төрки халыкларны берләштерүче идеология. Һәр халык аны, үзенчәлекләрен, тарихи һәм мәдәни үсеш дәрәҗәсен күздә тотып, үзенчә кабул итә. Төрки халыклар XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында төркичелек эволюциясенә үзләренең кабатланмас өлешләрен керткән үзенчәлекле теоретикларын һәм идеологларын күтәрделәр. Идел буе һәм Урал яны татарлары – империянең күпсанлы төрки халкы гына булып калмыйча, үз тарихын, зур дәүләттә тоткан урынын күзаллауда һәм фикерләүдә (бигрәк тә XIX гасырда) югары активлык күрсәткән һәм үзенең бердәйлеге, тарихи-сәяси киләчәге хакында тирәнтен уйланган халык.

Татарларның ике гасыр чигендә иҗтимагый-сәяси хәрәкәтендә төркичелекнең роле һәм урыны турындагы мәсьәләне күтәргәндә, идеология буларак, төркичелек белән татарларның шул чордагы милли хәрәкәте арасында ниндидер ясалма бүленешнең, төгәл генә чикнең була алмавын тәгаен аңлау мөһим, ул чикне ясалма рәвештә булдырырга кирәкми. Төрки халык буларак, татарларның үзаңында һәм милли омтылышларында төрки башлангыч табигый состав өлешне тәшкил итте. Милли хәрәкәттә дә һәрвакыт төркичелек идеологиясенең кайбер постулатлары хөкем сөрде, алар ят элемент булмады.

Моннан тыш, XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында төркичелек һәм татар милли хәрәкәте арасындагы үзара бәйләнешкә бәя биргәндә, әлеге бәйләнештә дини факторның да

зур роль уйнавын аңларга кирәк. Россиянең күпмилләтле дәүләт сыйфатындагы тарихи үсешенең төп үзенчәлекләреннән берсе – бәхәссез ки, иң элек аның мөселман гражданнарының төрки халыклар булуы. Аларның аңында һәм милли-азатлык хәрәкәтендә мөселман теләктәшлеге, «дин берлеге» идеясе төрки халыкларның кардәшлеге, алар язмышының тарихи уртаклыгы турындагы карашлар комплексы белән тыгыз үрелде. Панисламчылык кебек үк, пантөркичелек Россиядә, татар зыялыларының мәдәни-либераль хәрәкәте буларак, 1880 елларда барлыкка килә. Төркичелек теориясенең, аннан аерылгысыз мөселман мәгариф системасын яңарту программасының (җәдитчелекнең) формалашуы һәм таралуы, барыннан да бигрәк, кырымтатар мәгърифәтчесе Исмәгыйль Гаспралының иҗтимагый һәм фәнни эшчәнлеге белән бәйле. Кыскасы, милли хәрәкәттә төрле состав өлешләр үзара үрелде, һәм аларны ясалма рәвештә бүлү нәтиҗә бирмәячәк.

Ике аспектны, ике өлкәне аерып күрсәтү мөһим – аларда төркичелек идеяләренең татарлар өчен әһәмияте аеруча зур иде.

Беренче аспект XIX–XX гасырларда татар этник бердәйлеге формалашу белән бәйле. Бигрәк тә XIX гасыр башында татар зыялылары ачыктан-ачык «Без кемнәр? Без үзебезне ничек атарга тиеш?» дигән сораулар куя башлыйлар. Татар җәмгыятендә бу темага кайнар бәхәсләр кабына, XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында милли бердәйлек идеясенә һәм халыкның үзатамасы мәсьәләсенә карата төрле карашлар яши. «Вәисиләр» буларак танылган хәрәкәт вәкилләре болгар идеясен алга сөрә. Баһаветдин Вәисов оешмасы дин сафлыгын, барлык мөселманнарның тигез хокуклылыгын яклый, җирле хакимиятләргә һәм гражданлык кануннарына буйсынмаска чакыра; вәисиләр, «татарлар» этнонимына каршы чыгып, «болгарлар» атамасын кабул итү максатын куя. Мөселман руханиларының төп өлеше мөселман бердәмлеге идеясе тарафдарлары була һәм «мөселманнар» терминын этноним сыйфатында куллануны яклый. Шул ук вакытта төрки яки гомумтөрки идея вәкилләре активлык күрсәтәләр, алар «төрки» яки, соңгы чиктә, «төрки-татарлар» этнонимын хуплыйлар. Нәкъ менә шунда И. Гаспралы идеяләренең, төркичелек идеологиясенең татар идеологик даирәсенә шактый ук көчле йогынтысы чагыла.

1905–1907 еллар революциясеннән соң этноним хакындагы киң колачлы бәхәсләр күпсанлы татар газеталары һәм журналлары сәхифәләрендә урын ала, төп бәхәс «болгарлар» яки «мөселманнар» этнонимнары тирәсендә түгел, «татарлар» һәм «төркиләр» этнонимнары тирәсендә бара. Димәк, милли бердәйлек идеясе аерым зыялылар игътибарын гына җәлеп итеп калмый, аның белән меңнәрчә кешеләр кызыксына башлый, дип әйтә алабыз. Мәсәлән, «Без кемнәр: төрекме, татармы?» дигән баш астында абруйлы «Шура» һәм «Аң» журналлары сәхифәләрендә барган

бәхәсләр генә дә әлеге фикеребезгә шаһитлык итә. Бу сорауга җаваплар да бер кимәлдә генә булмый. Шунысы кызык, «татар» этнонимын Мәрҗани һәм Насыйри дәвамчылары гына түгел, бәлки татарларга каршы юнәлтелгән рәсми пропагандага җавап итеп «татар» атамасын кулланган, аны Чыңгыз ханның һәм Батыйның дөньякүләм танылган казанышлары аша олылауга омтылган затлар да яклый.

Гасырлар чигендә гомумтөрки бердәмлек идеологиясе тарафыннан татар милли хәрәкәтенә ясалган йогынтының икенче аспектын сәяси аспект дип атарга мөмкин.

Россиядә төркичелек тәүге нәүбәттә мәдәни-агарту идеологиясе буларак яралса да, төрки халыкларның сәяси активлыгы үсү белән бергә, ул торган саен сәяси төсмер ала бара. Билгеле бер дәрәҗәдә ул империячел Россиядә киң таралган панславизм коткыларына реакция дә була. Мөстәкыйль һәм оригиналь пантөркичелек концепциясенең XIX гасырның икенче яртысында активлашкан панславизмга карата билгеле бер күләмдә полемик җавап булуын билгеләп узган Якоб Ландау: «Россия империясенең «борынгы», башка төрки төркемнәргә караганда самодержавие изүе астында һәм Россия идарәсендә озаграк гомер кичергән халкы буларак, татарларның ни өчен пантөркичелекне нигезләүдә һәм пропагандалауда инициативага һәм лидерлыкка ия булулары бик яхшы аңлашыла… Татар зыялылары (Идел–Урал, шулай ук Кырым төбәкләрендә) беренчеләр булып төрки төркемнәрнең географик җәһәттә бүленгәнлегенә чик куярга һәм аларның бер-берсе белән бәйләнешләрен ныгытырга тиешле гомумтөрки теләктәшлекнең әһәмиятен билгеләделәр» [Landou, p. 8–9], – дип ассызыклады.

1905–1907 еллар революциясе төркичелек идеяләре таралуга этәргеч бирә. Мөселманнарның 1905 елгы революцион вазгыять шартларында уздырылган беренче корылтайлары төрки-ислам теләктәшлеге идеяләрен гамәлгә ашыруга юнәлеш тота. Түбән Новгородта 15–28 августта үткәрелгән Беренче корылтай карары ук Россиянең милли мәнфәгатьләргә җавап биргән реформалар уздыруга омтылган барлык мөселманнарын берләштерү таләбен куя. 1906 елның 16–20 августында Түбән Новгород тирәсендә җыелган Өченче корылтай Мөселманнар берлеген программасы пантөркичелек идеологиясенә нигезләнгән сәяси партия итеп үзгәртү хакында карар кабул итә. Бу очракта без янә милли татар, дини һәм гомумтөрки компонентларның үзенчәлекле үрелешен күрәбез.

Нәтиҗәдә, татарларның бер өлешендә милли бердәмлек идеясенә таянган гомумтөрки аң уяна башлый. Сәяси төркичелекнең танылган теоретигы Йосыф Акчура Россия төркиләренең Беренче рус революциясе чорында уздырылган өч корылтаеның, алар мөселманнарныкы буларак аталса да, асылда милли (төрки) корылтайлар булуын билгеләп уза [Мухаметдинов, с. 31]. Россия

төркиләренең бердәмлеге идеясен гамәлгә ашыру мәсьәләсендә Й. Акчура карашының И. Гаспралыныкыннан аермасы аның үз сәяси идеяләрен гамәлләштерүдә Госманлылар империясенә зур өметләр баглавыннан гыйбарәт. Аның карашлары полиэтник империяне төрекләр этник милләтенә әверелдерүне алга сөргән госманлы төркичелеккә якын тора иде. Бигрәк тә шуның өчен (Төркия белән уйдырма элемтәгә күрә) Россиянең дәүләти-сәяси аппараты татар төркичелегенә пантөркичелек ярлыгын такты; югыйсә, татар төркичелеге беркайчан да, Россиянең башка халыклары белән чагыштырганда, төркиләрнең өстенлекле булуы идеясен пропагандаламады, бары тик Россия төркиләрен Идел буе төркиләре тирәсендә этноконфессиональ җәһәттә туплау максатына хезмәт итте. Татар төркичелеге лидерлары, аерым алганда, Фатих Кәрими, Җамал Вәлиди, Һади Максуди татарларның башка төркиләр арасында аерым тарихи урын биләвен ассызыклыйлар һәм нәкъ менә татарлар башка төрки халыкларны берләштерергә тиешләр, дип исәплиләр. Фатих Кәрими Идел–Урал төбәген төрки дөньяның үзәге дип саный һәм Идел буе татарларын төньяктагы төркиләр (шималь төрекләре) дип атарга тәкъдим итә. Төркичелек идеяләре «Вакыт», «Йолдыз», «Казан мөхбире», «Таң йолдызы» газеталары сәхифәләрендә киң урын ала. Шуңа да карамастан, төркичелек концепциясе татар зыялыларының чагыштырмача тар даирәсендә генә популярлык казана, татар халкының төп массалары арасында әлләни уңышка ирешми [Юзеев, 2002; Юзеев, 2018].

XIX–XX гасырлар чигендә татар милли һәм иҗтимагый-сәяси хәрәкәтендә төркичелекнең ролен һәм урынын анализлаганда Россия империясендә төркичелек идеологиясенең иң элек татарлар арасында яралуын, төркичелекнең татар җәмгыятенә читтән кертелмәвен, күренекле татар фикер ияләренең – сәясәтчеләрнең, философларның, дин эшлеклеләренең, язучыларның күп кенә мәсьәләләрдә гомумтөрки бердәмлек идеяләрен уртаклашуларын исәпкә алу (истә тоту) мөһим. Төркичелек алар тарафыннан сәяси перспектива юлларының берсе буларак күзаллана, мәдәни-агарту җәһәтендә дә игътибарны җәлеп итә.

### Әдәбият

*Landou Jakob M.* Pan-Turkism. From Irredentism to Cooperation. London: Hurst & Company [1995]: 2 nd edition, revised and updated, with a new bibliography. P. 8–9.

*Мухаметдинов Р.Ф.* Зарождение и эволюция тюркизма. Казань: Заман, 1996. 272 с.

*Юзеев А.Н.* Ислам и национальная идентичность казанских татар во второй половине XIX–XX вв. // Ислам и проблема идентичности татар. Казань, 2002. С. 11–12.

*Юзеев А.Н.* Исламизм, тюркизм и татаризм как компоненты общественно-политического сознания татар начала XX века // Ислам в современном мире: внутригосударственный и международно-политический аспекты. 2018. Т. 14. № 1. С. 173–182.

*Публикация статьи осуществлено в рамках мероприятия 3.5.4 Государственной программы «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014–2020 годы».*

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасының 3.5.4. номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә.*

***Гыйләҗев Искәндәр Аяз улы,***
*тарих фәннәре докторы, ТР ФА мөхбир әгъзасы,*
*ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү*
*институты директоры*

УДК 371+821.512.14

*К.С. Фәтхуллова*

# ЯҢА ШАРТЛАРДА ТУГАН ТЕЛ УКЫТУЧЫСЫНЫҢ МЕТОДИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

Статья посвящена исследованию вопросов повышения результативности обучения татарскому языку в общеобразовательных школах в условиях реализации ФГОС, а также рассмотрению методических компетенций, которыми должен владеть современный учитель.

**Ключевые слова**: современная школа, педагогические требования, инновации в обучении, татарский язык, проектирование урока.

Федераль дәүләт белем бирү стандарты (алга таба – ФДББС) – дәүләт аккредитациясенә ия булган башлангыч, гомуми, төп гомуми, урта гомуми, урта һөнәри белем бирү оешмалары тарафыннан төп укыту программаларын гамәлгә куйганда мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиешле дәүләт таләпләре җыелмасы [Шәмсетдинова, б. 12]. ФДББС-ны гамәлгә кую чорында мәгариф өлкәсендә эшләүче белгечләрдән түбәндәге гомуми компетенцияләргә ия булу таләп ителә: сәяси һәм социаль компетенцияләр (җаваплылыкны үз өстеңә алу, дөрес карар кабул итә белү); күпмәдәниятле җәмгыятьтә яшәү шартларын ачык күзаллау; эштә һәм җәмәгать урыннарында төрле катлам вәкилләре белән телдән һәм язмача аралашуга әзер булу; интернет һәм массакүләм мәгълүмат чараларында урын алган хәбәрләргә тәнкыйть күзлегеннән карый белү; һөнәри яктан да, шәхси яктан да үсеш алуга, методик осталыкны һәм иҗади активлыкны арттыру, гамәли эшчәнлекне камилләштерүгә омтылу, белем бирү өлкәсендәге үзгәрешләрне алдан тоеп эш итү. Болардан тыш, яңа шартларда мәктәп укытучыларыннан билгеле бер педагогик осталыкларга ия булу да мөһим таләпләрдән санала. Фәнни-методик хезмәтләрдә аларның түбәндәге төрләре күрсәтелә:

– оештыру осталыклары (укучыларны берләштерү, танып белү эшчәнлегенә тарту, эшкә нәтиҗә ясау);

– дидактик осталыклар (дәрес материалын эзлекле итеп аңлату, укучыларның танып белү активлыгын арттыру, күрсәтмәлелектән файдалану);

– перцептив осталыклар (психологик күзәтүчәнлек, укучыларның эчке халәтендәге үзгәрешләрне күрә белү, психик үзенчәлекләрен исәпкә алу);

– суггестив осталык (укучыларга эмоциональ тәэсир күрсәтә алу);

– тикшеренү осталыгы (педагогик ситуацияләргә һәм укыту процессына объектив бәя бирү);

– фәнни-танып белү осталыгы (үз өлкәндә фәнни белемнәргә ия булу).

Гомумән алганда, бүгенге көндә балаларга татар теленнән белем бирүче укытучылар үзләренең методик эшчәнлекләренә үзгәрешләр кертү һәм дәресләрне яңача үткәрүне төп эшләре дип кабул итәләр. Татар теле дәресләрен заманча планлаштыру һәм үткәрү өчен, укытучы үзендә билгеле бер методик компетенцияләр булдыру юнәлешендә системалы эш алып барырга тиеш. Аларга түбәндәге осталыклар карый:

– «укытучы-укучы» системасы белән идарә итә белү (максат-бурычларны билгеләү, белем бирү процессын оештыру һәм нәтиҗәләрне бәяләү);

– укучыларга мөстәкыйль белем алу өчен шартлар булдыру (укытучы – ярдәмче, тьютор, юл күрсәтүче);

– импровизациягә сәләтле булу (дәрес барышында аңа үзгәрешләр кертә алу);

– белем бирүнең сыйфатын яхшырту һәм эшнең нәтиҗәлелегенә ирешү;

– шәхескә юнәлтелгән педагогик технологияләрдән файдалана белү.

Димәк, бүгенге көн татар теле укытучысы үз эшчәнлеген белем бирүнең сыйфатын яхшыртуга, белем бирү стандартларында билгеләнгән дәрәҗәгә ирешүне тәэмин итүгә, педагогик бурычларны мөстәкыйль хәл итүгә юнәлтергә тиеш [Халилова, с. 16].

ФДББСда билгеләнгәнчә, урта гомуми белем бирүнең методологик нигезен системалы-эшчәнлекле юнәлеш тәшкил итә, шуңа күрә барлык предметларны, шул исәптән туган телләрне укыту да аның нигезендә алып барыла [Громова, с. 4]. Әлеге юнәлешнең төп эчтәлеге түбәндәгеләрдән гыйбарәт: укучыларда җәмгыять таләпләренә, мәдәниятләр дуслыгы принципларына җавап бирә торган шәхси сыйфатлар тәрбияләү; укучыларның шәхес буларак һәм социаль үсешен тәэмин итә торган технологияләрдән файдалану; белем бирүнең төп нәтиҗәсе итеп укучыларда универсаль уку гамәлләре, дөньяны танып белү күнекмәләре булдыруны билгеләү; укучыларның социаль үсешенә ирешү өчен, белем бирү эчтәлегенә, уку эшчәнлеген оештыру алымнарын төрләндерүгә төп игътибарны юнәлтү; укучыларның яшь һәм психологик үзенчәлекләрен, аралашу формаларын, иҗади потенциалын исәпкә алып эш итү; дәресләрдә танып белүнең актив формаларыннан файдалану (модельләштерү, чагыштыру, системалаштыру, анализлау, күзәтү ясау һ.б.); рефлексия (гомуми яки индивидуаль нәтиҗә) өчен, шартлар булдыру (эшчәнлекнең нәтиҗәләренә үзбәя бирергә өйрәтү); белем бирү баскычларының эзлеклелеген тәэмин итү.

Алга таба туган телләргә өйрәтүнең гомумдидактик принципларын ачыклап үтик: укытуның шәхескә юнәлтелгән булуы принцибы; укытуны иҗади процесс буларак оештыру принцибы; укытуның эшчәнлекле юнәлештә алып барылуы принцибы. Алардан чыгып, методик принциплар билгеләнә: укытуның аралашуга юнәлтелгән булуы принцибы;

телне мәдәниятара аралашу чарасы буларак үзләштерү өчен, укытуны реаль шартлардагы аралашуга якынайту принцибы; укучыларның ана телennән алган белемнәреннән, этномәдәни күнекмәләреннән файдалану принцибы.

Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: мәгариф өлкәсендә нинди генә реформалар үткәрелсә дә, нинди генә технологияләр кулланылса да, төп укыту формасы булып дәрес санала. Эшчәнлекле дәрес – нәтиҗәгә ирешүгә юнәлтелгән чаралар системасы ул. Заманча дәреснең төп эчтәлеге укучыларда универсаль уку гамәлләрен (алга таба – УУГ) формалаштырудан гыйбарәт. УУГ – танып белү күнекмәләре һәм уку мотивациясе булдыруга хезмәт итә торган гомуми гамәлләр. Алар укучыларга уку эшчәнлеген оештырырга һәм төп компетенцияләргә ия булу мөмкинлеген тудырырга ярдәм итәргә тиеш. Методистлар эшчәнлекле дәреснең нигезен тәшкил итә торган берничә факторны атыйлар: дәрес укытучы белән укучының уртак эшчәнлеге аша хакыйкатьне ачып бирү һәм аңлауга юнәлтелә; хакыйкатьне аңлау субъекты буларак, укучы дәреснең төп кыйммәте итеп билгеләнә; дәрес – укучы тормышының мөһим бер өлеше, шуңа күрә аны югары дәрәҗәдә үткәрү таләп ителә.

Дәрес төрле этаплардан торса да, ул эчке логикага буйсынган бербөтен процесс буларак кабул ителә. Заманча дәрестә барлык мәсьәләләр дә комплекслы, ягъни үзара тыгыз бәйләнештә хәл ителә. ФДББСны гамәлгә кертүгә карап, укытучыга үз эшчәнлегендә уңышлы традицион алымнарны куллануdan һич тә баш тартырга ярамый. Киресенчә, аларны саклап калу һәм планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешү максатыннан файдалану мөһим. Ә инде заманча педагогик технологияләр белем бирү барышын, белемнәрне үзләштерү нәтиҗәләрен, төрле чараларны планлаштыруны һәм гамәлгә ашыруны үз эченә ала. Әлеге эшләр, яңалыклар кертү исәбенә, укыту процессын камилләштерүгә, яңа укыту-методик комплекслар һәм компьютер программалары, интерактив уеннар белән тәэмин итүгә юнәлтелгән. Бүгенге көндә урта гомуми белем бирү системасында киң кулланыла торган технологияләрне санап үтик: проектлар технологиясе; проблемалы укыту технологиясе; уен технологиясе; үстерелешле укыту технологиясе; интегратив укыту технологиясе; модульләп укыту технологиясе; этнопедагогик технология; дистанцион технология; кейс технологиясе (ситуацияне анализлау методы); тәнкыйди фикерләү технологиясе; алга китеп (опережающая) укыту технологиясе; концентрик белем бирү технологиясе; интенсив укыту технологиясе һ.б. Укучыларның татар теле буенча белемнәре сыйфатын яхшырту өчен, укытучылар әлеге технологияләрдән системалы һәм урынлы файдаланырга тиеш. Татар теле дәресләрендә заманча технологияләрне куллану укытучыга түбәндәге максатларга ирешү мөмкинлекләре тудыра:

татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту; укучыларның танып белү эшчәнлеген активлаштыру; укучыларның иҗади мөмкинлекләрен ачып бирү һәм иҗади үсешен тәэмин итү; укучыларга җитәрлек мәгълүмат бирү; уку материалын аңлаешлы итеп җиткерү; белемнәрне системага салу; үзлектән белем алуны яхшырту; укучыларда эзләнү-тикшеренү теләге уяту; предметара бәйләнеш булдыру. Күренекле җәмәгать эшлеклесе һәм мәгърифәтчебез Р. Фәхретдин үз чорында бу мәсьәләгә карата бик тә үтемле сүзләр әйтеп калдырган: «Балаларыгызны үзегезнең заманыгыздан башка заман өчен укытыгыз, чөнки алар сезнең заманыгыздан башка бер заманда яшәү өчен дөньяга килгәннәр». Әлеге фикер бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмый, шуңа күрә бу сүзләрне һәр укытучы үзе өчен эш шигаре буларак кабул итсен иде.

Татар теле дәресләрен иҗади якын килеп алып баручы укытучылар, заман таләпләренә туры килгән биремнәрдән файдаланып, укучыларда сөйләм осталыгы, тел осталыгы, этномәдәни осталык булдыруга омтылалар. Тәҗрибәле укытучыларның дәресләрендә киң кулланыла торган эш төрләренә мисаллар китереп үтик. Сөйләм осталыгы үз эченә телдән сөйләм һәм язма сөйләмне ала. Методистлар фикеренчә, һәр төргә бәйле аерым күнегүләр куллану зарур. Мәсәлән, телдән сөйләм үстерү биремнәре: *Җөмләләрне укыгыз һәм сораулар куегыз. Диалогны тулыландырыгыз. Диалогны дәвам итегез. Ситуациягә бәйле репликаларны әйтегез. Туры килгән репликаны табыгыз. Ике рәсемне чагыштырыгыз һәм алардагы аермалар турында әйтегез. «Башкалабыз – Казан» темасына ток-шоу оештырыгыз (1 нче төркем – белгечләр, алар чыгыш ясыйлар; 2 нче төркем – экспертлар, алар кызыклы фактлар турында хәбәр итәләр; 3 нче төркем – тыңлаучылар, алар сораулар бирәләр). Онлайн аралашуда чит илләрдәге татарларга бүгенге Татарстан турында сөйләгез. Укылган текстның төп эчтәлеген 2–3 җөмлә белән әйтеп бирегез. Сез китапханәгә актив йөрүче укучы буларак интервью бирәсез. Сорауларны игътибар белән тыңлагыз һәм тулы җаваплар бирегез (Сез кайсы китапханәгә йөрисез? Яраткан язучыларыгыз кемнәр? Яшьләр нәрсәләр турында укырга яраталар? Татар язучыларыннан кемнәрнең иҗаты белән таныштыгыз? Әдәбият дәресләрендә нәрсәләр эшлисез?) Телләр өйрәнү турында сөйләгез. Сөйләмегездә түбәндәге сорауларга җаваплар да булсын: Мәктәптә нинди телләр өйрәнәсез? Татар теле дәресләрендә нишлисез? Телләр белү ни өчен файдалы? Чит телләрне яхшы белү өчен, нәрсәләр эшләргә кирәк?* һ.б.

Язма сөйләмгә өйрәтү күнегүләренә мондый мисаллар китерергә мөмкин:

*Җөмләләрне тулыландырып языгыз (ахырын, башын язып бетерегез; дәвам итеп языгыз). Беренче җөмләнең эчтәлегенә туры китереп, икенче җөмләне языгыз* (Безнең монда яши

башлавыбызга ун ел үткән инде. Без биредә ... яши башладык (ун ел элек)). *Күренекле шәхестән интервью алу өчен, 8–10 сорау төзеп языгыз. Мәктәбегездә буласы чара турында белдерү языгыз. Үрнәк буенча котлау языгыз (туган көн, юбилей, һөнәри бәйрәм, гаилә бәйрәме). Интернеттан файдаланып, һәр ел фасылы (һәр ай) турында сынамышларга мисаллар языгыз. Җөмләләрне җәенкеләндереп языгыз. Рәсемнәр буенча җөмләләр төзеп языгыз. Рәсемнәргә карап, бирелгән җөмләләрне тиешле эзлеклелектә языгыз. Сюжетлы картина буенча хикәя төзеп языгыз. Үрнәк буенча реклама тексты төзеп языгыз. Хикәянең ахырын язып бетерегез. Тормышыгызда булган кызыклы вакыйга турында языгыз. Дустыгызның сорауларына җавап биреп, аңа хат языгыз. «Тормышыма ни өчен рәхмәтлемен?» темасына эссе языгыз* һ.б.

Тел осталыгы булдыруга хезмәт итә торган биремнәргә тукталып үтик: *Тизәйткечне (санамышны) тыңлагыз һәм кабатлагыз. Хәрефләрдән сүзләр төзеп языгыз. Анаграммаларга мисаллар әйтегез (үрнәк: сукно – конус; атлас – салат). Сүзләргә сораулар куегыз. Кирәкле сүзләрне куеп, текстны укыгыз. Сүзләрне кирәкле формада куеп, текстны укыгыз. Сүзләрдән җөмләләр төзеп әйтегез. Текстны укыгыз һәм туры килгән сүзне билгеләгез. Үрнәк буенча җөмләләр төзеп әйтегез. Үткән вакыйгага карата мөнәсәбәтегезне белдерегез һәм бәя бирегез (очрашу, бәйрәм, ярыш, конкурс, шәһәр яки республика күләмендәге чара).* ***Җ*** *хәрефенә башланган сүзләрдән җөмлә төзеп языгыз. Сүзләрдән чылбыр төзеп языгыз. Сүзләрне синонимнары (антонимнары) белән алыштырып, җөмләләрне укыгыз* һ.б.

Алга таба китереләчәк биремнәр укучыларда этномәдәни осталык булдыру максатыннан кулланыла. Мисал өчен: *Итагатьле сүзләрне (сөйләм гыйбарәләрен) кулланып, әңгәмә корыгыз. Сөйләм гыйбарәләрен татарча әйтегез (Пока! С приездом! Счастливо доехать! До новой встречи! Вы очень добры. Браво!). Татарстанда яшәүче халыкларны һәм аларның милли бәйрәмнәрен атагыз. Милли бәйрәмнәр турында күмәк сөйләшү (полилог) үткәрегез. Интернеттан Татарстан халыклары Ассамблеясы һәм Дуслык йорты турында мәгълүмат табып сөйләгез. «Бәйрәме бар халык – бай халык» темасына проект эше яклагыз. «Шәһәребезнең бер һәйкәле» темасына презентация әзерләп сөйләгез. Кунакларны туган ягыгыз белән таныштырып, мәктәп музеенда экскурсия үткәрегез. «Кече Ватаным» темасына мәктәп газетасы өчен мәкалә языгыз. «Татарстан – уртак йортыбыз» фестивалендә катнашу өчен чыгыш әзерләгез. «Халыклар дуслыгы – Татарстан байлыгы» темасына ток-шоу оештырыгыз. РФ төбәкләрендә һәм чит илләрдәге татар милли оешмаларының эшчәнлеге турында мәгълүмат табыгыз һәм сөйләгез. Яраткан татар милли ризыкларыгыз турында видеосюжет әзерләгез* һ.б. Алдынгы

тәҗрибә күрсәткәнчә, шундый эш төрләре укучыларда белем бирү стандарты таләп итә торган регулятив, танып белү, коммуникатив уку гамәлләре формалаштырырга ярдәм итә, һәм һәр укучы үз эшчәнлеген мөстәкыйль һәм нәтиҗәле оештырырга өйрәнә. Алар укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып сайлана, дәреснең һәр этабында – мотивлаштыру, актуальләштерү, танып булү эшчәнлеген оештыру, ял итү, белемнәрне ныгыту, нәтиҗә ясауда кулланыла. Шулай эшләгәндә генә, татар теле дәресе, чын мәгънәсендә, эшчәнлекле дип атала ала. Күренекле педагог В.А. Сухомлинский сүзләре белән әйткәндә: «Дәрес – укытучының гомуми һәм педагогик культурасын, акыл байлыгын һәм эрудициясен чагылдыра торган көзге ул» [Фәтхуллова, б. 49]. Әйтелгәннәрдән чыгып, заманча дәрестә укытучының төп бурычларын ассызыклап китик: уңышка ирешү ситуациясе тудыру; балаларның эшчәнлеген хуплау; аларны бер-берсе белән киңәшләшергә өйрәтү; сыйныфташлары арасында аерым укучының абруен күтәрү; коллектив эшчәнлек оештыру; чыганаклардан файдаланып, яңа мәгълүмат табарга күнектерү. Чын укытучы, һичшиксез, теләсә нинди шартларда, теләсә нинди формадагы дәресне үткәрергә әзерлекле була һәм үз эшенә һәрвакытта тәнкыйть күзлегеннән карарга тырыша.

Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында берничә ел инде укытучыларның квалификациясен күтәрү программалары тормышка ашырыла. Аларның эчтәлеге, урта гомуми белем бирү оешмаларында татар телен һәм әдәбиятын укытканда, ФДББСның төп таләпләрен гамәлгә кую мәсьәләләренә багышланган. Әлеге программа кысаларында, семинарлар белән гамәли дәресләрдән тыш, мәктәпләрдә стажировкалар үткәрү дә каралган. Курсларга килгән укытучылар, төркемнәргә бүленеп, төрле мәктәпләрнең педагогик эшчәнлеге белән танышалар, татар теленнән ачык дәресләр һәм сыйныфтан тыш эшләр барышын карыйлар, аларны анализлау һәм фикер алышуда катнашалар. Шунысы шатландыра: стажировка мәйданчыкларында, тәҗрибәле укытучылар белән беррәттән, яшь мөгаллимнәр дә үзләренең методик табышлары белән уртаклаша, казанышларын күрсәтә. Шул ук вакытта дәрес барышында кайбер методик җитешсезлекләр дә күзгә ташлана. Дәресләрне анализлаганда, укытучылар проблемалы урыннарга бәйле үз тәкъдимнәрен әйтеп баралар, аларны хәл итү юлларын бергәләп билгелиләр. Типик кимчелекләрне гомумиләштереп атап үтик: төп игътибарны сөйләм күнегүләренә юнәлтмәү; укучыларның мөстәкыйль эшчәнлегенә җитәрлек вакыт бүлеп бирмәү; дәреснең эзлеклелеген бозу; дәрес барышында үзгәрешләр кертә белмәү, ягъни импровизациягә сәләтле булмау; аерым укучыларның эшчәнлегенә индивидуаль якын килмәү; барлык укучыларны танып белү эшчәнлегенә тартмыйча, берничәсе белән генә эшләү; дәрес-

нең тәрбияви әһәмиятен исәпкә алмау; укучылар белән аралашуда итагатьлелек сакламау; хаталарны төзәтүне дөрес оештырмау; укучыларның эшчәнлегенә объектив бәя бирмәү һ.б.

Йомгак ясап әйткәндә, укытучылар, заман белән бергә атлап, укучыларда кызыксыну уята торган алымнар куллануга омтылса һәм урта гомуми белем бирү өлкәсендәге үзгәрешләрне алдан тоеп эш итсә, мәктәпләрдә туган тел дәресләренең сыйфаты һәм нәтиҗәлелеге бермә-бер артыр иде. Ә бу исә, үз чиратында, укучыларны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләп, аларны көндәлек тормышта, полиэтник җәмгыятьтә үзара аңлашып һәм хезмәттәшлек итеп яшәргә әзерләр иде.

**Әдәбият**

1. 2018/2019 нчы уку елында татар телен укыту буенча методик тәкъдимнәр / төз.: Р.Р. Шәмсетдинова, Р.Ф. Фәттахова, Л.Г. Гыйләҗева... Казан: Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, 2018. 62 б.

2. ФГОС. Настольная книга учителя / В.И. Громова, Т.Ю. Сторожева. Саратов, 2013. 120 с.

3. Фәтхуллова К.С. Заманча дәрес – сыйфатлы белем нигезе // Мәгариф. 2016. № 8. Б. 48–49.

4. Халилова Х.М. Педагогические требования к учителю современной общеобразовательной школы // Образование и воспитание, 2015. № 3. С. 16–17. URL https://moluch.ru/th/4/archive/9/160/ (мөрәҗәгать итү датасы: 14.10.2018)

***Фәтхуллова Кадрия Сөнгать кызы,***
*педагогика фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының гамәли тел белеме һәм тюркология кафедрасы доценты*

УДК 371+821.512.14

***Г.Н. Мөхәрләмова,***
***Д.М. Абдуллина***

# ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ХРОНОТОПНЫ ӨЙРӘНҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

В статье рассматривается проблема изучения хронотопа на уроках родной (татарской) литературы в школе. Анализ литературного произведения в аспекте художественного времени и пространства дает возможность более глубокого его понимания. Изучение этих категорий должно проходить последовательно. Учащиеся, шаг за шагом вникая в суть этих понятий, учатся определять их роль в осмыслении идейно-художественной стороны литературного произведения. Это также позволяет расширить теоретико-литературные знания учащихся, формирует у них правильное эмоционально-ценностное восприятие художественного текста.

**Ключевые слова:** хронотоп, художественное время, художественное пространство, хронотопический образ, открытое пространство, закрытое пространство, бинарная оппозиция, хронотоп дороги, перцептуальный хронотоп.

Бүгенге мәктәптә әдәби белем бирүнең төп максатларыннан берсе – китапны яратып һәм аңлап укучы шәхес формалаштыру. Аңа ирешү өчен укучыларны әдәби әсәрне анализларга өйрәтү мөһим эшләрдән санала. Әсәргә анализ ясау аны тирәнрәк аңлау, алга таба әдәби әсәрләрне мөстәкыйль сайлый белергә, бәяләргә өйрәтү өчен кирәк. Мәктәптә әдәби әсәрне анализлау һәрвакытта әдәбият белеме фәнендә эшләнгән теоретик материалга нигезләнә. Ягъни әсәрне өйрәнгән вакытта, укучының игътибарын әдәби әсәр поэтикасын анализлауга җәлеп итеп, сүз сәнгатенең закончалыклары турында билгеле бер белемне үзләштерүгә ирешелә. Димәк, әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү әдәбият укытуда аерым урынны били. Алар арасындагы әдәби вакыт һәм урын төшенчәләре дә әдәби әсәрне тирәнрәк аңлауга, аның идеясенә төшенүгә хезмәт итәләр.

Белем бирүгә куелган заман таләпләреннән чыгып, бу категорияләрне әдәбият буенча программа эчтәлегенә кертү зарури саналса да, нигездә, аларны өйрәнү татар мәктәпләренең югары сыйныфларында гына күздә тотыла. Шуның белән бергә әдәби вакыт һәм урынны әдәби әсәр жанры, композицион үзенчәлекләр белән бәйләнештә өйрәнү җитәрлек дәрәҗәдә каралмаган. Хронотопның күп кенә үзенчәлекле якларын истә тотып, аларны әсәр мисалында анализлау да юк дәрәҗәсендә дияргә мөмкин.

Әдәби вакыт һәм урын, ягъни хронотоп теләсә кайсы сәнгать (әдәби, музыка сәнгате, рәсем, театр сәнгате) әсәренең аерылгысыз, мөһим өлеше, үзенчәлеге

булып тора. Әдәбиятта вакыт һәм урын категорияләрен өйрәнү чынбарлыкның сәнгатьчә чагылышын, әдәби әсәрнең эчке спецификасын ачып бирүгә, әсәрне кабул итү закончалыкларын ачык аңлауга ярдәм итә.

Әдәби әсәрдә вакыт һәм урын пространство белән бәйле булган һәм вакыт тарафыннан билгеләнгән һәрнәрсәдә дә (сюжетта, пейзажда, портретта һ.б.да) чагылыш таба ала. Шуңа күрә хронотоп категориясен тикшерү әсәрнең сюжет, композицион һәм жанр үзенчәлекләре белән бергә алып барылырга тиеш дип саныйбыз.

Әсәрдә вакыт һәм урын мөнәсәбәтен күрү җиңел эш түгеллеген дә истә тотарга кирәк. Аларны күз алдына китерү, аңлау билгеле бер кыенлык тудырырга мөмкин, чөнки кеше вакыт һәм урынны субъектив рәвештә генә кабул итә. Шуңа күрә әлеге эшне башкарганда укучыга укытучының ярдәме кирәк. Хронотоп төшенчәсен аңлату конкрет әсәргә анализ ясау мисалында оештырыла. Гадәттә, бу категорияләрне өйрәнү катлаулы булмаган, киң таралган хронотопик образларны тикшерүдән башланып, алга таба этаплап дәвам ителә. Укучылар, укытучы ярдәме белән, бу төшенчәләрнең асылын аңларга тырышалар, алар ярдәмендә әдәби әсәрнең идея-художество эшләнешен билгелиләр.

Хронотоп төшенчәсе белән танышуны урта сыйныфларда (5 нче сыйныфтан ук) башларга мөмкин. Бу вакытта анализлау өчен эпик әсәр алынса, дөресрәк була. Кечерәк хикәя мисалында теге яки бу вакыйга барган вакыт һәм урынны билгеләргә тәкъдим ителә. Мәсәлән, 6 нчы сыйныфта Г. Ибраһимовның «Яз башы» хикәясен өйрәнгән вакытта укучылар, әсәрдә тасвирланган ел фасылыннан һәм аның белән бәйле урыннан чыгып, әдәби вакыт һәм пространствоны билгели алалар. Алга таба бүлмә, йорт пространствосының тасвирламасын тикшерүне оештырып мәсьәләне катлауландырырга була. Бу вакытта әлеге пространствоны билгеләп торучы аерым детальләргә игътибарны юнәлдерү аларның мәгънә белдерүче функцияләрен аңлауны тәэмин итә. Һәр очракта да укучылар тексттан мисаллар китерә.

Пространствоны анализлаган вакытта укучыларга хронотоп билгеләрен төгәл табарга түбәндәге биремнәр ярдәм итә: Әсәрнең бу өлешендә тасвирланган урын белән бәйле предметларны атагыз? Алар урынны ни рәвешле билгелиләр? Ничек уйлыйсыз: алар җитәрлек биреләме, әллә автор кайбер предмет һәм күренешләрне төшереп калдырганмы? Ни өчен? Урынның вакыт белән бәйләнеше нәрсәдә чагылыш таба? Урын геройны ничек характерлый? Әдәби әсәр текстында геройның әлеге урынга мөнәсәбәте чагылыш табамы? Ул аның шәхси пространствосын билгеләргә ярдәм итәме? Яки пространство геройның шәхси идивидуальлеген чагылдыра аламы? Шушы сорауларга җавап эзләү процессында укучылар әдәби текстта урын һәм вакыт образларын мөстәкыйль рәвештә табарга өйрәнәләр.

Зуррак сыйныфларда пространствоның ачык һәм ябык

төрләре белән танышу оештырыла. Биредә беренчесенә – кыр, дала, урман, елга, мәйдан, икенчесенә бүлмә, йорт, төрмә образларын мисал итеп китерергә мөмкин.

Татар әдәбиятында, ачык пространство образы буларак, Идел елгасына еш мөрәҗәгать ителә. Укучылар әсәрләрдә аның төрле мәгънә алуын да билгеләргә тиеш булалар. Мәсәлән, Идел хронотобы, ачык пространство хасил итеп, вакыйгалар барган урынны билгели, гомер белән тиңләштерелеп, аның агышын, өзлексез булуын аңлата, Идел, татар халкының анасы рәвешендә кабул ителеп, аның яклаучысы булып та карала. Шулай ук, язучылар төп геройның хис-кичерешләре үзгәрүен күрсәтү өчен дә Идел образын кулланалар.

Ябык пространствоның бер төре булган йорт образына укучыларның игътибарын Ф. Әмирханның «Хәят» повестен өйрәнгән вакытта юнәлдереп була. Ул тар һәм һавасыз күпсанлы бүлмәләр чагыштырмасында бирелә. Укучылар бу очракта йортны ябып куелган читлек, кысан урын итеп күзаллыйлар. Боларның барысының да төп геройның күңеленә тәэсир итүенә бәйле рәвештә, «урын кешене үзенә тарта торган сыйфатта, кеше урынның үз өстеннән хакимлек итүен тоярлык, аның эчке дөньясына тәэсир итәрлек оештырылган»ны [Заһидуллина, б. 57] ачыклыйлар.

Алдагы этапта конкрет урын һәм вакыт образлары өстендә эш дәвам ителә. Мәсәлән, күп кенә әсәрләрдә юл хронотобы ачык чагылыш таба. Юл, геройның аны үтүе күп очракта аның максатын эзләвен һәм аңа ирешүен аңлата, шуңа тәңгәлләштерелә. Әлеге пространство образы әдәби герой турында күп мәгълүмат бирә ала, аның көчле һәм йомшак якларын, җәмгыять белән мөнәсәбәтен, максатына ирешү юлларын, шәхси әхлакый кыйммәтләрен характерлау аша укучының фикер йөртү мөмкинлеген ачыклый. Юл дәвамында геройларның холыклары, кешеләргә, чынбарлыкка мөнәсәбәтләре ачыла. Мәсәлән, М. Галәүнең «Мөһәҗирләр» исемле романының икенче өлешендә сурәтләнгән дөнья берөзлексез хәрәкәттә бирелә. Юл хронотобы хәрәкәт юнәлешен барлыкка китерүче бер чара буларак аңлашыла. М. Галәү юл хронотобы ярдәмендә хикәяләүгә төрле персонажлар кертә, геройларны төрле сынаулар, хәвеф-хәтәрләр алдына куюга ирешә. Юл укучыларга әсәр геройларының уңай һәм шул ук вакытта тискәре сыйфатларын ачыкларга, аларның рухи үсешләрен күзәтергә дә ярдәм итә.

А. Гыйләҗевның «Өч аршын җир» повесте да юл хронотобына нигезләнеп анализланырга мөмкин. Бу вакытта укучылар геройның туган ягына кайтуын аның әхлакый яктан үзкамилләшүенә ярдәм итү буларак кабул итәләр.

Әсәрдә урын алган юл хронотобының үзенчәлекләрен билгеләү максатыннан укучыларга түбәндәге сорауларны тәкъдим итәргә мөмкин:

– Укучылар, игътибар иткәнсездер инде, язучы юлның төрле күренешләрен бирә. Юл хронотобы нинди мәгънәләрне ачыклап

килүен күзәтик. Поезддан төшеп, Шәмсегаянны машинада хастаханәгә озатып барганда, юл кинәт тарая. Бу очракта юл хронотобы нинди мәгънә ала икән? Ничек уйлыйсыз?

– Мирвәлинең күңелен ни өчен туп-туры юл борчый, ни өчен туры, тигез юл да аңа бер дә ошамый? Кинәт борылыш пәйда булгач, ул моңа шатланамы?

– Геройларның юллары кайсы юнәлештә бара? Моны ничек аңларга мөмкин?

– Юл гел туры гына барамы? Шул урынны табып укыгыз. Әсәрдәге үзәннәр, чокырчакырлар, таучыклар нәрсәне аңлата?

– «Ук кебек сузылып яткан киң юл буп-буш иде» дип, автор нәрсә әйтергә тели?

– Авылга якыная барган саен юл тарая төшә, Мирвәли аты белән кинәт юлсыз җиргә кереп китә. Ул нәрсә эшләргә тели? Мирвәлинең Шәмсегаянны шунда гына җирләп, авылга кермичә качып китү ниятенә ничек карыйсыз? Юлсыз калу, барган юлдан тайпылу нәрсәне аңлатырга мөмкин?

Бу сорауларга җавап бирү процессында укучылар әдәби әсәрнең идея-мәгънә эчтәлегенә төшенүдә юл хронотопик образының зур әһәмияткә ия булуын аңлыйлар, ягъни теманы өйрәнүнең предмет нәтиҗәсе булып укучыларның әсәр идеясенә төшенүдә юл хронотобының ролен аңлауга ирешүләре тора.

Укучыларга әдәби вакыт һәм урын характерының кеше тормыш иткән төрле өлкәләрдә чагылыш тапкан дөнья образларына бәйле булуын аңлау да мөһим. Бу вакытта әдәбиятта культурологик мәгънәгә ия булган һәм татар халкының билгеле бер яшәү рәвешен символлаштыручы хронотопик образлар (юл, тупса, туган җир, нигез, ишегалды, морзалар утары, урман, өй, Идел [Татар әдәбияты. Теория. Тарих, б. 33]) булуын күрсәтергә кирәк. Укучылар әлеге хронотопларның һәркайсы үзенә хас мәгънәгә ия булуын аңларга тиеш була. Аерым алганда, Г. Исхакыйның «Көз» повестенда пристань образы ике геройның, озак очрашмый торганнан соң, күрешү урыны – очрашу хронотобы буларак күзаллана. Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестенда исә пристань, киресенчә, аерылышу хронотобына туры килә, чөнки әлеге пространство образы Галиянең туган шәһәреннән пароходка утырып китүе, элеккеге тормышы белән хушлашуы һәм яңасына юл алуы буларак аңлашыла. Шул рәвешле укучыларда бер үк хронотопның төрле әсәрләрдә төрле мәгънәгә ия булуына төшенү процессы бара.

Өлкәнрәк сыйныфларда укучыларның хронотоп турында билгеле бер күзаллаулары барлыкка килә, алар аңа тулы анализ бирергә әзер булалар. Мәсәлән, 9 нчы сыйныфта Г. Исхакыйның «Көз» повестен өйрәнгән вакытта анализ башында әсәрнең композицион яктан төрле вакытта һәм төрле урында барган вакыйгаларны тасвирлаган өч өлештән торуына игътибар итәләр. Беренче өлешнең эченә кертелгән калган икесенең аның сәбәп-нәтиҗәсе дә бу-

лып торуын билгелиләр. Әсәрдә беренче өлеш, анда соңыннан булган вакыйгалар турында сөйләнсә дә, хронологик яктан, киресенчә, алдан бирелә. Укучылар моңа аның көзге ел фасылында сөйләнүенең дә ишарә итүен җиңел билгели алалар.

Әсәрдә ике героиня – Нәфисә белән Гөлсемнең яшәү рәвешләре белән бер-берсеннән үзгә булган тормыш пространстволары капма-каршы куелуын укучыларга схематик рәвештә түбәндәгечә күрсәтеп бирергә мөмкин.




яки




Алга таба укучылар шундый схемаларны мөстәкыйль төзи башлыйлар. Мәсәлән, Гөлсем белән Нәфисәнең пароходта бер-берсе белән очрашып, танышып мәхәббәт тарихларын бер-берсенә сөйләп пространстволары белән якынаюын укучылар схемада түбәндәгечә чагылдыралар.




Әсәрдәге вак кына деталь дә әдәби вакыт һәм урынны билгеләүдә үз өлешен кертә ала. Мәсәлән, повестьта Нәфисәләрнең өйләренә Хәлил кунакка килгәч, Нәфисә, төшеп, үзе үк аңа ишекне ача. Әлеге күренеш Нәфисәнең егетне күңеленә якын кабул итәргә әзер булуын күрсәтеп тора. Ләкин кызның әтисе бу егетне бик тиз генә кабул итәргә ашыкмый, аның фикеренчә, ул бөтенләй башка мохиттә тәрбияләнгән, ягъни Нәфисә белән бу егетнең пространстволары тәңгәл түгел. Шуңа күрә беренче тапкыр егет Нәфисәләрнең өенә (пространстволарына) ничек кергән, шулай чыгып та китә. «Ишек ачылды, ябылды, егет югалды» дигән җөмлә шуңа ишарә итә.

Схемада бу күренеш түбәндәгечә күрсәтелә ала:




Егетнең Гөлсем белән мөнәсәбәтләрендә дә шундый аерым детальләр билгеләнә. Әйтик, яшьләр арасында барлыкка килгән упкынның көннән-көн тирәнәюен язучы алар барысы бергә су буена ял итәргә баргандагы вакыйга аша күрсәтә. Гөлсем белән Паша төрле арбаларга утырып барырга мәҗбүр булалар: «Пашаларның арбасы гына һаман артта бара» иде. Укучылар Ерак/Якын оппозициясенең бу очракта Югары/Түбән оппозициясенә туры килеп, егетнең социаль хәле ягыннан да Гөлсемнән үзгә икәнлеген күрсәтүче билге булуын аңлыйлар.

Бинар оппозицияләрне кулланып хронотоп төшенчәсе белән

эшләү укучыларны күп өстәмә мәгълүмат бирүе белән кызыксындыра. Лирик әсәрләрне анализлаганда да бу яктан тикшерү кызыклы нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Мәсәлән, Дәрдемәнд иҗатын өйрәнү барышында укучылар шагыйрьнең кеше гомерен ике өлешкә – үткәнгә һәм хәзергегә бүлүен күрәләр. Дәрдемәнд шигырьләренең күпчелегендә әлеге ике вакыт катламы бер-берсенең дәвамы буларак түгел, ә бәлки капма-каршы куелган төшенчәләр итеп шагыйрь әсәрләрендә Үткән/Хәзерге оппозициясен билгеләү аша кабул ителә.

Дәрдемәнд шигъриятендә яшьлек, ягъни шагыйрь өчен үткәндәге тормыш яз образына тиңләштерелә. Гомернең язы – яшьлек, календарь вакытның «шифалы, нурлы, хуш исле» яз фасылына туры килә. Хәзергесе исә кыш образында тәгаенләнә. Ул шагыйрь өчен яшәү мәгънәсенең югалуын, гомеренең тәмамланганлыгын билгели. Аны аңлау аша укучылар Дәрдемәнднең пессимистик хисләренең сәбәпләренә төшенәләр.

Дәрдемәндтән аермалы буларак, хәзерге чор шагыйре Р. Фәйзуллин лирик геройның тормыш юлы ике ноктадан – яшьлек һәм картлыктан гына, ягъни яздан һәм кыштан генә тормавына басым ясап, аның әле алтын уртасы – җәе, ягъни адымнарны саный торган, көчне чамалый торган, бар нәрсәгә дә саклык белән карап эш итә торган вакыты да булуын сөйли.

Мәктәптә Р. Фәйзуллин иҗатын өйрәнгән вакытта әдәбият программасы шагыйрьнең вакыт, тарих, тормыш турында фәлсәфи уйлануларын тикшерүне дә күздә тота. Укучылар бинар оппозицияләр белән эшләү барышында шагыйрьнең вакыт агышын күзәтеп, аның мәңгелеген билгеләвен, кеше гомерендәге яшьлек, картлык кебек чорларның үзенчәлекләрен барлавын, аларга үз мөнәсәбәтен белдерүен күрә алалар.

Югары сыйныфларда әдәби әсәрне вакыт һәм урын аспектында анализлау перцептуаль хронотопка мөрәҗәгать итүне дә күздә тота. Билгеле булганча, ул – әсәр геройлары белән булган психологик процессларга бәйле. Перцептуаль хронотоп, субъектның тышкы һәм эчке тәҗрибәсен билгеләп, художестволы образ формасында чагылыш таба. Әсәрләрдә перцептуаль хронотоп геройларның хатирәләре, уйлары, хыяллары, төшләре, саташулары рәвешен ала. Әдәби урын һәм вакыт категорияләре белән эшләү барышында укучылар бу төшенчәләрнең субъектив булуын аңлыйлар. Объектив урын һәм вакыттан аермалы буларак, ул – субъектив дөньяның билгеле бер күренешләренә, ягъни кешенең психик халәтенә, эчке дөньясына юнәлгән була.

Г. Рәхимнең «Идел» повестенда, перцептуаль хронотопның бер формасы буларак, геройның уйланулары, хыяллары да тасвирлана. Ильяс, еш кына, хыялга бирелергә ярата, бу аның романтик рухлы булуы белән бәйле. Ильясның хыяллары чиксез, кайберләре саташу вакытында, кайберләре ялгыз чакларында килә. Мондый вакытларда ул үзен шагыйрь дип хис итә. Ильясның төшләре

күп очракта саташу рәвешен ала. Ильяс бизгәк белән авырганда күп саташа. Саташулары үзләренең үзенчәлекле эчтәлекләре белән аерылып торалар, күпчелек очракта геройның халәтен чагылдырып бирәләр. Мәсәлән, бер төшендә герой текә ярдан тәгәрәвен күрә. Куллары-аяклары белән тырмашып, туктамакчы да була, ләкин булдыра алмый, «аякка гер таккандай», түбәнгә шуа. Биредә Югары/Түбән оппозициясе билгеләнә. Шуның аша укучылар геройның тормышта үзенә урын, күңел тынычлыгы таба алмавын аңлыйлар.

Шулай итеп, укучылар күптөрле һәм тирән мәгънәгә ия булган хронотопларның барлыгын аңларга тиешләр. Әсәрләрне әдәби вакыт һәм урын үзенчәлекләре нигезендә анализлау һәм шәрехләү укучыларның әдәби-теоретик белемнәрен, әдәби текстны кабул итүне камилләштерүен тәэмин итә һәм әсәргә карата дөрес эмоциональ-кыйммәти мөнәсәбәт формалаштыра. Шул рәвешле әсәрне әдәби вакыт һәм урын аспектында өйрәнү аны кабул итү, анализлау һәм шәрехләү арасында бәйләнешләрне тирәнрәк аңлауга хезмәт итә.

**Әдәбият**

*Бахтин М.М.* Формы времени и хронотопа в романе // Вопросы литературы и эстетики. М., 1975. С. 234–407.

*Заһидуллина Д.Ф.* Әдәби әсәргә анализ ясау: урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / Д.Ф. Заһидуллина, М.И. Ибраһимов, В.Р. Әминева. Казан: Мәгариф, 2005. 111 б.

Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова. Тулыл. 2 нче басма. Казан. Мәгариф, 2006. 319 б.

***Мөхәрләмова Гөлназ Нурфат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге мөдире*

***Абдуллина Диләрия Марат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының милли мәгариф бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 7.03

*О.А. Гыйльметдинова*

# АКАДЕМИК СӘНГАТИ БЕЛЕМ ҺӘМ ИСЛАМ СӘНГАТЕ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ, АЛАРНЫҢ БЕР-БЕРСЕНӘ ҮЗАРА ЙОГЫНТЫСЫ[1]
## (Н.И. Фешин исем. Казан сәнгать училищесы мисалында)

В статье предпринята попытка проследить процесс взаимодействия традиций академического художественного образования и «исламского искусства». Анализ работ студентов и современных художников-педагогов показывает, что обогащение и взаимовлияние различных эстетических систем способствует формированию своеобразного художественного языка, который открывает новые возможности развития регионального искусства.

**Ключевые слова:** Академия художеств, Казанская художественная школа, художественное образование, исламское искусство, традиции.

Россиянең академик сәнгати белем бирү системасы озак вакытлы тарихи үсеш процессында формалаша һәм үз дәверендә берничә буын рәссамнар әзерләп чыгара. В. Ванслов фикеренчә, «эта школа в процессе развития культуры корректировалась и совершенствовалась, впитывала в себя новые достижения искусства, и она является нашим ценнейшим национальным достоянием» [Ванслов, с. 5].

Бу – чынбарлыкны миметик сурәтләү мәктәбе. С. Гавриляйченко билгеләп үткәнчә, «к родовым чертам академической школы следует отнести почитание традиций» [Гавриляйченко, 2007, с. 241]. «Её проблемы – это проблемы развивающегося метода изображения, неизбежно требующего освоения уже накопленных методов и умений, учета опыта предшественников» [Дуброва, 2009, с. 132]. Шул ук вакытта «…традиция уже в своем семантическом значении «передача» (латинское «traditio») означает существование прошлого в новых условиях, а без этого обязательного значения, без своего временного, движущегося из прошлого в настоящее оттенка превращается в простой, никому не нужный склад готовых, отживших свое форм» [Валеева-Сулейманова, 1990, с. 133]. Нәтиҗәдә, сәнгать мәктәбе үзенең тотрыклылыгын һәм үсешен үткәндәге сәнгати мираска таянып тәэмин итәргә тиеш.

Хәзерге вакытта сәнгать белеме, шулай ук тасвирый сәнгать белеме бирүдә ике тенденция яшәп килә. Беренчесе – дөньякүләм сәнгать агымнарына, тенденцияләренә һәм традицияләренә актив кушылу. Икенчесе – милли традицияләргә игътибарны көчәйтү. Шулай эшләгәндә генә мәдәниятләрне һәрьяклап баету мөмкин булачак. Рәссамнар үткән гасырларның бөек мирасына мөрәҗәгать итеп, үзләрен кызыксындырган күп кенә сорауларга җавап табачаклар.

1895 елда Казанда ачылган сәнгать мәктәбе (хәзерге Н.И. Фешин исемендәге сәнгать училищесы) инде зур тәҗрибә тупларга һәм күптөрле сәнгати традицияләр үзләштерергә өлгерде. Эшли башлаган көненнән үк ул Сәнгать академиясенең киңкырлы яклавыннан файдалана, һәм бу мәктәпнең нигезе дә классик академик белем бирүгә юнәлдерелә[2].

Мәктәпнең сынлы сәнгать бүлеге аеруча танылу яулый. Бу яктан ул үз рухындагы башка уку йортлары арасында зур популярлыкка ирешә. Казан сәнгать мәктәбендә рәсем һәм сынлы сәнгать белеме бирүне Н.Н. Белькович, И.А. Денисов. Г.А. Медведев, Х.Н. Скорняков башлап җибәрәләр. Алар эшен шушы мәктәпне тәмамлагач, сәнгать академиясендә белем алып кайткан Н.И. Фешин, П.П. Беньков, М.С. Григорьева, В.К. Тимофеевлар дәвам итә. П.М. Дульский да мәктәптә белем бирү эшчәнлеге алып бара[3] [Дульский, 1914; 1925; 1929; 1930].

1917 елгы революция, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге башка юнәлешләр кебек үк, рәсем сәнгате буенча белем бирү эшчәнлеген дә өзә. Сәнгати белем бирүнең инде формалашып килгән тотрыклы системасы игълан ителгән «яңа сәнгать» тарафыннан җимерелә [Период становления..., 2004]. Мәктәпнең данын тоткан күп кенә рәссам-педагоглар 1926 елда эшчәнлекләрен туктаталар, күпләре республикадан ук күчеп китәләр (шуларның берсе Н.И. Фешин була).

Бу чорның күп кенә рәссамнары теленә хас тасвирый үзенчәлек конструктив-композицион характердагы фикерләүгә нигезләнә. Яңа сәнгатьне чагылдыру чаралары үсешенең билгеле бер юнәлеше нәкъ әнә шуннан гыйбарәт. «Основное значение в теоретических установках приобретают прикладные виды искусства, ремесленно-производственные формы творчества. Главными принципами объявляются целесообразность и отказ от ненужного внешнего украшательства, переход к новой дизайнерской бездекорной форме» [Валеева-Сулейманова, 1995, с. 23]. Мәктәпне тәмамлап, сәнгатьнең авангардизм һәм футуризм тарафдарларына ияргән Д.Д. Бурлюк, А.М. Родченко, И.А. Никитин, К.К. Чеботарев, А.Г. Платунова кебек иҗатчылар, сәнгати сәясәттә алдынгы идеяләргә ия булуларына карамастан, яшь рәссамнар тәрбияләүнең яңа системасын тудыра алмыйлар. Үткән традицияләргә кире кайтырга тормыш аларны үзе мәҗбүр итә.

Татар сәнгатенең үзенчәлеген саклау һәм «татарлардан рәссамнар» үстерү проблемалары кискен характер ала. Озак еллар дәвамында татарларга академик дәрәҗәдәге сәнгать белеме алуга мөмкинлек булмый, бу аларның ислам кануннары нигезендә яшәүләре сәбәпле тоткарлана. «Ислам с самого начала отказался от помощи изобразительного искусства для пропаганды своих идей и этим сразу исключил возможность существования тех видов искусства, которые мы знаем

в средневековой Европе» [Большаков, с. 142–153]. Татарлар диндә исламның катгый ортодоксаль формасы – сөнниләр юнәлешенә буйсыналар. Сынлы сәнгатьтә кешене гәүдәләндерү – «сурәт» төшерү алар өчен тыелган була.

1938 елда П.М. Дульский Язучылар берлегенең яңа идарәсенә теләк йөзеннән язылган юлламасында болай дип белдерә «…Необходимо в ближайшее время установить связь с Академией художеств, сделать запрос для привлечения молодых советский художников, окончивших Академию, для освежения преподавательского состава Татарского художественного училища» [Червонная, 2006, с. 37]. Шул ук елда Татарстанның рәссамнар коллективын һәм сәнгать училищесы укытучылары составын Ленинград сәнгать академиясен тәмамлаган Я.В. Ушков, Р.С. Зиновьев һәм Н.В. Вәлиуллин тулыландыра. Татар милләтеннән булган Н.В. Вәлиуллин КСУда 1938–1941 елларда белем бирә. Ул анда татар укучылары төркеме белән җитәкчелек итә. Һөнәри осталык һәм сәнгать тарихы нигезләре буенча лекцияләрен татар телендә укый. «Своим ученикам он передавал эстафету знаний, полученных в ленинградской школе, и именно из плеяды этих учеников нового поколения выдвинулись люди, ставшие руководителями творческих союзов послевоенной поры, организаторами зональных выставок, лауреатами высших премий страны, первыми академиками (Х. А. Якупов)» [Червонная, с. 37]. Укучыларының хәтерендә сакланганча, ул импрессионистлар юнәлешенә һәм В.И. Суриков иҗатына өстенлек бирә торган булган.

1940–1950 еллар социалистик реализм канунннарының иң кырыс чоры була. Сәнгати профильдәге барлык уку йортларында да белем бирү бердәм катгый методикага нигезләнә. Казан сәнгать мәктәбе педагоглары арасында Ленинград һәм Мәскәүдәге сәнгать уку йортларын тәмамлап килгән В.К. Тимофеев, В.К. Архипов, П.Т. Сперанский, М.Н. Васильев, С.А. Ротницкий, В.С. Подгурский да була.

1960–1970 елларда педагоглар буыны алышыну училищеда сәнгать белеме бирүдә яңа этапны башлап җибәрә. Анда В.И. Куделькин, Е.В. Зуев, Р.Ф. Имашев, Б.М. Майоров, К.А. Нафиков, Р.И. Төхвәтуллин, Х.Х. Хәйдаров, Т.М. Юдина, А.С. Иванцев эшли башлый. Белем бирү системасы үзгәреш кичерә. Педагогларның индивидуаль үзенчәлеге укучыларның стилистик аерымлыкларында чагылыш таба. Мәсәлән: Р. Төхвәтуллинга буяулар төшерүдә кыюлык хас булса, Е. Зуев декоратив чәчәкләр төзелеше, ә Б. Майоров катлаулы соры-перламутр төсләр кушылмасыннан файдалану алымнарын оста кулланалар.

Әлбәттә инде, атеистик пропаганда көчле җәелдерелгән елларда милли традицияләргә, бигрәк тә ислам сәнгатенә игътибарны юнәлтү хакында сүз дә алып барып булмый. Совет режимы алар хакындагы иҗади эзләнүләрне һич тә хупламый, сәнгати белем бирү процессында

андый традицияләргә игътибар күрсәтү аеруча рөхсәт ителми. Рәсемнәрдә миллилек тышкы атрибутларда гына, әйтик, кием детальләрендә, татарларга хас йөз төзелешендә чагылыш таба. Татар тарихына багышланган темалар бөтенләй күтәрелми Ислам йолаларына кагылышлы атрибутлар рәсем сәнгатендә урын алмый.

1980 еллар ахырыннан башлап, Казан сәнгать мәктәбенең «өр-яңа тарих»ы башлана. Милли үзаң күтәрелә башлау белән бәйле рәвештә, халыкның үз тарихына һәм милли тамырларына омтылышы көчәя. Тасвирлау теленең күптөрлелегенә борылыш башлана. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, училищеда Мәскәү сынлы сәнгать мәктәбе вәкилләре А.Г. Хәмидуллин белән М.А. Ваһапов эшли башлагач, укыту программасына яңа темалар өстәлә, ягъни уку йортына алар «саф агым» алып килә[4].

Әлбәттә, студентлар иҗаты да, педагоглар эшчәнлеге дә, иң элек, академик рухтагы сәнгать мәктәбенең программаларына нигезләнгән була. Әмма күп кенә картиналарда авторларның үз халкы тарихы, шул ук вакытта дини йолалары белән табигый кызыксынуы да чагылдырыла. Рәссамнар белән студентлар исламның һәм татар мифологиясенең бай арсеналына ешрак мөрәҗәгать итә башлыйлар. Ул чорның сәнгати вазгыяте С.М. Червонная иҗатында ачык характерлана. Ул үзе әйткәнчә, эштә «большой накал патриотических чувств при изображении и осмыслении всего, что соответствует понятиям «наша земля», «наша родина», «наша семья», «наш народ», «наш дом», всего того, что в европейской традиции принято обозначать словами «дух места». Причем этот «дух» и это «место» здесь имеют неповторимую исламскую специфику, соответствующую действительности, или придуманную художником, воплощающим таким образом в художественную ткань свою мечту, свою любовь и веру» яңгыраш таба [Червонная, 2008, с. 429]. Э. Әхмәтованың «Кичке чәй» («Вечерний чай», 1995) дигән диплом эскизы (җитәкчесе – Ю. Бердников, сәнгать укутучысы – А. Хәмидуллин) шушы рухта эшләнгән[5]. Картинада милли киемнәрдәге хатын-кызлар төркеме сурәтләнгән. Алар кул эше белән мәшгуль: кайсыдыр чигү чигә, кайберләре әзер эшләнмәләрне карый, өлкән яшьтәге хатын йон эрли. Күренештәге интерьер милли һәм дини үзенчәлекләргә хас детальләр белән баетылган: стенада – шамаил, чигелгән тастымаллар эленгән, идәндә – кулдан суккан паласлар. Эскизның композициясе горизонталь яссылыкта бирелгән. Йөзмә сызыкларның йомшак ритмыннан музыкальлек бөркелә. Картинада мәгънәви үзәк юк. Акцентлар төс һәм тоннар ярдәмендә тоемлана. Кызыл һәм зәңгәр төсләрнең бай нюансы бер-берсенә бик көйле үрелгән. Н. Вахитованың «Сөембикә» әсәрендә (җитәкчесе Ю. Бердников, сәнгать укытучысы – А. Хәмидуллин, 1995) композиция фронталь рухта төзелгән, анда, Кәнчыгыш миниатюраларындагыча,

горизонт сызыкларының югарыга омтылышы күзгә ташлана. Сөембикәнең фигурасы, башка персонажлар белән бербөтенне тәшкил итеп, өчпочмаклык барлыкка китерә, картинага ниндидер кискенлек һәм фаҗигалелек өсти. Төсләр колориты төрле чагылыштагы кызыл төскә нигезләнгән. Баш героиня шул фонда аерылып торган силуэт рәвешендәге ак төс белән гәүдәләндерелгән. Әйтеп үткән ике эш тә «ислам сәнгате» белән янәшәлеккә омтылалар, аларда полихром һәм катлаулы ясау манерасы буенча йомшак тоннар күчешенә ия герат миниатюралары сынлы сәнгате төзелешенә охшатырга тырышу сизелеп тора.

Үз картиналарында чигү, бизәкләп туку, гадәти милли тормыш рәвеше элементларын чагылдырып, авторлар үз халкының тарихи хәтерен яңарталар.

Мөселман дөньясын Европа тасвирый системасын файдаланып яктырткан эшләр шактый күп. Шулардан И. Әскәровның «Йосыф кыйссасы» («Сказание о Юсуфе», 2005) дигән диплом эскизы (җитәкчеләре – О.А. Гыйльметдинова һәм Н.Т. Хаҗиәхмәтов, сәнгать укытучысы –А.Г. Хәмидуллин) Урта гасыр татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре сюжетына нигезләнгән. Картина станок композициясенең классик метод һәм алымнарын файдаланып эшләнгән: картинада шактый гына гомумиләштерелгән күләгәдәге алгы план, мәгънәви композицион үзәк урнаштырылган икенче план һәм караңгы яссылыктагы арткы план бирелгән. Автор геройларын төп мәгънә буенча төркемнәргә берләштереп, аларның психологик халәтен, эмоциональ кичерешләрен чагылдырырга омтыла. Анда төсләр контрасты һәм күләгәләр көчле тасвирый чара булып хезмәт итә. Рәссам яктылык һәм күләгәләр аша сюжетның мәгънәви тәэсирен көчәйтергә тырыша. И. Халиковның «Сәләхетдин» әсәре (җитәкчесе – А.Г. Хәмидуллин, 1999), Европа осталарына гына хас тасвирлау чаралары кулланып иҗат ителүгә карамастан, Көнчыгышның гомуми колоритын хәтерләтә. Анда хәтта XIX гасыр башындагы театральлек, тантаналы монументальлек сыйфатларын гәүдәләндергән каҗар осталары стилен дә чамаларга мөмкин.

Ислам дөньясы дини корылмалары урын алган пейзажлар һәм интерьерлар аеруча зур кызыксыну тудыра. Бу темага багышланган барлык эшләрдә дә диярлек, алар урнашкан тирәлекне, аның табигатен тирәнтен өйрәнүгә омтылыш сизелеп тора. Андый картиналарның композициясе тантаналылыкны тасвирлауга юнәлдерелгән була. Эшләрдә, шулай ук, Европа һәм Россия пленэр сәнгате традицияләре дә тоемлана (мисал итеп, М. Хәсәновның «Кол Шәриф мәчете» (2007), «Кол Шәриф мәчетенең эчке күренеше» (2007) эшләрен китерергә була).

Әмма тагын шундый пейзажлар да бар – алар башка тасвирый телдә эшләнгәннәр: кайберләрен витраж фрагментларына яки мозаикаларга таркатырга була, икенчеләрен, әйтерсең,

җепләрдән үргәннәр. Мәсәлән: Л. Насыйбуллинаның «Кремль панорамасы» (2005), Р. Габбасованың «Казаным минем» (2004) әсәрләре. Аларда, «ислам сәнгате»ндәгечә, декоратив башлангычка омтылу күзәтелә. Белгечләр фикеренчә, «мусульманская чувствительность по самой своей природе сторонится любого натуралистического изображения – объемно трактованной человеческой фигуры, трехмерной пространственной перспективы, иллюзорного моделирования предметной формы» [Валеева-Сулейманова, 1997, с. 63]. Авторлар, шулай ук, шамаилләрдә дә, мөселман дөньясына мөрәҗәгать итеп, мәчетләрне, эпиграфиканы, чәчәкүсемлек орнаментларын үзара стильләштереп сурәтлиләр[6].

Натюрморт жанрында, аеруча Көнчыгыш сюжетларында авторлар, кайбер очракларда, тасвирланган объектларның тәэсирле бизәлешен көчәйтеп, кабул итү аспектын үзгәртәләр. Картиналарда натура, Көнчыгыш миниатюраларын сурәтләү традицияләре һәм Европа колоризмы кушылган хәлдә бирелә (моңа мисал итеп, Р. Габбасовның «Көнчыгыш натюрморты»н (2005) китерергә була).

Педагог-рәссамнар иҗатында да Көнбатыш Европаның академик традицияләре һәм ислам сәнгате традицияләренең үзара бәйләнеше күзәтелә.

Көнчыгыш реминисценцияләр Н.Т. Хаҗиәхмәтов иҗатында («Внутренний дворик Ханского дворца» (2003), «Ханский дворик в Казани» (2003), «В мавзолее Сафа Гирея» (2003) картиналарында) чагылыш таба. Бу автор үзенең иҗатында декоративлыкка һәм ориентализмга омтыла. Ул турыдан-туры тарихи сюжетларга мөрәҗәгать иткәндә дә Шәрык экиятләрендәгедәй иллюстрацияләр тудыра һәм шуның белән Көнчыгыш миниатюралары традицияләренә якыная. Н.Т. Хаҗиәхмәтов картиналарында орнаментларны күп файдалана, алар ярдәмендә геройлары өчен мозаик тирәлек тудыра. Әмма төп персонажларны гәүдәләндерүгә ул реаль якын килә. Бу рәссам иҗатында «ислам сәнгате» чагылышын Казан метросындагы мозаикалардан да күрергә була. Аларда – төсләр үрелмәсе дә, кешеләр төркемен декоратив кабул итү дә, катнаш аспектларның фронталь композициясе дә.

Күп төрле жанрда иҗат итүче М.А. Ваһапов иҗатында үзенчәлекле эволюция күзәтелә. Башлангыч чордагы эшләрендә натурага аналитик караш өстенлек итсә, тора-бара тасвирый теле декоративлаша төшә, төсләр бирелеше байый, сурәтләгән объектларының күләме кими. Рәссам үзе әйткәнчә, аның программ әсәре булып «Цветы. Приношение» натюрморты санала. Бу фәлсәфи тукыма – авторның әнисенә багышламасы. Тема композицион алымнарны һәм сәнгатьчә манераны рәссамга үзе үк тәкъдим итә. Тоташ орнаментлар белән чуарланган фон һәм аңа үрелдереп урнаштырылган чәчәк бәйләнемнәре, шәрык келәмнәрен хәтерләтеп, бердәм орнаменталь өслек барлыкка китерә, һәм

чәчәккә күмелгән бакчаны, «җәннәтне» күз алдына китерә.

Авторның декоративлыкка һәм төсле тапларны локальләштерүгә омтылышы шушы әсәрендә тулы чагылыш таба. Рәсемнең ирекле ритмы, сурәтләүдә төсләр интенсивлыгы – болар һәммәсе дә картинаны «җылы» тон, күтәренке рухтагы бер көй буларак кабул итүгә юнәлдерелгән.

Рәссам А.Г. Хамидуллин иҗатына ачык төсләрдән гыйбарәт үзенчәлекле полихромия хас, ә нәфис төсмерләрне чагылдыруында авторның объектларны күләмле итеп гәүдәләндерүгә, һәм киңлекне табигый сурәтләүгә омтылышы тоемлана. Аның һәр эше җентекле уйланган композициягә нигезләнгән. Аларда очраклылык юк, һәр сызык, төсле һәр тап, күләгәле яктылык юнәлешләре – барысы да бер-берсе белән бәйләнгән. Күзаллауның нәтиҗәлелегенә ирешү өчен рәссам, еш кына, алтын һәм перламутрлы акрил, кайчагында фольга да куллана.

А. Хәмидуллинның «Натюрморт с серебристым кувшином» әсәре (1997) нәфис бизәкләнеше белән аерылып тора, аннан Шәрык сәнгате (орнаментлар төшерелгән тукыма һәм көнкүреш әйберләре) рухы бөркелеп тора. Әлеге хезмәттә, бу авторга гына хас булганча, төсләрнең шигъри аһәңе һәм Көнчыгышның бормалы бизәкләрен хәтерләткән пумала эзләре кинетикасы ачык сизелә.

А. Хәмидуллинны Шәрык сәнгатенә турыдан-туры омтылышы булмаган эшләрендә дә аның эчке тоемлавы күзгә ташлана. «Натюрморт с фруктами на окне» әсәрендә (2008), мәсәлән, кышкы кичнең шигъри аһәңе яңгыраш ала. Тәрәзә артындагы пейзаж исә, агач кәүсәсенең ирекле линияләре белән үрелеп, үзенә бер хикмәтле геометрик орнамент барлыкка китерә. Фронталь композиция симметрияле итеп уйланылган. Формаларның җиңелчә генә сурәтләнүенә карамастан, образ эчке тулы мәгънәгә ия. Тәрәзә рамнарын рәсемдә күрсәтмәү нәтиҗәсендә, тәрәзә төбендәге җиләк-җимешләр һәм урам пейзажы тоташ бербөтен хасил итә.

«Натюрморт на зеленом ковре» әсәрендә рәссам карашның берничә реаль ноктасын берләштереп, аларны хәрәкәттә тоемлауга этәрә. Натюрморттагы предметлар келәм бизәгенә әверелеп, ниндидер тылсым белән, аннан аерылып чыга сыман. Натюрморттагы сызык юнәлешләре әле кушылып, әле аерылып әйләнмә хәрәкәт барлыкка китерәләр.

Авторның бу эшенә дә «җәннәт бакчасы» метафорасы аваздаш. Әйтеп үтелгән натюрмортта иртәнге җәйге бакча сурәтләнгән булса, алдагысында кышкы кич тасвирлана. Соңгы рәсемдә зәңгәр һәм яшел төсмерләр кызыл, куе кызыл, алтынсу-кызгылт, сары бөрчекләр белән чуарланган.

А. Хәмидуллин пейзажлары тирән шәхси үзенчәлеккә ия. Аларның көче – мәгънә тирәнлегендә, табигый гүзәллек чагылышында. Мәчетләр сурәтләнгән картиналарда аларның тирәлеге бербөтен булып күзал-

лана. Аларда төп объект мәчет булса да, пейзаждагы гомуми тоны һәм төсләр сайланышы белән һәркайсы (мәсәлән, «Вечер. Бурнаевская мечеть», «Бурнаевская мечеть Солнечный день» картиналары) кабатланмас хис уята.

А. Хәмидуллин үз заманы рухындагы сәнгать тудыра, шул ук вакытта, аның иҗаты үз күңеленә якын «ислам сәнгате»нә дә аваздаш. Ул авторның Көнчыгыш мотивларына тәңгәл бизәлеш ритмнарында, үзенчәлекле төсләр аһәңендә чагыла. Автор үзе әйткәнчә, аларда «бабаларыбыз хәтере» яңартыла, моны фәкать эчке сиземләү аша гына тормышка ашырырга мөмкин.

Шулай итеп, студентлар һәм кайбер рәссам-педагоглар эшләренә ясалган анализдан мәгълүм булганча, ислам темасына мөрәҗәгать иткәндә, ике тенденциясе күзәтелә.

Аларның берсе – Европаның реалистик сәнгате күзлегеннән караганда, рәссамнар иҗатында мөселман дөньясы пәйда булуга нигезләнгән. Андый сурәтләрнең тематикасы, тасвирый теленең характерын үзгәртмичә генә, үз халкының тарихын, гореф-гадәтләрен, яшәү рәвешен дини омтылышларын хәтердә яңартуга юнәлдерелә. Мондый рухтагы картиналарда тудырылган образлар үткәннәргә эмоциональ караш уята һәм индивидның бүгенге проблемаларга реакциясен ачыклый.

Икенчесе – Европа сынлы сәнгате алымнары һәм элек-электән мөселман цивилизациясенең бер өлеше буларак үсеш алып, дөньяны сәнгати кабул итү үзенчәлеген саклап кала алган милли мәдәнияткә нигезләнгән. Әлеге юнәлештәге күп кенә эшләрдә авторлар үз идеяләрен «метафорик» чагылдыруга омтылалар. «Согласно исламской концепции, художник не должен воспроизводить внешний мир, сотворенный богом, поскольку копия его не может сравниться с божественным оригиналом. Он должен стремиться понимать бога, а значит и созданный им мир» [Валеева-Сулейманова, 1997]. Монда үзенә бер тасвирый телдә һәм композицион алымнар белән белдерелгән натура хакында сәнгати фикер-йөртү характеры да ачыклана. Бу очракта инде төгәл генә реалистик тасвирлау була алмый, рәссам дөньяны шартлы гына кабул итә, ә реаль фикер йөртү авторның шәхси сәләтенә бәйле рәвештә абстракт формада гына булырга мөмкин. Әйтик, «принципы «обобщенного реализма», которые выражаются в контурных реалистического характера изображениях, в их орнаментально-декоративной стилизации» [Валеева-Сулейманова, 2006, с. 595]. Шул ук вакытта ислам һәм милли тематика буенча иҗат итүчеләр интерпретацияләрендәге аерманы Көнбатыш Европа һәм Ватан сынлы сәнгатенең иң яхшы казанышлары синтезын чагылдырган «ислам сәнгате» традицияләре тәшкил итә.

Н.И. Фешин исем. Казан сәнгать училищесының бүгенге үсеш этабында үз идея-художество системасы формалаша, ул үзенең күп кенә аспектларында

сәнгать белеме бирү өлкәсенең үзәген тәшкил иткән академик мәктәп һәм Европа колоризмы традицияләренә нигезләнеп, шулай ук милли һәм дини традицияләргә дә актив мөрәҗәгать итә.

Шулай итеп, Казан сәнгать мәктәбенең «үз йөзен» формалаштыру төрле мәдәниятләр һәм традицияләрнең үзара йогынтысы, бер-берсен баетуы аша гамәлгә ашырыла.

**Искәрмәләр**

[1] «Ислам сәнгате»н киң мәгънәдә аңларга кирәк, чөнки ул сәнгать белеме арсеналының дини-культ характерындагы предметлары артефактын гына түгел, ә китап графикасы, Көнчыгыш миниатюралары, көнкүрештәге төрле әйберләр һ.б. ларны да колачлый.

[2] 1915 елга кадәрге мәктәп тарихын тирәнтен өйрәнүчеләр: *Ключаевская Е.Т.* Из истории художественной жизни Среднего Поволжья конца XIX – первой трети XX века. (Роль Казанской художественной школы в подготовке мастеров изобразительного искусства): дис. ... канд. искусствоведения. Л.. 1986; *Даричева Е.Н.* Традиции художественного образования в подготовке специалистов в профильных ССУЗ: дис. ... канд. пед. наук. Казань. 2001.

[3] Сәнгать белеме кандидаты, Татарстан Республикасның атказаган сәнгать эшлеклесе Петр Максимилианович Дульский (1879–1956) – сәнгать тарихы, сәнгать тәнкыйте һәм педагогикасы, музей төзелеше һәм һәйкәлләрне саклау, экспозиция-күргәзмәлелек, редакцион-нәширлек өлкәсендә бәяләп бетергесез өлеш керткән шәхес. Ул республикада рәссамнар һәм архитекторларның иҗади берлекләре эшчәнлеген оештыруга да зур көч куйды. Аның сәнгать белеме өлкәсендә түбәндәге фәнни тикшеренүләре аеруча мактауга лаек: *Дульский П.М.* Памятники Казанской старины. Казань, 1914; *Дульский П.М.* Искусство казанских татар. М., 1925; *Дульский П. М.* Искусство Татреспублики за годы революции. Казань, 1929; *Дульский П.М.* Оформление татарской книги за революционный период. Казань, 1930.

[4] Нәкъ менә шул вакыттан башлап студентларның эше тулырак һәм аерым-аерым тәкъдим ителә башлады. Ул чорга кадәр, 1895–1930 еллардагы эшләрне исәпкә алмаганда, күпчелек эшләрдә автор, педагог язмалары, кайчагында хәтта эшләнү датасы да күрсәтелми. Өлкән педагоглар истәлекләреннән аңлашылганча, студентларның гына түгел, хәтта педагоглар шәхесен дә аерып атау әдәпсезлек санала.

[5] Диплом җитәкчеләренең хезмәтен бәяләп бетермәү нәтиҗәсендә, 1980–2000 елларда диплом эскизлары өстендә эшләү өчен аларны фәкать кыска гына срокка – 2 айга чакыртып алалар. Ә менә рәсем, сынлы сәнгать һәм композицияләр буенча студентларның йөзен формалаштыру өчен педагоглардан җентекле эш һәм озак вакыт таләп ителә. Шуңа күрә дә эшләрдә, диплом җитәкчесеннән тыш, студентның тасвирый сәнгать теленә зур йогынты ясаган педагог исем-фамилиясен күрсәтүне да кирәк дип саныйбыз.

[6] Шамаил гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә «сыйфат, дәрәҗә» дип аңлатыла (Арабско-русский словарь / сост. Х.К. Баранов. Русский язык. 1976. С. 417). Татарларда шамаил сәнгатьле эшләнгән график әсәр санала, аны өй эченә гадәттә стенага, ишек өсләренә элеп куялар. Аның эчтлеген Коръән тексты тәшкил итә. Ул каллиграфик почерк белән язылган, әйләнә-тирәсенә орнаментлар төшерелгән була. Шамаилне бизәкләүдә төрле күренешләр, астраль, гамәли мотивлар, тарихи һәм көнкүреш сюжетары да кулланылырга мөмкин.

**Әдәбият**

*Большаков О.Г.* Ислам и изобразительное искусство // Труды Гос. Эрмитажа. Т. X. 1969. С. 142–153.

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Булгарское искусство // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. II. Казань: РухИЛ, 2006. 959 с.

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Декоративное искусство Татарстана (1920-е – начало 1990-х годов). Казань: Фэн, 1995. 192 с.

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Мусульманское искусство в Волго-Уральском регионе. Казань: Магариф, 2008. 223 с.

*Валеева-Сулейманова Г.Ф.* Ветры будущего. Зарисовка к портрету «Дастана» // Казань. № 3–4. 1997. С. 63.

*Валеева-Сулейманова Г.Ф., Шагеева Р.У.* Декоративно-прикладное искусство казанских татар. М.: Советский художник, 1990. 216 с.

*Ванслов В.В.* О преемственности Российской и Императорской Академий художеств // Сб. ст.: к 250-летию Академии художеств. Русское искусство нового времени. Вып. 10. М.: Памятники исторической мысли, 2006. С. 5–10.

*Гавриляйченко С.А.* Очерк истории реформ «академического» художественного образования в России // История художественного образования в России. Вып. I–II. СПб.: Композитор. 2007. С. 240–300.

*Дубова О.Б.* Становление академической школы в западноевропейской культуре. М.: Памятники исторической мысли, 2009. 276 с.

Ислам: Энциклопедический словарь. М.: Наука, Главная редакция восточной литературы, 1991. 315 с.

Персидская живопись и рисунок XV–XIX веков в собрании Эрмитажа. Каталог выставки на русском и английском языках / под общ. ред. М.Б. Пиатровского. СПб.: АО «Славия», 1996. 376 с.

*Полякова Е.А., Рахимова З.И.* Миниатюра и литература Востока: Эволюция образа человека: Альбом. Ташкент: Изд-во лит. и искусства, 1987. 288 с.

*Султанова Р.Р.* Искусство новых городов Республики Татарстан (1960–1990 гг.). Казань, 2001. 196 с.

*Улемнова О.Л.* Искусство графики Татарстана 1920–30-х годов: дис. .. канд. искусствоведения. Казань – Москва. 2004.

*Червонная С.М.* Вкус заздравной чаши. Из истории создания Союза художников Татарстана // Казань. 2006. № 8–9. С. 37.

*Червонная С.М.* Искусство и религия: Современное исламское искусство народов России. М.: Прогресс – Традиция, 2008. 552 с.

***Гыйльметдинова Ольга Александровна,***

*Н.И. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесы директоры*

УДК 745

*Г.С. Мохтарова*

# КОРАМАЛАРДАН ТЕГЕЛГӘН «ҚҰРАҚ» ҺӘМ АНДА ДӨНЬЯНЫҢ МОЗАИК КАРТИНАСЫ

Статья посвящена изучению специфики техники лоскутного шитья курак у казахов. Традиция техники «курак» рассматривается в комплексном единстве мировоззренческих, обрядовых, историко-этнографических компонентов. Составление композиции из различных лоскутков ткани представляется как философия построения мозаичной картины мира и темы единства многообразия. Особое внимание уделяется изучению значения лоскута как оберега, медиатора, транслятора традиций в казахской культуре. Приводится классификация традиционных текстильных изделий, выполняемых в технике казахского курака. В качестве примера приводится традиция подготовки лоскутного одеяла «курак корпе», как обязательного атрибута в приданом казахской невесты «жасау» и пошив лоскутной рубашки для младенца «ит койлек» и др.

**Ключевые слова:** пэчворк, курак, стегать, лоскутное шитье, мозаика, орнамент, традиция, приданое, лоскут, оберег, единство, многообразие.

Пэчворк – ул төрле төстәге һәм үлчәмдәге тукыма кисәкләреннән мозаика тегү техникасы («patchwork» инглизчәдән рус теленә «төрле төстәге корамалардан тегелгән әйбер» дип тәрҗемә ителә). Безнең эрага кадәр Мисырда газәл тиресеннән эшләнгән орнамент пэчворкның иң борынгы үрнәкләреннән санала.

Пэчворк чыгышы белән рәсми рәвештә Англиянеке саналса да, дөньядагы илләрнең һәркайсында диярлек корамаларны тегеп эшләүнең үзләренә генә хас техникасы бар. Бүгенге көндә АКШта һәм Япониядә пэчворк һәм артквилт сәнгате киң үсеш алган. Пэчворк техникасының килеп чыгышын тукыманы экономияләү һәм аның калдыкларыннан максатчан файдалану белән бәйләргә була. Әлеге мәкаләдә сүз казакъ пэчворкы – «құрақ» мисалында тукыма кисәкләренең фәлсәфи һәм сакраль мәгънәсе һәм аның милли традицияләрне тоташтырудагы роле турында барачак.

Һәр халыкның гадәт һәм йолалары кеше яшәеше циклларыннан (туу, мохиткә җайлашу, ярәшү, туй, җирләү) чыгып урнаша. Казакъларда корамалардан мозаикалар эшләү сәнгате туй һәм башка йолалар белән бәйле рәвештә ныгыган.

Казакълар пэчворкны «құрақ» (kurak) дип атыйлар, ул казакъ сүзе «құрау»дан алынган, ягъни төрле төстәге тукыма кисәкчекләрен катнаштырып тегелгән әйберне аңлата. Һәм, шуннан чыгып, корамалар тегү техникасын да «құрақ» дип йөртәләр. Казакъ декоратив-гамәли сәнгатендә тукыма кисәкләреннән тупланган бизәкләр спектры аеруча бай.

Тукыма кисәкләрен ялгап эшләнгән юрган һәм карават япмасын – «құрақ көрпе»не казакъларда килен бирнәсе буларак

файдаланганнар; идәнгә җәеп утыру өчен тар итеп сырып эшләнгән «құрақ төр көрпеше»нә хөрмәтле кунакларны утыртканнар; бер кеше өчен генә аска салып утыра торган мендәрчек – «құрақ көпшiк» тә теккәннәр; тышлыгын тукыма кисәкләрен бер-берсенә ялгап «құрақ жастық» эшләгәннәр; бишек өчен корамалардан «құрақ бесiк көрпе» теккәннәр; бала биләү өчен дә тукыма кисәкләреннән тупланган одеал – «құрақораулы көрпе»дән файдаланганнар; кыйпыклардан нәни балалар өчен сакчы күлмәк «қырық көйлек» яки «ит көйлек» теккәннәр; акыннар өчен ачык төсләрдәге кыйпыклардан ялгап тегелгән халат – «сал-сери шапаны», шаманнар өчен тыйнаграк төстәге тукыма кисәкләреннән мозаик халат – «бақсы шапаны» эшләгәннәр; төрле төстәге ситсы калдыкларыннан түбәтәй – «құрақ тақия» теккәннәр. Кыйммәтле тукыма кисәкләреннән дә «құрақ көрпе» эшләгәннәр.

Карамалардан эшләнгән юрган – «құрақ көрпе» кәләш бирнәсенең мәҗбүри бер элементы булып санала. Кызлары булган гаиләдә казакъларда «жасау» дип аталган бу бирнәне алдан ук әзерләгәннәр.

Бу традиция әлегә кадәр сакланган, казакъ осталары бирнә өчен ситсы кисәкләре файдаланып, юрган сыруны дәвам итәләр. Кыз бирнәсе составында алар аз дигәндә алтау (җидесе идәнгә салып утыру өчен, икесе – өскә ябыну, шулай ук пар мендәрләр комплектында да) булырга тиеш.

Кагыйдә буларак, ул юрганнарны туйга кадәр бөкләп бөкләп сандык өстенә өеп куялар. Алар өеме биегрәк булган саен кәләшнең дә «рейтингы» югарырак санала. Казакъларда урын-җир әйберләрен бер урынга өеп куйганда аларның төсләре гармониясенә әһәмият бирелә. Урын-җир әйберләрен матур һәм пөхтә итеп тирмәнең түренә үк өеп куялар. Казакъларда кызның пөхтәлеге һәм уңганлыгы аның куллары белән сандык өстенә оста итеп куелган юрганнар өеме аша бәяләнә. Казакъларда шундый мәкаль бар: «Қыздын жиған жүгiндей екен», ягъни «кыз җыеп куйган урын-җир әйберләредәй матур һәм пөхтә».

Казакъларның күренекле тикшеренүчесе – этнограф А.Х. Маргулан болай дип яза: «Казакъларның урта хәлле өлеше туй тирмәсен купшы итеп көйләргә тырышалар, аның өчен алар акчаны да, материалны да кызганмыйлар. Кәләш бирнәсе – «жасау» әзерләүгә алар бөтен мөмкинлекләрен файдаланалар. Әмма ул, кәләш өчен йолым акчасы күләменә түгел, ә кияү ягыннан бирнә хакын кайтару суммасына тәңгәл булырга тиеш» [Маргулан, с. 97].

Идәнгә җәеп утыру өчен эшләнгән стандарт көрпәләрдән тыш, кәләш бирнәсе составында «шай көрпе» (кәләш-киленнең үзенә эшләнгән юрганы) булу мәҗбүри, ул кунакларга һәм гаилә әгъзаларына чәй салып биргәндә аңа үзе утыра. Корамалардан эшләнгән юрган – «құрақ көрпе»гә, кәләш бирнәсе буларак, нинди мәгънә салынган соң?

Бу традиция тирән фәлсәфи мәгънәгә ия. Кәләшкә дип тукыма

кисәкләреннән «құрақ көрпе» теккәндә «қуралсын», ягъни «барысы да нык булсын» (ныклы гаилә оешсын) дип телиләр. «По представлениям казахов, лоскутные мозаичные подушка и одеяло были обязательными элементами убранства свадебной постели. Они должны были способствовать быстрому привыканию молодых друг к другу. Лоскутные вещи обеспечивали прочность брачных уз жастар құрылып кетеді. (букв.: «молодые устроятся»)» [Тохтабаева, с. 75–76].

«Қуралсын» теләге контекстында шулай ук «дуние қуралсын» дип тә әйтәләр, монысы гаиләнең матди ягын – байлыкмуллыкка ирешүне күздә тотып әйтелә.

Тукыма кисәкләреннән мозаик эшләнмәләр әзерләүне киңрәк мәгънәдә алганда, аның мөһим сакраль үзенчәлеге шунда: күп кисәкләрдән тупланган көнкүреш әйбере яшьләр аша тоташкан төрле нәселнең бербөтен булып, таркалмыйча яшәве төшенчәсенә барып тоташа. Әлбәттә, андый юрган кияүгә чыккан хатынкызга, яңа гаиләдә үз әти-әнисе өендә яшәгән чагын хәтерләтеп, туган ягы белән бәйләнеш тоту функциясен дә үти.

Корама юрган ялгап тегү һәм сыру техникасы ярдәмендә әзерләнә. Бу техниканы казакълар «сыру» яки «сырып тігу» дип атыйлар.

Мәхмүт Кашгарыйның (IX гасыр) «Диване лөгатет-төрк» сүзлегендәге «sïrï» нык итеп тегү, сыру дигәнне аңлата. Казакъларның «сыру» сүзе дә нәрсәне дә булса тоташтырып тегү, сыру мәгънәсенә ия. Алардагы киез келәмгә дә шул «сыру» фигыле белән бәйләп, «сырмак» диләр [Древнетюркский, с. 505].

Шулай итеп, корамалар ялгау гына түгел, киез келәмнәр эшләү техникасы да «сыру» сүзе белән бәйләнгән. Тәбәнәк кенә өстәл янәшәсендә утырырга җайлы һәм җылы булсын өчен, «құрақ көрпе» (тукыма кисәкләреннән әзерләнгән идән матрасы) өстенә «текемет» (киез келәм) салганнар. «Құрақ көрпе»не кроватька да (матрас өстенә) җәйгәннәр.

Корамалардан эшләнгән юрган эченә сарык яки дөя йонын юка гына итеп таратып җәйгәннәр. Аның өчен йонны, иң элек, чүпләрдән арындырганнар, юып киптергәннәр һәм теткәннәр. Корама юрганның өске ягы гади генә геометрик орнаментлар белән төрле төстәге затлы тукыма кисәкләреннән тегелгән. Геометрик формалардан «ушбурыш» (өчпочмаклык), «ромб», «жулдыз» (йолдыз), «тұмарша» (бөти), «сегіз жапырақ» (яфрак) аеруча киң кулланыла.

Тукыма кисәкләреннән тегелгән мозаик эшләнмәләрне анализлаудан күренгәнчә, зооморф системадагы мөгезләләр мотивы, аеруча «қошқар мүйіз» (кышкар мөгезе) еш очрый. Ул матди муллык һәм мал асраучының җитешлелеген аңлаткан һәм күчмә халыклар мәдәниятенең иң борынгыларыннан санала. Корамаларны ялгап бизәкләр эшләү техникасы өчен «сынық муйіз» (сынык мөгез) аеруча кулай мотив булып исәпләнә. «Құрақ көрпе»не (корамалардан эшләнгән озын юрган-матрасны) гадәт-

тә тирмәнең «төр»енә (түренә) җәяләр. «Төр» ул тирмәнең ишеккә каршы ягы. Ул изге урын санала һәм анда хөрмәтле кунакларны утырталар. Бу юрганны «төр көрпе» дип тә атыйлар.

«Төр құрақ көрпе»не бәйрәм вакытларында аерым хөрмәткә лаек кунаклар өчен җәяләр. Ачык төстәге ситсы кисәкләре, тоташтырып теккәч, язгы даланы, зәңгәр күл өстен хәтерләтә. Төрле төсләрдәге корамалар җыелмасы яшел үлән, кызыл һәм сары лалә чәчәкләр һәм мәкләр сыман күренә.

Төсләрнең психофизиологик тәэсире нәтиҗәсендә ачык матур кыйпыклардан эшләнгән юрган өй эченә бәхет һәм аһәңлелек биреп тора. Тукыма кисәкләреннән эшләнгән юрган һәм матраслардан тыш, казакъларда әле тагын шундый ук юл белән тегелгән «көпшік» (күпчек, кечкенә миндәр) тә була.

Казакъларның традицион мәдәниятендә корамаларны ялгап әйберләр эшләү кияүгә бирәсе кызлары булган гаилә өчен хас. Бу эшкә кыз балаларны кечкенәдән үк өйрәткәннәр. Тукыма кисәкләреннән бизәкләр формалаштырып тегү процессы кызларда сабырлык тәрбияли, әйберне саклап тотарга, төсләрне дөрес сайларга, пропорцияне төгәл билгеләргә өйрәтә.

Казакъ мәдәниятендә корамалардан орнаментлар эшләп тегү техникасы кебек феноменаль шөгыль сакраль һәм тылсымлы мәгънәгә ия. «Лоскут имел определенный семиотический статус, судя по его использованию в свадебном, похоронном, лечебном и прочих действах. С ним связывались благопожелательные и охранные понятия. Важная роль лоскута заключалась в функции медиатора, т.е. в выполнении миссии передатчика определенных качеств или свойств от одного человека другому» [Джексенбаева, с. 43].

Тукыма кисәкләрен казакълар «жыртыс» диләр. Ул кисәкләр билгеле бер формада (30×30 см яки 50×50 см) булырга тиеш. Казакълар тукыма кисәкләренә гаилә йолалары уздырганда мөһим саналган символик һәм изге теләктәге бүләк дип карыйлар. «В казахской среде и по сей день считается, что лоскуты «жыртыс» заключают в себе благодать – удачливость, богатство, плодовитость и счастье семьи, выдающей замуж дочь, празднующую появление наследника и т.д.» [Октябрьская, Сураганова, с. 400].

Мәсәлән, казакъларда туй вакытында кияү һәм туганнары ягыннан «кәде» (тукыма кисәкләре) бирү йоласы бар. Кияүнең мондый бүләкләрен хатын-кызлар үзара бүлешәләр. Бу йола хакында шундый мәкаль дә бар: «Қалынсыз кыз булса да, кәдесез куйеу жок» («Калымсыз кыз булса да, «кәде»сез кияү булмый») [Аргынбаев, с. 191].

Тукыма бирүнең әһәмияте зур. Әйтик, озак гомерләр уңышлы яшәп үлгән кешене күмгәндә дә өләшәләр аны. Бу очракта ул тукыманы «тәбәрік» дип атыйлар, һәм алган кеше аны «озын гомергә» дип саклап тота.

Элек «тәбәрік» яки «жыртыс» сыйфатында мәетнең исән чакта кигән киемнәреннән ертып

алынган кисәкләрне өләшкәннәр, бу йола үлгән кешенең теге дөньяга озатучыларга үзенчәлекле бүләге булып саналган. Хәзер инде алар урынына яңа тукыма, әзер яулыклар яки сөлгеләр тараталар. Мәетне озату йоласы вакытында бу эшләрне аның якыннары арасындагы хатын-кызлар башкара. Алар тукыма сатып алып, аны зур булмаган кисәкләргә бүләләр. Батыр ир-ат үлсә, аның киемнәрен кискәләп, алардан балалар өчен бөтиләр тегәләр. Шулай ук баланы кыю, батыр булып үссен өчен, батырларча гомер кичереп вафат булган ир-ар күлмәге итәгенә салу гадәте дә бар. Ә инде күп балалар тудырып үстергән һәм йөз яшькә җитеп үлгән ананың баш яулыгын кисәкләргә бүлеп тараталар.

Мондый традицияләр казакъларда «ырым» төшенчәсе белән бәйле. Ырым – ул төрле ышанулар белән бәйле символик йолаларны үтәү. Әйтик, эшләре һәрчак уңышлы барган, хөрмәт яулаган өлкән кешенең нинди дә булса әйберенә ия булганнан соң, үз тормышың уңайланып китү кебек символик характердагы күренешнең чагылышы. «Жуғысты болсын» (ягъни сезгә уңышлар юлдаш булсын, һәм туегыз, бәйрәмнәрегез булсын) төшенчәсе дә «ырым» белән бәйле. «Являвшиеся воплощением ритуалов «ырым» являлись лоскуты, собранные и соединенные в формате новой вещи, становились материализацией идеи счастья и благополучия семьи, рода и клана» [Октябрьская, Сураганова, с. 400]. Кайчандыр бөтен булган тукыма кисәкләреннән яңа чынбарлык төзү физик кына түгел, ә социаль яктан да бербөтенне формалаштыра. Элек бер генә зат ия булган әйбер күпләрнекенә әйләнә һәм, шуңа нигезләнеп, аларны үзара берләштерә. Тукыма кисәкләрен бүлешү һәм «жыртыс» тарату йоласы әлеге төркемнең уртак язмыш нигезендә үзара тагын да ныграк берләшүенә йогынты ясый.

Кешелек мөнәсәбәтләренең асылын тәшкил иткән өлешләрне, бәхет һәм яшәү көчен бүлешү социаль бәйләнешларны хәрәкәткә китерә. Символик рәвештәге үзара бүләкләр алышу анда катнашучыларның даими кулланылыштагы кешелек кыйммәтләре каршында җаваплылыкларын арттыра [Октябрьская, Сураганова, с. 400].

Казакъларда кечкенә бала өчен иске кием калдыкларыннан күлмәк тегү кебек кызыклы йолага аерым тукталып үтик. Чиста итеп юылган иске чүпрәк кисәкләреннән тегелгән күлмәкне балага туган көнендә үк кидерәләр һәм ул аны кырык көн дәвамында кияргә тиеш була. Корама күлмәк бала сәламәт һәм көчле булып үссен дигән теләктәге бөти ролен үти. Аны «ит-көйлек» («эт күмәге») дип атыйлар. «Сразу после рождения ребенка заворачивали в кусок старой, но чистой ткани или в чистую, но старую одежду пожилого, благополучного, здорового человека, например, штаны деда или подол платья бабушки ребенка» [Антипина, с. 1].

Бу йола кешене борынгы бабаларының күзгә күренмичә генә үз балаларын саклавына ишарә-

ли. Ул төрле төстәге чүпрәктән туника рәвешендә туры җиңнәр утыртылып тегелә, алгы ягының урта бер җиреннән вертикаль итеп икегә бүленә. «Ит-көйлек»-не, балага кидергәнче, кайсы да булса этнең башына салып алалар һәм «ит опа, ит жаксы» («эт яхшы») диләр. Шулай ук «ит кырык жанды» («этнең кырык җаны бар») дигән борынгыдан килгән ышану да яши, бу – этнең чыдам, яшәүчән булуы турында сөйли. Күчмә казакълар этне хуҗаның йортын һәм бүреләрдән терлекләрен тугры саклаучы буларак югары бәялиләр. Эт җитез чапкын ат, ау бөркете һ.б. кебек җиде хәзинәнең берсе булып санала.

Элек яңа туган балалар еш үлә торган гаиләләрдә, күз тиюдән саклый дип, тукыма кисәкләреннән кечкенә юрганнар эшләгәннәр. Шулай ук җиде йорттан җыелган җиде кораманы ялгап бала күлмәге дә теккәннәр (жеті жерден жеті құрақ). Ул күлмәкнең итәк һәм җиң очлары бөгелми калдырылган («етегін қайырмайды»). Җөйләре дә тышкы яктан эшләнгән. Монысы бала тәненә уңайлы һәм аның үсешен, теле ачылуын һ.б.ны тоткарламасын өчен шулай тегелгән. «Ит-көйлек»не гадәттә балага үз әнисе теккән; соңыннан да аны беркемгә дә бирмәгәннәр, үзләрендә саклаганнар.

Корамалар шаманнар йолаларында да алыштыргысыз атрибут саналган. Шаманның чапанын тукыма кисәкләрен ялгап теккәннәр һәм аңа кечкенә шөлдерләр (бубенчики) такканнар. Изге агачка («аулие агаш»ка) табыну йоласы вакытында шул агачның ботагына киемнең бер урыныннан ертып алынган тукыма кисәге яки нинди дә булса материя бәйләү гадәте булган. Әйтеп үтелгән йола һәм гадәтләрнең күбесе исламгача чорда ук барлыкка килгән, аны корамалар ялгап тегү һөнәренең борынгылыгы факты дәлилли.

Пэчворк техникасы тарихы да борынгы күчмә халыклар заманына ук барып тоташа. Бу төр һөнәрнең барлыкка килүе тарихи чорның башлангычына ( б.э.к. беренче меңьеллыкка) карый, һәм алар генетик яктан борынгы күчмә халыклар культурасына (Таулы Алтай һәм Җидесу курганнары табылдыклары, б.э.к. VI–V гасырлар) кагылышлы корамаларны ялгап тегелгән әйберләр табылу белән расланалар.

1940 еллар ахырында рус галиме С.И. Руденко тарафыннан Таулы Алтайның бозлыклы курганнарында табып алынган әйберләрдән күренгәнчә, корамалардан, предметның формасына туры китереп, композицияләр төзү һөнәре борынгы күчмә халыклар мәдәниятендә үк формалашкан булган. «В Пазырыкских курганах сохранились остатки одежды меховых кафтан (верх оттого из них выделан в виде мозаичного узора» [Маргулан, с. 34].

Киез келәмнәр («сырмак»-лар) арасында борынгы, сирәк очрый торган ысул – инкрустацияләп төзү технологиясенә нигезләп, төрле төстәге киез кисәкләрен ялгап эшләннәре дә бар. Сүз уңаеннан шуны дә әйтергә кирәк, киез келәмнәр

(«сырмак»лар) аппликация юлы белән, ягъни төрле төстәге киезләрдән кисеп алынган орнаментларны алдан әзерләнгән бизәк эзе буенча тоташ киезгә куеп, читләреннән шнур-җепләр ярдәмендә тамбурлы җөй белән беркетеп тегәләр.

Аппликацияле киез келәмнәр төрки халыкларның күбесендә кулланыла. Әмма «сырмак»ның тукыма кисәкләреннән «құрақ» тегү принцибына, мозаика техникасына нигезләнеп эшләнгән төрләре күбрәк казакъларда һәм кыргызларда очрый. «Известно, что технология мозаичных войлочных ковров совсем не знакома другим народам средней Азии» [Антипина, с. 148]. Рубрук кыпчакларның җәйге тирмәләре бизәлеше хакында болай дип яза: «Именно они (кипчаки) сшивают цветной войлок или другой, составляя виноградные лозы и деревья, птиц и зверей, и они делают подобные жилища настолько большими, что те имеют иногда 30 футов в ширину» [Рубрук, с. 85].

«Құрақ» сәнгате өчен симметрия законына буйсынган пропорциялелек мөһим: «Казахским мозаичным изделиям “құрақ” присущ лаконизм изобразительного языка и строгость стиля, использование исключительно геометрических мотивов, четкий ритм и динамика в построении элементов, контрастные локальные цветовые сочетания» [Джексенбаева, с. 7].

«Құрақ»ның өске ягы өчен гадәттә рәсемсез тукымалар сайлаганнар, чөнки классик төслар кушылмасын этник аңлау төсләрне дөрес урнаштыру белән бәйләнгән. Тукыма кисәкләреннән мозаик әйберләр эшләү технологиясе җиңеллеге белән аерылып тора. Анда шаблоннар яки трафаретлар кулланылмый. Корамаларны күз үлчәме, ягъни кул бармаклары, уч һәм куллар үлчәме белән чамалап кына кисеп алалар.

Төп фон һәм бизәкләрнең пропорциональ мәйдан биләве, шулай ук сайланган төсләрнең кискен аерылып торуы сәбәпле, фон да өстәмә бизәк буларак кына кабул ителә. «Құрақ» сәнгатендә, форма бирүче элементларның чикләнгәнлегенә карамастан, орнаментларның геометрик, зооморф, үсемлек, космогоник бизәкләрен төсләр һәм формалар чиратлашуы ярдәмендә интерпретацияләү мөмкинлеге бирелә.

«Құрақ» сәнгатенең символик үзенчәлеге корамалардан эшләнүендә генә түгел, ә бизәкләр сайланышы һәм аларның композицияләрендә дә чагыла. Бизәкләре ниндидер яктылык һәм җылылык идеясе белән сугарылса, композициясе дөньяның космогоник картинасын күзалларга ярдәм итә. Аларда иң гади элементлар – өчпочмаклыклар, ромб, квадратлар, әвернә, алтыпочмаклык, сигез чатлы йолдызчык, хачсыман мотивлар, киртләчле һәм тешле медальоннар, туры һәм бормалы юл сыман бизәкләр һ.б. «Лоскуты вырезались в виде ромбов, квадратов. Эти ковры были нарядными. До сих пор казашки так украшают верх легких матрацев – «курак корпеше», которые постилают на пол, усаживая гостей. Несмотря на различную технику

изготовления (вваливание, аппликация, мозаика), все войлочные и вышитые ковры можно считать однотипными. Их центр делится на квадратную сетку, в которую вписаны крестовины с парными завитками бараньих рогов. Композиция имеет две или одну ось, всегда симметрична, площади фона и узоров примерно одинаковы. Такая же композиция сохраняется и в ворсовых тканых коврах» [Маргулан, с. 147].

Аерым өлешләрнең пропорциональ тәңгәллеге, фонның һәм орнамент рәсеменең бер-берсен тулыландыру принцибы бердәмлек белән капма-каршылыкны тиңләштерә.

Картинада каршылыклар юк, ә сәнгати бердәмлек һәм аһәңлелек кенә хөкем сөрә. Корамалардан эшләнгән «құрақ»ның бизәлеше казакъ орнаменталарының геометрик, зооморф, космогоник һәм үсемлек мотивларыннан гыйбарәт.

Аның нигезен геометрик элементлар тәшкил итә. Казакъларның декоратив-гамәли сәнгать әсәрләренең барысына да, шул исәптән «құрақ»ка да күп төрле төсләр кушылмасы хас.

Корамалар өчен мамык тукыма, ситсы, сатин, постау, бәз (бүз), җитен тукыма, вельвет, хәтфә, плюш, атлас, саржа, ефәк, тафта, парча кулланыла. Корамалар өчен тукыманы махсус сатып алалар, шулай ук башка әйбер теккәндә калган яки бүләккә бирелгән кисәкләрдән дә файдаланалар. Тукымаларны сайлаганда фактурасы, калынлыгы буенча бер-берсенә туры килгәнен сайлыйлар. Ягъни хәтфә кебек төкле (ворслы) тукымага ярашлы итеп шуңа охшаш эшләнешлене, яки җиңелчәләрен дә бер-берсенә туры китереп алалар. Структурасы, тыгызлыгы туры килмәгән тукымалардан композиция төзү уңышлы булмый.

Корамаларны бер-берсенә ялгап тегүдә мозаика һәм аппликация ысуллары кулланыла. Зур форматлы эшләнмәләрдә, иң элек, композициянең блок өлешләрен әзерлиләр, аннан соң аларны тоташтыралар. Ә кечерәк үлчәмле эшләрне композициянең үзәгеннән башлап, тукыма кисәкләрен ялгый-ялгый як-якка үстерә баралар. Казакълар орнаментлар өчен, нигездә, чәчәксыман бизәлешле, каймалы элементлар сайлыйлар һәм аларны кабатлаулы ысул белән дә урнаштыралар.

Космогоник элементлар хач (тәре), түгәрәк, квадрат, ромб һ.б. формалар аша тәкъдим ителә. Алар арасыннан иң киң таралганы – квадрат эченә ромб («бота көз») урнаштыру. Бу элемент күп кенә композицияләрнең төзелешендә үзәк урынны били. Ромбны квадрат эчендә бирү эшләнмәгә тирәнлек һәм күләм эффекты өсти. Еш кына вертикаль буенча бер-бер артлы урнаштырылган өч ромб («үз көз») мотивы кулланыла, ул галәмнең өч өлешле системасын, дөнья агачын гәүдәләндерә. «Құрақ» өчен гадәттә дүрт ромб («төрт түлігі сай») рәсеме урнаштыру хас. Бер формалы яки охшаш мотивны кабатлау байлыкны, үрчемне арттыруга юрала, «уңышлы» башлангычка юл сала дип карала. Бер үк мәгънәгә ия дүрт

яки сигез элементны, үзәктән башлап, як-якка симметрияле итеп урнаштыру дөнья моделен, күчмә халыклар Галәмен чагылдыра [Джексенбаева, с. 12].

Өчпочмаклык та элек-электән көчле саклаучы дип бәяләнгән. «Құрақ»тагы өчпочмак формасы, еш кына, күз тиюдән саклаучы «тұмар» яки «тұмарша» буларак кабул ителгән. Өчпочмаклар тезмәсе күп очракта каймалап бизәкләү мотивы саналган. Андый тезмә – почмакларны («бұрыш») яки зигзагны («‹) хәтерләтә. «Құрақ көрпеше» читләре буйлап урнаштырылган зигзаг-өчпочмаклыклар тезмәсе «үш қиық» дип атала. Әле тагын «түйе өркеш» (таулар) варианты бар, анда байлык, азык муллыгы символы булган дөянең пар өркәчләре сурәтләнә. Тәре рәсеме яки әвернә дә композицион элементлар санала. Ул көнкүрешнең төп кагыйдәләрен, үзәк символын, пространствоны тәртиптә тоткан һәм дөньяның дүрт ягына юнәлдерелгән тамганы символлаштыра. Тәрегә (хачка) нигезләнгән композицияне сайлаган оста аңлы рәвештә гаилә, өй, нәсел иминлеген, гармониясен саклауга омтылган. Күп халыклар өчен хас булган космогоник символиканың нигезендә дә тәре (хач) ята, ул сигезнурлы йолдыз һәм баскычлы ромб рәвешендә гәүдәләндерелә. Сигезнурлы йолдызның («жұлдыз» яки «сегіз кырлы өрнек») башлангычы тәрегә барып тоташа һәм ул Кояш, йолдызлар, гомумән күк яктырткычлары идеясе белән бәйле рәвештә тәре (хач) семантикасын саклый. Баскычлы ромб исә Галәм көпчәге буларак кабул ителә.

Әһәмияте ягыннан мөһим саналган мотивлардан зооморфлар төркеменә түбәндәгеләр керә: «мүйиз» (тәкә мөгезе), «қос мүйіз» (пар мөгез), «қаз мойын» (каз муены), «өркеш» (дөя өркәче).

Кайсы да булса кошларны яки җәнлекләрне чагылдырган икенче бер мотивлар генезислары буенча зооморф мотив саналмыйлар. Аларның исемнәре фауна дөньясының башка вәкилләре формалары белән ассоциацияләшү буенча соңрак барлыкка килгән. Шундый мотивларның берсе – «тырна» (торна), ул күктә өчпочмакланып очкан торналар тезмәсен хәтерләтә. Бу мотив шулай ук «құс таңдай» (кошлар күге) буларак та мәгълүм. Кыйгачлап тезелеп очкан торналар белән ассоциацияләшүдән барлыкка килгән бу яңа исем казакълар орнаментында кошларның бөтеннән өлешләргә бүленү (канат – «құс канат», томшык – «құс тұмсык», муен – «құс мойын», «қаз мойын», эз – «құс із») принцибына нигезләнгән.

«Құрақ»ларны буй-буй бизәкләү техникасы да бар, кайбер төбәкләрдә аларны «кабырга» яки «чикурак» дип дә атыйлар. Шулай ук «қудық» (кое) элементы да кулланыла, ул полосадагы дүртпочмаклыкларда уртага таба кечерәйтелә барган бизәкләр аша коеның тирәнлеген аңлата.

Үсемлек мотивлары тагын да сирәгрәк очрый. Алар арасыннан сигезкырлы йолдыз рәвешендәге «гүл» (гөл) һәм кыек ромб яки бер якка кыйшаеп торган турыпочмалыкны хәтерләткән

«жапырак» (яфрак) мотивлары гына ешрак кулланыла [Шаханова, с. 10].

Шулай ук төсләр гармониясенә ирешүдә тукыма кисәген дөрес урнаштыру алымнарына тукталу да мөһим.

Төсләр семантикасында иң таралганнары түбәндәгеләр: зәңгәр төс – күк һәм күккә табыну символы; кызыл – ут, кояш; сары – гакыл; кара – җир; яшел – яз, яшьлек.

Келәмнәрне мозаика ысулында турыпочмаклы корамалардан ялгап эшләгәндә, алар турыпочмаклы ятьмәне хәтерләтәләр. Ромбларны очларыннан ялгап тегү «құрақ көрпе»дә әнә шундый ятьмә сыман бизәк барлыкка китерә [Шаханова, с. 403].

«Құрақ»ларны игътибар белән карасаң, казакъларның дөньяның төзелеше һәм образы турындагы күзаллауларын төшенү кыен түгел. Бу символика аның мозаик принцибына да, изге теләкләргә ия бизәкләренә һәм композициясенә дә салынган. Алардагы бизәкләр саклауга, бәхет, уңышлар, игелеклелек һәм сәламәтлек теләүгә юнәлдерелгән. Нәкъ менә шуның өчен корама эшләнмәләр һәр йортның мәҗбүри атрибутларыннан санала. «Символизм лоскутного дарообмена определяла дихотомия смерти-рождения и разрушения-созидания. Разрушение и последующее восстановление жизненного потенциала сообщества в череде смертей, рождений и свадеб дублировалось актами символического разъятия целого (жертвенной туши, ритуального угощения, тканых полотнищ) на части с перегруппировкой в перспективе коллективного счастья и доли для воссоздания целостности» [Октябрьская, Сураганова, с. 403].

Киң мәгънәдә алганда «құрақ»та синтез һәм эклектика тиңләштерелә. Корама эшләнмәләрнең символик үзенчәлеге берләштерүдән, төрле кисәкләрне бербөтенгә тоташтырудан гыйбарәт. Шуңа күрә «құрақ» техникасында интерпретация дә булырга мөмкин.

Хәзерге вакытта «құрақ»ны тукыма кисәкләреннән ялгап эшләү техникасы яңа интерпретацияләр белән байый. Әйтик, киемнәрне һәм сәнгати тукыма эшләнмәләрне бизәү элементы буларак та кулланыла башлады. Казакълардагы корамаларны ялгап тегү идеясе күптөрлелекнең бердәмлеген чагылдыра, «құрақ» техникасының башка элементлар белән органик кушылып китүе кешенең Галәм белән гармониягә юл табуын күрсәтә.

**Әдәбият**

*Антипина К.И.* Особенности материальной культуры и прикладного искусства южных киргизов. Фрунзе. 1962. С. 32.

*Аргынбаев Х.А.* Брак и семья у казахов (историко-этнографический сборник) / отв. ред. АН КазССР А. Маргулан. Алма-Ата, 1973. 328 с.

*Джакипбекова М.Ж., Жолдасбекова К.А., Болысбаев Д.С., Кенжебаева А.Н., Камалова Н.К.* Национальные традиции шитья курак в современном искусстве дизайна // Международный журнал экспериментального образования. 2014. № 8. С. 67–69.

*Джанибеков У.* Эхо... по следам легенды о золотой домбре. Алма-Ата: Онер, 1991. 304 с.

*Джексембаева А.М.* Казахские тканевые мозаичные изделия «құрақ»: автореф. дис. ... канд. искусствовед. Алматы, 2010. КазНАИ им. Т. Жургенова. URL: www.litart.acdemset.kz/files/Jeksembaeva.htm

*Джексембаева А.* Наследие казахских кураков. URL: http://ru.nomad-kazakhstan.kz/1796.html

Древнетюркский словарь. Л., 1969.

*Жукенова Ж.Д.* Художественные образы. Казахское народное декоративно-прикладное искусство. Астана: КазНУИ, 2014. 20 с.

Казахские кураки: материалы международной научно-практической конференции, университет «Кайнар». Алматы, 2008. С. 227–231.

*Маргулан А.Х.* Казахское народное прикладное искусство. Алма-Ата: Онер. Т. 1. 1986. 256 с.

Наследие казахских кураков и перспективы их развития: материалы международной научной конференции, ГМИ РК им. А. Кастеева. Алматы, 2009. С. 144–155.

Несовременное искусство и традиционные мозаичные тканевые изделия: материалы международной научно-практической конференции, АБМ «Сымбат». Алматы, 2008. С. 496–500.

*Октябрьская И.В., Сураганова З.К.* Лоскуты на счастье. Вещной мир казахской культуры – живая традиция. История историко-культурное наследие и духовные ценности России. М.: Росспэн, 2012.

Обычаи и обряды, связанные с казахскими тканевыми мозаичными изделиями «құрақ» // Поиск (Алматы). 2008. № 4 (1). С. 119–122.

*Писарчик А.К., Хамиджанова М.А.* Узорные изделия из кусочков материи (курома или курак) // Таджики Каратегина и Дарваза. Душанбе, 1970. вып. 2. С. 203–224.

*Рубрук В.* Путешествие в восточные страны. Перевод А.И. Малеини. СПб., 1911.

*Шаханова Н.* Традиционная одежда казахов. URL: http://ru.nomad-kazakhstan.kz/1779.html

Технология изготовления казахских корпе (лоскутные одеяла). URL: www.orenburg-nasledie.ru/index.php/texniki-texn/114-laskutnoe-odeyalo

*Тохтабаева Ж.Ш.* Шедевры Великой степи, Алматы, 2008, 240 с.

URL: www.rae.ru/meo/?section=content&op=show_article&article_id=5793 (дата обращения: 19.06.2015).

*Мәкаләдә кулланылган фотолар (журналның ахырындагы кушымтада) авторның шәхсән үзе тарафыннан 2015 елның 12 октябрендә Казакъ ханлыгының 550 еллыгын бәйрәм иткәндә төшереп алынды һәм эшләнмәләр авторлары – халык осталары рөхсәте белән нәшер ителә.*

***Мохтарова Гайни Сейсен кызы,***
*фәлсәфә фәннәре кандидаты, доцент,*
*Казакъ милли сәнгать университетының сәнгать факультеты*
*Сценография һәм декоратив сәнгать кафедрасы мөдире*

УДК 332.142.6

*И.И. Җиһаншин*

# ТӨБӘК ДӘРӘҖӘСЕНДӘГЕ ТАБИГЫЙ ТЕРРИТОРИЯЛӘРНЕ ТОТРЫКЛЫ ҮСТЕРҮ ПРОБЛЕМАЛАРЫ ҺӘМ АЛАРНЫ ХӘЛ ИТҮ ЮЛЛАРЫ

Статья посвящена анализу региональных проблем устойчивого развития природных территорий и возможным путям их решения в условиях Республики Татарстан. Развитие хозяйств органического производства может рассматриваться как перспективное направление при разработке региональных программ устойчивого развития территорий. Проведенные исследования показали, что хозяйства Республики Татарстан, занимающиеся производством органической продукции, имеют высокий потенциал для развития туристкой деятельности с использованием элементов природоохранной структуры.

**Ключевые слова:** органическое сельское хозяйство, особо охраняемые природные территории, устойчивое развитие, Республика Татарстан.

Җәмгыять ихтыяҗлары арта баруы һәм биосфераның аларны тәэмин итә алмавыннан килеп туган каршылыклар планетада яшәүне куркыныч астына куя. Берләшкән Милләтләр оешмасының 1992 елда Рио-де-Жанейрода узган «XXI гасырга көн тәртибе» конференциясендә кешелекнең тотрыклы үсешкә ирешү буенча гамәли планын кабул итүнең төп сәбәбе иң тискәре сценарийны – глобаль экологик һәлакәтне күз алдына китерүдән килеп туды. Биредә җәмгыятьнең икътисади үсешенең табигый ресурслардан нәтиҗәле файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау зарурлыгы, аның хәзерге вакытта яшәүче кешеләрнең генә түгел, ә киләчәк буыннарның да ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тиешлеге күздә тотыла [БМО сайты: http://www.un.org].

Тотрыклы үсеш стратегиясе дөнья хуҗалыгының барлык тармакларына, шул исәптән авыл хуҗалыгына да тәэсир итеп, күпчелек дәүләтләр һәм дөнья төбәкләренең икътисади нигезенә дә кагыла. Бу концепция дүрт мөһим принципка нигезләнә: хәзерге вакытта яшәүче барлык кешеләрнең төп ихтыяҗларын канәгатьләндерү, планетаның бөтен халкы өчен әлеге канәгатьлендерүнең тигез стандартларын булдыру; табигый ресурсларны сак куллану; киләчәк буыннарның төп ихтыяҗларын тормышка ашыру мөмкинлеген саклау [Рио-де-Жанейро декларациясе: http://www.un.org]. Шулай итеп, территорияләрнең тотрыклы үсеш стратегиясе икътисади, социаль һәм экологик факторлар арасында оптималь ярашуны күз алдында тота. Аның икътисади максаты һәм рентабельлелеге шул ук вакытта социаль гаделлек һәм экологик куркынычсызлык таләпләренә дә җавап бирергә тиеш.

Традицион авыл хуҗалыгы әйләнә-тирә мохитне глобаль

һәм региональ масштабларда антропоген пычрату чыганагы булып тора. Синтетик минераль ашламалар, пестицидлар, генетик модификациягә дучар булган организмнар, антибиотиклар һәм үсеш гормоннары куллану авыл хуҗалыгы продукциясенең кешеләр сәламәтлеге өчен куркыныч сыйфатларын арттыра һәм тотрыклы үсеш принципларына җавап бирә торган альтернатив, экологик юнәлешле авыл хуҗалыгы җитештерүенә күчү мәсьәләсен кискен куя. Дөньяның күп кенә илләрендә соңгы дистә елларда тере организмнарда тискәре реакция китереп чыгармый торган һәм экологик чиста территориядә табигый азык-төлек җитештерүгә юнәлдерелгән органик авыл хуҗалыгы сизелерлек үсеш алды.

1963 елда FAO UNESCO ЮНЕСКО һәм WHO Food Standards Programme тарафыннан кулланучылар сәламәтлеген саклау һәм азык-төлек продуктлары белән намуслы сәүдә алып бару максатында халыкара стандартлар булдыру өчен эшләнгән Алиментариус кодексы органик авыл хуҗалыгын, «җитештерү белән идарә итүнең синтетик материаллар куллануга капма-каршы рәвештә, төрле агрономик, биологик һәм механик методлар ярдәмендә система эчендәге махсус функцияләрне үтәүче, аграр экосистеманы, биологик төрлелекне, биологик циклларны һәм туфракның биологик активлыгын стимуллаштыручы һәм көчәйтүче комплекслы системасы», – дип билгели [Codex Alimentarius, 1999].

Органик авыл хуҗалыгы Европа Берлеге илләрендә актив үсә, анда аны үстерү өчен күп эш башкарыла, шул исәптән органик игенчелек принциплары һәм кагыйдәләре эшләнә [European Union Council Regulation No. 2092/91; European Union Council Regulation No. 834/2007; European Union Council Regulation No.889/2008]. Әлеге документлар нигезендә органик авыл хуҗалыгы авыл территорияләрен киңәйтүгә, шулай ук табигый мохитне саклауга ярдәм итеп, югары сыйфатлы азык-төлек җитештерү юлы белән азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итеп, комплекслы социаль роль үтәргә тиеш.

Россия Федерациясенең икътисади үсеш алган субъектларының берсе буларак, бөртекле культуралар, шикәр чөгендере һәм бәрәңге үстерү, шулай ук ит, сөт һәм йомырка җитештерүдә югары үсеш алган авыл хуҗалыгы булган Татарстан Республикасында соңгы елларда халыкның табигый азык-төлек продуктларына зур ихтыяҗы билгеләп үтелә.

Шул ук вакытта, Татарстанда органик игенчелек үсеше, тулаем Россиядәге кебек үк, формалашу стадиясендә икәнен дә билгеләп үтәргә кирәк. Җирле массакүләм мәгълүмат чараларында «экологик чиста туклану продуктлары» сатып алуга юнәлтелгән тәкъдимнәр күп. Әмма аларның органик игенчелек таләпләренә һәм стандартларына туры килүен билгеләү мөмкин түгел диярлек, чөнки республикада органик сертификацияләү системасы әлегә эшләми.

Әлегә Россиядә, милли органик стандарт кабул ителгән АКШтан яки Бердәм органик стандарт гамәлгә кергән Европа Берлегеннән аермалы буларак, органик җитештерү турында закон, бу закон астындагы актлар, аларны көйләүче кагыйдәләр, шулай ук сертификацияләү һәм аккредитацияләү органнары оештыру буенча процедуралар кабул ителмәгән. Органик продукцияләр буенча 2016 елда гамәлгә кертелгән 56508-2015 номерлы ГОСТ хәлне тамырдан үзгәртмәде, илдә әлеге стандарт буенча сертификация үткәрү өчен аккредитацияләнгән оешмалар юк. Сертификация вакытында үсемлекчелек, терлекчелек һәм азык-төлек продукциясе җитештерү өлкәсендәге авыл хуҗалыгы технологиясенең органик агроҗитештерү таләпләренә туры килүен бәяләү генә түгел, ә авыл хуҗалыгы предприятиесе урнашкан территориянең экологик хәлен интеграль бәяләү дә кирәк.

2015 елда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Экология проблемалары һәм җир асты байлыкларыннан файдалану институты хезмәткәрләре тарафыннан Татарстандагы фермер хуҗалыкларының органик агроҗитештерү таләпләренә туры килүенә карата тикшерү уздырылды. Аның нәтиҗәләре буенча республиканың 21 муниципаль районында 39 хуҗалыкны органик продукция чыгара дип сертификацияләргә мөмкин [Григорьян һ.б., 2016]. Барлык хуҗалыклар да экологик яктан чиста урыннарда ял итү, табигый һәм мәдәни мирас объектларына экскурсияләр, актив ял итү (балык тоту, коену, күймәләрдә йөрү һ.б.), хайваннар белән аралашу, уңыш җыюда һәм төрле чараларда катнашу (спорт, этнофольклор, күңел ачу һ. б.) кебек экологик юнәлешле туризмның төрле юнәлешләрен оештыру өчен яраклы кече һәм урта бизнес категориясенә керә.

Татарстан Республикасы территориясе буенча органик хуҗалыкларның урнашуына карап, аларның күпчелек өлеше республика башкаласы Казан шәһәре янындагы районнарда тупланган, бу, күп очракта, аларның киң кулланучыга юнәлгәнлегенә бәйле. Алар барысы да махсус саклана торган табигый, экологик имин территорияләрдә урнашкан, бу исә әлеге уникаль табигый мирас объектларына экскурсияләр оештырырга мөмкинлек бирә.

Махсус саклана торган табигый территорияләрнең региональ системасында төрле категориядәге саклау статусы һәм режимнары булган. Шуларга нигезләнгән федераль, региональ әһәмияттәге һәм җирле әһәмияттәге 171 объект исәпләнә [Дәүләт реестры, 2007]. Алар республиканың туристлык-рекреацион потенциалының мөһим өлешен алып тора. Әмма ул туристлык хезмәте күрсәтү программаларында тиешле чагылышны тапмый. Тикшерүләрдән аңлашылганча, махсус саклана торган табигый территорияләрдә туристлык-рекреацион эшчәнлекне үстерүнең төп проблемасы туристлык инфраструктура булмауга бәйле [Зиганшин, Иванов, 2016]. Бу, күп очракта, зур торак пунктлардан ерак

урнашу аркасында гына түгел, ә, иң элек, килүчеләрне каршы алу, кабул итүнең тиешле дәрәҗәдә оештырылмавы белән дә аңлатыла. Транспортка ерак булу, шулай ук начар юл инфраструктурасы уникаль табигать объектларына баруны катлауландыра.

Әлеге проблеманы хәл итүнең нәтиҗәле юлы – ул да булса, органик продукция җитештерү белән шөгыльләнүче яки җитештерүгә юнәлдерелгән хуҗалыклар базасында туризмны үстерү. Алар җирлекнең табигый, мәдәни-тарихи һәм башка ресурсларын рациональ файдалану һәм туристлар өчен экосистемаларның бөтенлеген бозмый торган продукт булдыру, җирле халыкны туристлык бизнесына җәлеп итүдән гыйбарәт. Шул ук вакытта, халыкның хәрәкәте чикләнгән катламын кабул итүне оештыру да, инфраструктур проблемаларны хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк [Зиганшин, Иванов, 2016]. Экологик-органик туризмның ял итүчеләр өчен дә, аларга хезмәт күрсәтүчеләр өчен дә өстенлекләре зур булуга карамастан, органик игенчелек тикшеренүләре хуҗалыкларның бер өлеше (25% ы) генә хәзерге вакытта туристлык хезмәте күрсәтүне актив үстерә. Шул ук вакытта, дәүләт тарафыннан ярдәм күрсәтелгән шартларда башка органик хуҗалыклар экологик юнәлешле мондый бизнесны үстерергә әзер.

Республика территориясендә экотуризмны үстерү проблемаларын һәм мөмкинлекләрен анализлау өчен SWOT-анализ үткәрелде (табл.), аның нәтиҗәләре органик продукция җитештерү белән шөгыльләнүче хуҗалыкларның туристлык эшчәнлеген үстерү, шул исәптән, махсус саклана торган табигый территорияләргә экскурсия сәфәрләре оештыру буенча да зур потенциалга ия булуын күрсәтте. Бу – күпчелек органик хуҗалыкларның махсус саклана торган табигый территорияләр янәшәсендә уңышлы урнашуы һәм, шулай ук, республикада халык арасында органик продукциягә ихтыяҗ арта бару белән бәйле. Органик игенчелек хуҗалыклары базасындагы әйтеп үтелгән өстенлекле якларны һәм тышкы мөмкинлекләрне эко-органик туризмны үстерүнең конкурентлы стратегиясе нигезе буларак карарга мөмкин. Алар файдалануга һәм тагын да киңәйтүгә юнәлдерелгән чаралар системасы аша тормышка ашырылырга тиеш. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, туризмны үстерү өлкәсендәге комплекслы проблемалар шактый кискен һәм системалы характерга ия. Экологик туризм Татарстан Республикасы территориясенең тотрыклы үсеше өчен мөһим элемент булырга мөмкин һәм булырга тиеш тә. Органик игенчелеккә нигезләнгән һәр аерым хуҗалыкка, шулай ук махсус саклана торган һәр конкрет табигый территорияләргә килүчеләрне кабул итү мөмкинлекләрен җентекләп өйрәнүгә фәнни якын килү таләп итеlә.

Таблица

Татарстан Республикасындагы махсус саклана торган табигый территорияләрне тотрыклы үстерү потенциалын SWOT-анализлау

| Көчле яклар | Көчсез яклар |
|---|---|
| – энергия һәм табигый ресурслардан рациональ файдалану;<br>– югары сыйфатлы табигый продукция җитештерү;<br>– органик игенчелек алып бару өчен яраклы туфрак-климат шартлары;<br>– территориянең югары табигый-рекреацион потенциалы;<br>– аеруча саклана торган табигый территорияләрнең үсеш алган системасы булу;<br>– республика халыкларының тарихы һәм мәдәнияте белән бәйле чаралар оештырылу;<br>– йорт һәм фермер хуҗалыклары составында урнашу һәм туклану инфраструктурасы булу;<br>– органик игенчелек хуҗалыкларының транспорт чараларына якын урнашуы;<br>– авыл районнарының уңай экологик шартлары. | – урнашу һәм туклану буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең түбән сыйфаты;<br>– туристларга хезмәт күрсәтү буенча белгечләр җитешмәү;<br>– органик игенчелек хуҗалыкларының мәгълүмати яктан җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителмәве;<br>– климат шартларына бәйле хезмәтләрнең сезонлы булуы;<br>– дәүләт тарафыннан инвестицион ресурслар һәм финанс ярдәме булмау;<br>– авыл кешеләренең үз йортларында чит кешеләрне кабул итәргә әзер булмавы;<br>– махсус саклана торган табигый территорияләрдә эшләнгән экологик маршрутлар һәм күзәтү мәйданчыклары булмау;<br>– органик игенчелек хуҗалыкларында күрсәтелә торган хезмәтләрнең һәм азык-төлекнең югары бәядә булуы. |
| **Мөмкинлекләр** | **Җитешсезлекләр** |
| – халык арасында экологик туризмның популярлыгы арту;<br>– авыл халкының матди хәлен күтәрү һәм авылда социаль-икътисади климатны яхшырту;<br>– туризмны үстерү хисабына өстәмә табыш алу;<br>– төрле туристлык хезмәтләрне үстерү өчен мөмкинлекләр;<br>– социаль реклама аша органик игенчелек хуҗалыкларының имиджын күтәрү;<br>– салым базасын киңәйтү хисабына республика һәм җирле бюджетларны тулыландыру. | – авыл туризмында норматив-хокукый базаның камил булмавы;<br>– авыл халкына эшмәкәрлек активлыгы җитмәү;<br>– күчмә туризм белән югары көндәшлек;<br>– табигый объектларның экологик торышы начарлану;<br>– авыл туризмы белән шөгыльләнүче органик игенчелек хуҗалыкларына ярдәм программасы булмау;<br>– махсус саклана торган табигый территорияләрнең сыйдырышлылыгын исәпкә алмау;<br>– рекреацион йогынты нәтиҗәсендә табигый байлыкларның экологик торышы начарлану;<br>– Россиядә һәм Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсенең гомуми кимүе. |

**Әдәбият**

ГОСТ Р 56508-2015. Продукция органического производства. Правила производства, хранения, транспортировки.

Государственный реестр особо охраняемых природных территорий в Республике Татарстан. Казань: Идель-пресс, 2007. 407 с.

*Григорьян Б.Р., Кольцова Т.Г., Сунгатуллина Л.М., Сахабиев И.А.* Оценка соответствия сельскохозяйственных предприятий Республики Татарстан требования органического производства // Российский журнал прикладной экологии. 2016. № 4. С. 40–45.

*Зиганшин И.И., Иванов Д.В.* Инфраструктурные проблемы развития туристско-рекреационной деятельности на особо охраняемых природных территориях и возможные пути их решения на региональном уровне // Императивы развития инфраструктуры гостеприимства в регионе: матер. межд. научной. Конф. Волгоград, 2016. С. 90–93.

*Зиганшин И.И., Иванов Д.В.* Потенциал развития доступного туризма на особо охраняемых природных территориях Республики Татарстан // Российский журнал прикладной экологии. 2016. № 2. С. 42–47.

Рио-де-Жанейрская декларация по окружающей среде и развитию [сайт]. URL: http://www.un.org/ru/documents/decl_conv/declarations/riodecl.shtml (дата обращения: 25.07.2017).

European Union Council Regulation No. 2092/91 of 24 June 1991 on organic production of agricultural products and indications referring thereto on agricultural products and foodstuffs // Official Journal of the European Union. 1991. L. 198. 101 p.

European Union Council Regulation No. 834/2007 of 28 June 2007 on organic production and labelling of organic products and repealing Regulation No. 2092/91 // Official Journal of the European Union. 2007. L. 189. 23 p.

European Union Council Regulation No.889/2008 of 5 September 2008 laying down detailed rules for the implementation of Council Regulation (EC) No. 834/2007 on organic production and labelling of organic products with regard to organic production, labelling and control // Official Journal of the European Union. 2008. L. 250. 84 p.

The Codex Alimentarius Commission and the FAO/WHO Food Standards Programme. Guidelines for the production, processing, marketing and labeling of organically produced foods. Rome (Italy), 1999. 91 p.

*Статья подготовлена в рамках выполнения мероприятия 3.5.4 Государственной программы «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014–2020 годы»*

*Мәкалә «2014–2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасының 3.5.4 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

***Җиһаншин Ирек Илгизәр улы,***
*география фәннәре кандидаты, доцент,*
*ТР ФА Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институтының өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 929

*М.Р. Булатова*

# ТЕЛ БЕЛГЕЧЕ, ДИАЛЕКТОЛОГ ҺӘМ ГАҖӘЕП ОСТАЗ
## (галимә Рамазанова Дөрия Бәйрәм кызына – 80 яшь)

Статья посвящена 80-летнему юбилею ученого-языковеда, доктора филологических наук, профессора Д.Б. Рамазановой. Многочисленные исследования ученого внесли большой вклад в развитие не только татарского, но и тюркского языкознания.

**Ключевые слова:** Дария Байрамовна Рамазанова, ученый, языкознание, история языка, татарская диалектология, лексикология, лексикография, экспедиции, монография, Атлас татарских народных говоров.

Тел белемендә, татар диалектологиясендә тирән эз калдырган филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе Дөрия Бәйрәм кызы Рамазановага 2018 елда 80 яшь тулды.

Д.Б. Рамазанова 1938 елның 17 сентябрендә Татарстан Республикасының Саба районы Пүкәл авылында туа. Шәмәрдән урта мәктәбен тәмамлагач, 1957–1963 елларда Казан дәүләт университетында югары белем ала. 1964–1967 елларда Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих (хәзер – сәнгать) институтының аспирантурасында укый һәм 1967 елдан башлап 2017 елга кадәр шул Институтның лексикология һәм диалектология бүлегендә баш фәнни хезмәткәр буларак хезмәт итә. Ул – 2015 елга чаклы Институтның гыйльми советы әгъзасы; шул ук Институтта һәм Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында диссертацияләр яклау советы әгъзасы да булып тора.

Танылган татар диалектологы Л.Т. Мәхмүтова җитәкчелегендә диалектология өлкәсендә алып барган фәнни тикшеренүләренә нигезләп 1970 елда «Урта Кама тирәсе татар сөйләшләре» дигән темага – кандидатлык, 1998 елда «Көнбатыш Урал ареалы татар сөйләшләре формалашуы һәм яшәешенең тарихи-лингвистик үзенчәлекләре» темасына докторлык диссертацияләре яклый.

Д.Б. Рамазанова – татар диалектологиясе, тел тарихы, лексикология, лексикография, терминология, ономастика, татар халкының этник тарихы, матди һәм рухи мәдәнияте өлкәләренә караган 500 дән артык фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләр авторы. Шуларның 30 ы – китап (шул исәптән 16 монография) һәм сүзлекләр рәвешендә дөнья күрә.

Дөрия Рамазанова, барыннан да элек, татар тел белемендә үз эшен яратып һәм нәтиҗәле эшләүче диалектолог. Ул үзенең 50 елдан артык гомерен татар диалектологиясенә хезмәт итүгә багышлый. Аның җитәкчелегендә һәм турыдан-туры катнашлы-

гында бихисап диалектологик һәм лексикологик экспедицияләр оештырыла, ул татарлар яши торган барлык төбәкләрне дә диярлек йөреп чыгып, бай диалекталь материал туплый. Аспиранты буларак миңа да аның белән бергә Татарстан, Башкортстан, Мари Эл, Удмуртия Республикаларына һәм Әстерхан, Омск өлкәләрендә уздырылган диалектологик һәм комплекслы экспедицияләрдә катнашырга һәм остазымнан күп нәрсәләргә өйрәнергә насыйп булды.

Д.Б. Рамазанова Урта Кама буе һәм Урал алды татар халык сөйләшләрен тикшерүгә аеруча зур көч куя. Татар диалектлары системасында урта диалектка караган Пермь краенда яшәүче татарлар сөйләшен, Башкортстан татарларының тепекәй сөйләшен, Татарстанның көнчыгышында минзәлә сөйләшенең әгерже урынчылыгын, Башкортстанның көнбатышында минзәлә сөйләшенең бәләбәй урынчылыгын, мишәр диалектына караган Башкортстанның көньяк-көнбатышында стәрлетамак сөйләшен, беренче булып, бүлеп чыгара.

Д.Б. Рамазанованың фәнни эшчәнлегендә характерлы һәм әһәмиятле үзенчәлекләрнең берсе – сөйләшләрне шул сөйләш вәкилләренең тарихы белән бәйләп тикшерү. Моның өчен аңа Мәскәү, Уфа, Пермь архивларында эшләргә, архив язмаларын өйрәнергә туры килә. Ул архивларда әле моңа кадәр билгеле булмаган материаллар табып, татар халкы тарихының яңа сәхифәләрен ача. «Халыкның теле – аның тарихының көзгесе» дигән гыйбарә диалектологиядә үзен аеруча нык аклый, чөнки татар халкының формалашуы, тарихи үсеше, таралышы мәсьәләләрен тел мәгълүматларына нигезләнеп ачыклауда диахроник аспект, тел тарихы һәм шуның белән диалектология фәндә мөһим урын тота, ягъни сөйләшләрнең формалашуы тарих белән турыдан-туры бәйләнгән. Галимнең фикеренчә, тарихи фактларга, беренчел чыганакларга таянып өйрәнү сөйләшләрне тасвирлау барышында туган сорауларны ачыкларга, тел күренешләрен объектив һәм дөрес аңлатырга ярдәм итә. Бу җәһәттән бигрәк тә авторның «Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии» (1984), «К истории формирования говора пермских татар» (1996), «Татары Восточного Закамья: их распространение, особенности говора» (2001) дигән басма хезмәтләре игътибарга лаек.

Д.Б. Рамазанова татар диалектологиясе фәне үсешенең юнәлешләрен ачыклау («Вопросы татарской диалектологии» (2008) монографиясе, «Татар диалектологиясе: казанышлар һәм бурычлар», «Татарская диалектная лексикография и диалектная лексикология», «Л. Җәләй һәм татар диалектологиясе: бүгенгесе һәм киләчәге...», «Литературный язык и диалекты» һ.б. мәкаләләр), аларны популярлаштыру, нәшер ителә торган хезмәтләргә бәяләмәләр язу өлкәсендә дә актив эшчәнлек алып бара.

Галим татар диалектологиясенең җитди казанышларын

тәшкил иткән монументаль характердагы күп кенә хезмәтләрдә төп авторларның берсе һәм җаваплы редакторы булып санала. Мәсәлән: «Урта Идел һәм Урал төбәге татар халык сөйләшләре атласы» (1989), «Татар теленең диалектологик сүзлеге» (1993), «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге» (2009), «Татар халык сөйләшләре» (ике китапта, 2008), тулыландырылган һәм эшкәртелгән «Татар халык сөйләшләре атласы» (2015), Атласның электрон версиясе (2012, http://atlas.antat.ru) һ.б.

ТӘһСИ диалектологлары тарафыннан эшләнгән һәм 2015 елда басылып чыккан «Татар халык сөйләшләре атласы» ның 2012 елда башта электрон варианты эшләнде һәм интернет челтеренә урнаштырылды.

Ул атласларны интернет челтәренә урнаштыруның беренче тәҗрибәсе булды. Аны башка телләр арасында беренчеләрдән булып Казан (Идел буе) федераль университеты һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре эшләп чыкты. Бу эштә Д.Б. Рамазанова да катнаша. Татар теле һәм аның диалектлары белән кызыксынган һәрбер кеше, югарыда күрсәтелгән сайтны ачып, үз сөйләше, башка сөйләш үзенчәлекләре һәм сөйләш вәкилләренең таралу территориясе буенча кирәкле мәгълүматны таба ала.

Д.Б. Рамазанованың гыйльми эшчәнлегендә тагын бер зур юнәлеш бар: ул – лексикология. 1986 елда татар диалектологлары диалекталь лексиканың төрле лексик-семантик төркемнәрен барлау, тасвирлау эшен башлап җибәрәләр. Шушы максаттан чыгып, татарлар яшәгән барлык төбәкләргә лексикологик экспедицияләр уздырыла; нәтиҗәдә алдагы елларда тупланган лексик материал тагын да баетыла. Шуларны гомумиләштереп галим туганлык атамаларын, киемсалым исемнәрен, кешене сурәтләү сүзләрен һ.б.ны өйрәнүгә багышланган монографияләр һәм күпсанлы мәкаләләр язып бастыра. Әлеге хезмәтләр арасыннан: «Названия одежды и украшений в татарском языке в ареальном аспекте» (2002), «Татар телендә кешегә бәйләнешле лексика» (2013), «Атамаларда туганлык һәм гаилә мөнәсәбәтләре» (2014) һ.б.ны атап үтәргә мөмкин.

Д.Б. Рамазанова йола терминологиясе белән дә җитди кызыксына. Татар сөйләшләрен өйрәнгәндә, ул туй турында тоташ текстлар, сөйләү үрнәкләре язып ала һәм аларның бер өлешен «Туйлар, туйлар...» (1997), «Себер диалектларыннан материаллар» (2001), «Татар диалектларыннан сөйләү үрнәкләре» (2011), «Татар диалектларыннан тезмә текст үрнәкләре» (2013) дип аталган китапларында бастырып чыгара.

«Татар диалектларыннан сөйләү үрнәкләре» (2011) – татар диалектологиясе дәреслегенә хрестоматия буларак әзерләнгән хезмәт. Китапта татар халкы яши торган барлык төбәкләргә 1964–2010 елларда оештырылган диалектологик экспедицияләр барышында автор тарафыннан өстәмә материал буларак язып алынган сөйләү үрнәкләре ур-

наштырылган. Анда һәр төбәктәге авылларның тарихын, халыкның җанлы сөйләм телен, авыз иҗатын, ырымнарын, гореф-гадәтләрен, тормыш-көнкүрешен һәм йолаларын чагылдырган сөйләм үрнәкләре бирелә, риватьләр дә теркәлә.

Галим соңгы елларда тирәнрәк катламнарга төшеп, татар сүзләренең килеп чыгышын да тикшерә, татар теленең лексик составын тарихи яктан ачыклау өстендә эшли, фәнни эзләнүләр алып бара. Лингвистикада, хәзерге телләрнең төзелешен һәрьяклап тикшерү белән бергә, телнең тарихи лексикологиясен өйрәнү дә әһәмиятле фәнни юнәлешләрнең берсен тәшкил итә. Тарихи лексикология телнең лексик составында күп гасырлар дәвамында барлыкка килгән үзгәрешләрне өйрәнә. 2016 елда Д.Б. Рамазанованың татар тарихи лексикологиясе өлкәсенә караган «Татар тарихи лексикологиясенә материаллар» дип аталган китабы дөнья күрде. Бу хезмәтендә ул татар теле лексик фондының формалашу процессын төрле чорларга (ностратик, бабаалтай, монгол, бабатөрки, борынгы төрки) бүлеп өйрәнә. Шул этапларда чагылыш тапкан төрки-татар сүзләренең лексик-семантик төркемнәренә күзәтү ясый. Китапта татар теленең лексикасын тарихи планда тикшеренүчеләр өчен бай материал тупланган. Ул татар теле лексикасының тарихы белән генә түгел, гомумтөрки лексиканың формалашуы белән кызыксынучылар өчен менә дигән кулланма.

Д.Б. Рамазанованың фәнни-иҗади эшчәнлегендә тагын бер әһәмиятле һәм катлаулы юнәлеш бар. Ул – татар лексикографиясенә дә билгеле дәрәҗәдә өлеш керткән галим. XX гасырның 90 нчы еллар башында телләр турындагы канун игълан ителгәч һәм татар теле дәүләт теле статусы алгач, мөмкин кадәр кыска вакыт эчендә иҗтимагый тормышның бөтен тармаклары буенча да сүзлекләр төзү ихтыяҗы туа. Төрле тармакларга караган милли терминологияне булдыру – үтә мөһим һәм җаваплы бурычларның берсе. Ул татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтү, киләчәк буынга ана телендә белем бирү бурычлары белән турыдан-туры бәйләнгән. Әлбәттә, әһәмиятле һәм тиз арада башкарырга кирәк булган бу эшкә, башлап, Институт хезмәткәрләре алына. Д.Б. Рамазанова мәдәният (1995), транспорт (1996; автордашы – Ф.И. Таһирова), музыка оешмалары (1997; автордашы – И.Г. Алмазов) хезмәткәрләре өчен сүзлекләр төзеп, бастырып чыгара. Татар теленең 1 томлык аңлатмалы сүзлеген (2006) төзүдә дә автор буларак катнаша.

Д.Б. Рамазанованың фәнни-оештыру өлкәсендәге эшчәнлегендә педагогик белем һәм тәрбия бирү юнәлеше дә зур әһәмияткә ия. Ул берничә ел Казан педагогика университетында, Казан дәүләт университетында татар диалектологиясе буенча дәресләр алып бара. 2008–2012 елларда Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында Дәүләт имтихан алу

комиссиясе рәисе булып тора. 131 нче Физика-математика лицеенда 12 ел татар теле укыта. Аның дистәгә якын фәнни мәкаләләре татар телен өйрәтү, укыту мәсьәләләренә багышланган.

Галимнең хезмәтләре фәндә һәм көндәлек матбугатта һәрвакыт югары бәя алып килә. Ул Мәскәү, Уфа, Төмән кебек зур фәнни үзәкләрдә чыга торган фәнни басма хезмәтләрдә автор буларак катнаша, дөньякүләм дәрәҗәдә билгеле булган белгечләр белән тыгыз бәйләнеш тота; төрле төбәкләрдә уздырылган фәнни конференцияләрдә чыгышлар ясый.

2016 елда Д.Б. Рамазанованың тормыш юлы, фәнни иҗади эшчәнлегенә багышланган һәм хезмәтләре турында матбугатта басылып чыккан бәяләмәләрне туплаган биобиблиографик күрсәткеч дөнья күрде («Рамазанова Дария Байрамовна: биобиблиографический указатель» / сост. и отв. ред. М.Р. Булатова. Казань, 2016. 128 с.). Галимнең саллы хезмәтләре исемлеген туплаган бу күрсәткеч тюркология, татар тарихы, теле, лексикологиясе һәм диалектологиясе белән кызыксынучыларга әһәмиятле кулланма булыр, дип уйлыйм.

Д.Б. Рамазанованың төрле юнәлешләрдәге эшчәнлеге аның фәнни тикшеренү колачының киңлеген билгели, искиткеч түзем, тырыш, җентекле эшли торган, телне тирән тоемлаган зур белгеч булуы турында сөйли. Ул янәшәсендәгеләргә – тормышкөнкүреш мәсьәләсендәме, фәндәме – вакытын һич кызганмыйча ярдәм кулы суза, киңәшләрен бирә, кайгы-шатлыкларыңны уртаклаша белә. Дөрия Рамазанова һәр эшкә җитди, җаваплы карый; ул – башлаган эшен ахырына кадәр сыйфатлы итеп башкаручы галим. Аспирантлар җитәкләү, яшь алмаш әзерләү, яңа буын тикшеренүчеләргә юл күрсәтү дә аның күпкырлы эшчәнлегенең бер тармагы. Аның җитәкчелегендә әзерләнгән дистәдән артык фән кандидатлары – яшь галимнәр – бүгенге көндә мәгариф һәм фән дөньясында эшчәнлек алып баралар. Боларның барысы өчен дә Дөрия Бәйрәмовнага мең рәхмәтлебез.

Д.Б. Рамазанова Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе дигән мактаулы исемгә чыннан да лаек шәхес. Аның күп еллар буе татар җирле сөйләшләрен, телебезнең сүз байлыгын, халкыбызның сөйләм телен, тарихын, тормышкөнкүрешен, гореф-гадәтләрен, этнографиясен өйрәнеп чыгарган китаплары, сүзлекләре һәм башка фәнни эзләнүләре – татар тел белеменә, гомумән, тюркологиягә керткән зур хәзинә.

***Булатова Миңнира Рәхим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 929

***Г.Ф. Гайнуллина, Х.Х. Кузьмина***

# КҮҢЕЛ ТАЛӘБЕ – ФӘН
## (галимә Бәширова Илида Басыйр кызына – 80 яшь)

Илида Басыровна Баширова – видный татарский ученый, автор многочисленных трудов по лексикологии и лексической семасиологии, стилистике и истории татарского языка. В статье представлены краткое описание жизни и деятельности ученого, научные взгляды, а также анализ монографий.

**Ключевые слова:** Илида Баширова, татарское языкознание, лексикология, семасиология, стилистика, история языка.

Фән юлы катлаулы, авыр һәм сикәлтәле. Гомерен фәнгә багышлаган кешеләр моны ачык күзаллыйлар, әмма авырлыкларга бирешмичә, зур максат куеп һәм үз артыннан килгән яшь көчләргә юл ачып, алга баралар; яңа ачышларга омтылалар. Сүзебез – татар тел гыйлеме дөньясында әнә шундый кешеләрнең берсе – галимә Илида Бәширова турында.

Илида Басыйр кызы Бәширова 1938 елның 23 ноябрендә Оренбург өлкәсе Матвеев районының Иске Әмир авылында укытучылар гаиләсендә дөньяга килә. Ул елны Корбан гаете нәкъ менә 23 ноябрьгә туры килгән, шунлыктан кызчыкның әбиләре сабыйга Корбанбикә дип исем кушарга ниятлиләр, ләкин булачак галимнең әнисе, студент елларында белем биргән укытучысына хөрмәт йөзеннән, кызына Илида дип исем куша.

Илида кечкенәдән үк белемгә омтылучан, кызыксынучан булуы, күп укуы белән аерылып тора. Чордашы – олимпия чемпионы Лариса Латынина чыгышларын күреп, үзлегеннән гимнастика белән шөгыльләнә. «Күренекле гимнастка башкарган хәрәкәтләрне ясамыйча тынычланмый идем», – дип искә ала балачагын Илида апа.

Мәктәпне тәмамлагач, «Нишләргә, укырга кая барырга?» дигән сорау килеп баса. Колхоз рәисе мөхтәрәм Камил абый Бикмурзин, Илиданың эшкә уңганлыгын күреп, аны авылда калдырырга тели, пешекче булып эшләргә үгетли, ләкин Илида Бәшированың юлы инде анык билгеләнгән: ул галим булачак!

Яшьтән үк туган тел язмышы белән янып-көеп йөргән Оренбург кызы 1956 елда Казан дәүләт университеты тарих-филология факультутының татар бүлеген сайлый. 25 кешедән торган дус, тату төркемдә, татар дөньясында гына түгел, төрки даирәдә дә танылачак диалектолог, профессор, татар һәм төрек телләре белгече Фәрит Йосыпов, күренекле әдәбият галиме, язучы, тәнкыйтьче, профессор Тәлгат Галиуллин, гарәп теле белгече, гарәп илләрендә укып-

эшләп кайткан Илдар Әүхәдиев, киләчәктә Татарстан Радио комитеты дикторы булачак Рим Кәримов, шагыйрь, мөгаллим, дин белгече Равил Сәйфетдинов, укытучы һәм оста баянчы Әнвәр Мөхәмmәтҗанов (яшь башкаручы Сәйдә Мөхәммәтҗанованың бабасы), таләпчән җитәкче, авыл советы рәисе, академик Мирфатыйх Зәкиевнең сеңлесе Алинә Зәкиева (Садыйкова), танылган укытучы, Аяз Гыйләҗев әсәрләрен туплап бастыручы, әдипнең тормыш иптәше Нәкыя Гыйләҗевалар белем ала.

1961 елда Казан университетын тәмамлаганнан соң, яшь кыз Куйбышев өлкәсе Камышлы районы Бакай авылына татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшкә кайта. Анда 1963 елга кадәр хезмәт куя.

1963 елдан башлап бүгенгә кадәр Илида Басыйр кызының эшчәнлеге СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты (соңрак ТР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) белән бәйле. 1963–1966 елларда ул Тел, әдәбият һәм тарих институтының аспирантурасында укый һәм шунда ук кече фәнни хезмәткәр итеп эшкә алына. 1971 елда – танылган тел белгече Хәлиф Рәхим улы Курбатов җитәкчелегендә «Татар шигъриятендә сүз-сурәт» дигән темага кандидатлык диссертациясе, ә 2000 елда докторлык диссертациясе яклый. Бер үк вакытта Казан университетында лексикология һәм гомуми тел гыйлеме буенча дәресләр алып бара. 1980 елдан – өлкән фәнни хезмәткәр, 2001 елдан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр вазифаларын башкара.

Илида Басыйр кызы Бәширова – 9 монография, 8 уку-укыту, методик программа һәм кулланма, 200дән артык фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләр авторы. Үзенең фәнни эзләнүләрен ул өч юнәлештә алып бара: стилистика, лексикология һәм әдәби тел тарихы. Аның эш алымнарының үзенчәлеге шунда: кайсы гына өлкәгә алынса да, ул һәр куелган мәсьәләнең тирән катламнарына төшеп, аны иң катлаулы яссылыкларда ача. 1971 елда татар гуманитар фәне дөньясына «Татар шигъриятендә сүз-сурәт» дип аталган тема белән килеп кергән галим, соңрак, татар проза телен өйрәнүгә багышланган «Сәнгатьле чәчмә әсәрләр теле: татар прозасында хикәяләү стильләренең үсеше һәм аның әсәр теленә тәэсире», «Җидегән чишмә моңы… (Гомәр Бәшировның иҗат лабораториясеннән)» хезмәтләре белән таныла. 1974 елда дөнья күргән «Сүз белән сурәт ясау» монографиясендә Илида Бәширова сүзнең сөйләм телендә һәм әдәби текст тукымасында барлыкка килгән мәгънә үзенчәлекләрен, туры һәм күчерелмә мәгънәләрнең сурәт барлыкка китерүдәге үзенчәлекле рольләрен билгели. Шушы вакыттан башлап, татар филологиясе фәненә «сүз-сурәт» гыйбарәсе стилистик термин булаpак кереп урнаша. Чәчмә әсәрләр телен тикшерүгә багышланган хезмәтләрендә исә галимә татар сәнгатьле прозасы һәм хикәяләү

стиленең үсеш этаплары, аерым язучыларның индивидуаль телстиле формалашу, хикәяләү стилендәге сурәтләү чараларының үсеш тарихы мәсьәләләренә туктала. Алар аның татар әдәби теле тарихын өйрәнүгә багышланган хезмәтләрендә дә җентекле яктыртыла.

Тел тарихы – бик катлаулы, галим кешедән югары дәрәҗәдәге әзерлек, белем, күзаллау һәм булган гамәли белемнәрне нәзари яктан системалаштыруны таләп итә торган өлкә. Илида Басыйр кызы төрки-татар язма әдәби тел тарихы теориясенең шактый катлаулы һәм тиешле дәрәҗәдә эшләнмәгәнлеген күреп, 2000 еллардан соң фәнни эзләнүләрен шушы юнәлештә алып бара башлый, бөтен көчен иске татар әдәби телендәге норма һәм вариантлылык, диалект һәм әдәби тел, әдәби тел һәм функциональ стильләр мөнәсәбәте, матур әдәбият стиле үсешенең теоретик мәсьәләләрен чишүгә куя. Аның 2000 елда уңышлы якланган докторлык диссертациясе XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби телендә исем категорияләре һәм фигыль наклоненияләрендә әдәби норма, норма вариантлылыгы һәм функциональ-стилистик вариантлылыкны өйрәнүгә багышлана. Билгеле булганча, XIX гасыр ахыры – XX йөз башы – татар әдәби теле формалашуда иң катлаулы, яңаруларга һәм үзгәрешләргә бай, үзенчәлекле, бәхәсле чорларның берсе. Галим әлеге чорда «...өч жанры белән дә матур әдәбият, дин тәгълиматы, рухани-дөньяви дидактика, фәннең барлык тармакларына да караган фәнни һәм фәнни-популяр әдәбият, иҗтимагый публицистика, рәсми-эш, эпистоляр-хат, көндәлек-һөнәри дигән функциональ стильләре һәм әлеге стильләрнең үз эчләрендәге жанр-төрләре хәрәкәттә булып, иҗтимагый эшчәнлекнең төрле ягын чагылдыра торган әдәбият дөнья күрә» дип билгели. Бу әдәбиятның теле дә өч юнәлештә үсеш ала: «а) гарәп һәм фарсы алынмалары һәм гомумтөрки (архаик) формалар кулланып, язма традиция дәвам итәлә торган классик иске татар теле; ә) шул ук нигез угызгосманлы төрек теленең бертөрлекләре белән баетылып, «Тәрҗеман» газетасы теленә бик нык якынайтылган, төрки халыкларның күпчелеге укып аңласын дигән максатны күздә тотып, «урта лисан» дигән тармак, б) әдәби әсәр телен сөйләмә-халыкчан сүз һәм сүзформалар белән баетып язу юнәлеше». Әлеге фикер Илида Басыйр кызы тарафыннан бу чорда (татар әдәбияты, фәне һәм публицистикасы зур күтәрелеш кичергән «алтын чор») иҗат иткән бик күп язучы-шагыйрьләрнең гарәп язуында басылган әсәрләрен һәм кулъязмаларын, газета-журналларның телен анализлау нәтиҗәсендә әйтелә. Шул ук вакытта галим соңгы елларда аерым бер чорны гына анализлап калмыйча, татар әдәби теле үсеше тарихын тулаем күзаллап, зур күләмле хезмәтләр дә яза. Аның Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

тарафыннан чыгарылган «Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр – XX йөз башы). I т.: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлык; II т.: Морфология. Грамматик категорияләрнең структур-субстанциональ үзенчәлеге һәм функциональ-стилистик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлык» исемле коллектив монографиядә урын алган хезмәтләре татар әдәби теле тарихы турында тулы күзаллау булдырырга ярдәм итә.

Илида Басыйр кызы эзләнүләренең өченче юнәлеше семасиология фәне белән бәйле. Казан федераль университетында И.Б. Бәширова лексикология һәм гомуми тел гыйлеме дисциплиналарыннан дәрес-лекцияләр алып бара, студентларга сүз мәгънәсенең четерекле якларын аңлата. Бу дәресләр аңа семасиологияне фән буларак тирәнтен өйрәнүгә этәргеч бирә. Семасиология – лексикология фәне кысаларында барлыкка килгән, сүзнең мәгънә үзгәрешләрен, сүзләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләрен, бәйләнешләрен, сүзнең тышкы төзелешен генә түгел, ә кеше шәхесе белән бәйле булган психологик үзенчәлекләрнең сүзнең мәгънәсендә чагылышын өйрәнә торган катлаулы лингвистик юнәлеш. Чит илләр һәм рус тел белемендә бу юнәлеш шактый күптәннән – XIX гасырдан ук эшләнелә башласа да, төрки һәм, аерым алганда, татар лексикологиясе фәнендә алар XXI гасырга кадәр ачык килеш кала иде. Илида Басыйр кызы бу өлкәдә, беренче булып, татар семасиологиясе фәненең нәзари нигезләрен эшли, аларны тарихи яссылыкта баета. Тарихи аспектта алып барылган семасиологик тикшеренүләр – чын мәгънәсендә катлаулы фәнни юнәлешләрнең берсен тәшкил итәләр, чөнки сүзнең хәзерге татар телендәге парадигматик мәгънәсен ачыклаган очракта да, аның тарихи язма истәлекләрдә (шул исәптән сүзлекләрдә дә) башка мәгънә төсмерләре, кайбер очракта хәтта капма-каршы мәгънәләрдә куллану очраклары теркәлгән булырга мөмкин. Синтагматик мөнәсәбәтләр исә тагы да катлаулырак, биредә тел кулланышы субъектның (авторның) шәхси тел паспорты, дөньяга карашы, индивидуаль үзенчәлекләре кебек психологик моментлар белән үрелеп бара. Әйтергә кирәк, әлеге нигезләмәләр рус тел белемендә дә җитәрлек рәвештә эшләнмәгән.

Үзенең «Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология: татар лексикасында системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр» хезмәтендә И.Б. Бәширова мәгънә нигезен ачыклый торган алты катламның барлыгы турында яза (17 б.). Татар теле сүзлек байлыгының бер өлешен алынмалар тәшкил иткәнлеген истә тотсак (иске татар әдәби телендә исә гарәп-фарсы алынмалары – төп лексик катламнарның берсе), әлеге сүзләрнең чыганак телдәге парадигматик һәм синтагматик мәгънәләрен, мәгънә бәйләнешләрен, аларның татар телендәге трансформациясен дә белү-өйрәнү зарур икәнлеге ачыклана. Димәк, Илида Басыйр кызы башкарган хезмәт фикер күләме ягыннан да,

эчтәлеге-тирәнлеге ягыннан да хәзерге фән югарылыгы таләпләренә җавап бирә, бу юнәлешкә караган башка хезмәтләрдән алдынгы карашлары белән аерылып тора. 2010 елда шушы юнәлештә тулыландырылып, яңа материаллар белән баетылып чыккан икенче хезмәт – «Татар әдәби теле. Семасиология» китабы да фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршы алына. Сүз байлыгына бәйле рәвештә «вариант-инвариант» мөнәсәбәте, лексик-семантик категорияләр мәсьәләсе, деривация һәм коннотация кебек күренешләр автор тарафыннан язма истәлекләр теле мисалында, сүзләрнең хәзерге татар теленә кадәр үсеше мисалында аңлатыла. Әлеге хезмәттәге күзәтүләрнең чагыштырма-тарихи планда эшләнүе, ягъни бер сүз-берәмлекнең һәр чорда төрле авторлар тарафыннан кулланылган мәгънәләре һәм мәгънә үсеше төрлелеген ачыклау хезмәтнең кыйммәтен тагы да арттыра.

Илида Басыйр кызы Бәширова – татар лексикологиясенең моңа кадәр эшләнмәгән өлкәләрен фәнни җәмәгатьчелек игътибарына тәкъдим итүче, бу юнәлештә актив хезмәт куючы, яңа ачышларга, яңа эзләнүләргә омтылучы киң карашлы, тирән эрудицияле татар галиме. Фәнни карашларының киңлеге аның бик җентекле гамәли тикшеренүләре белән үрелеп, тулыландырылып һәм дәлилләнеп-расланып бара. Бүген без аны 80 яшьлек юбилее белән котлыйбыз, ныклы сәламәтлек, киләчәккә корган максатларына ирешерлек көчегәр, яхшы кәеф, уңышлар һәм яңа фәнни ачышлар телибез! Галимнең башкарган эшләре дәвамлы булсын, фән дөньясында чәчкән орлыклары уңдырышлы туфракка төшсен!

***Гайнуллина Гөлназ Фоат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Кузьмина Халисә Хатыйп кызы,***
*Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар теле кафедрасы доценты*

УДК 82-94

*Ш. Мәрҗани*

# КАЗАНҺӘМ БОЛГАР ХӘЛЛӘРЕ ТУРЫНДА ХӘБӘРЛӘР
## *(Икенче бүлектән)*

Приведен отрывок перевода исторического труда великого татарского ученого и богослова Шигабутдина Марджани «Мустафад ал-ахбар фи ахвали Казан ва Булгар» («Использованные сведения к истории Казани и Булгар»), посвящённого прошлому татарского и других тюркских народов.

**Ключевые слова:** Шигабутдин Марджани, «Мустафад ал-ахбар фи ахвали Казан ва Булгар», история, татарский народ.

Русия тугыз йөз алтмыш беренче (1552) ел ахырында татарларны җиңеп, Казан шәһәрен һәм аның тирә-юнен яулап алганда, крепость эчендә сигез манаралы бер мәсҗед җамигъ[1], «Таҗик ермагы» дип йөртелгән урында тагын бер мәчет һәм мәдрәсә булып, галимнәр, габбасиларның[2] олылары һәм бөек сәедләрдән[3] берничә кеше, ә аларның башлыгы нәкыйбел-әшраф[4] аталган мелла Шәриф Кол исемле бер кеше булып, ислам ханнары һәм шәһәр халкы каршында бик гыйззәтле һәм хөрмәтле зат иде.

Русия князьлары Казан ханнарына илче җибереп хатлар күндергәндә, мелла Шәриф Колга үзенә махсус хат һәм бүләкләр җибәрәләр иде, диләр.

Ахырда русиялеләр Казанга һөҗүм иткәндә, үзенең иярченнәрен җыеп, мәдрәсәгә кереп, мәдрәсә түбәсенә чыгып, бик каты сугышып, руслар мәдрәсә түбәсеннән чәнчеп төшереп шәһид булды.

[Халык уенча крепость эчендә бер зур китапханә булып, андагы бик күп китапны русиялеләр фанатиклык сәбәпле яндырганнар һәм галимнәрне һәлак иткәннәр. Бу хәлдән соң Казан һәм аның тирәсендәге мөселманнар качканнар; «Боже матери» дигән сурәтләре килгәч, христианнар аны күтәреп чыгып, һәрбер урында дога һәм шөкер итәләр[5]:]

Хәзерге көндә крепость капкасыннан башланып, университетка хәтле сузылган төз һәм киң урам, крепость капкасыннан чыгып, ике якка төшеп киткән урамнар ислам хөкүмәте заманында да шулай булган. Бу заманыбызда борынгы мөселманнардан калган истәлекләрдән бер манара – мөселманнар хан мәчете дип, руслар Сөембикә манарасы дип исемлиләр. Крепость эчендә хәзер банк урнашкан һәм «дом»

---

[1] Мәсҗед җамигъ – баш мәчет, җомга укыр өчен салынган мәчет.

[2] «Габбаси» – Якын Азиядә габбасилар хәлифәлегенә бәйле галимнәр.

[3] Сәед – башлык, җитәкче.

[4] Нәкыйбел-әшраф – бөекләрнең җитәкчесе.

[5] Цензура тарафыннан сызылган.

дип йөртелә торган губернатор сарае янында «Таҗик ермагы» исемле ермакта бер мәчет һәм мәдрәсә булган. Болакның көньягында хәзерге «Печән базары» дип аталган урында мөселман зираты икән. Руслар Казанны алганда, Шаһгали хан, гаскәр белән килеп, Зөя тамагында Зөя шәһәрен салып, шул тирәдә булган чуваш, чирмеш, калмык кебек халыкларны Русия кул астына кертеп, Казанга һөҗүмнәрендә Шаһгали хан алар яклы булып килгәндә, Казан мөселманнары хәзерге Җиһанша мәчете каршындагы чиркәү урынында булган нугай капкасыннан чыгып, бик каты сугыштан соң, Шаһгали хан Арча кыры ягына чыккан һәм каберләр өстендәге агачларга яшеренеп Болакны үткән. Шәһәрне руслар алганнан соң да мөселманнар бераз вакыт мәетләрен шул каберлеккә күмгәннәр, Йосыф бине Исхак бине Исәнкол бине Рахманколый бине Рәхмәтулла бине Габдерахманның ике углы Хәсән һәм Хөсәен үзләренең Рахманколый исемле бабаларын Печән базарында Әсәб җәлаб Мохтар бине Әднакол әл-Җәбәлли капкасы төбендә күмелгән атабыз Йосыф кечкенә чакта атасы Исхак белән бергә килеп зиярат кылганлыкларын сөйлиләр иде. Тагын Баязид бине Хәмид бине Арслан йортының, хәзер Гобәйдулла бине Габдулла бине Габдерәшид (Кәче авылыннан) йорты, аның бакчасында борынгыдан билгеле бер зират бар. Тагын Апанай Хафиз зәңгәр мәчет каршындагы каберлектә күмелгән, ә углы Исмәгыйль бабай ике бистә арасындагы каберлектә күмелгәнлектән, ике бистә арасындагы зират соңрак оешкандыр дип уйларга мөмкин.

Хәзер Казан шәһәрендә беренче мәчеттә[1] сөннәт бүлмәсендә[2] кабер өстенә куелган бер такта (таш) бар. Уң ягында: Калә эн-нәби галәйһис-сәлам: Әд-дөнья сәгатән фә әҗгальһа тагатән[3]. Сул якта язганы кубып төшкән, тик бер «Калә әл» сүзе генә калган. Алгы якта: Калә Аллаһы Тәгалә: Күллү мән галәйһа фань вә ябка вәҗһе раббикә зәл-җәлали вәл-икрам. Тукыз йөз утыз алтыда Шаһмөхәммәд Бикмөхәммәд углы Мөхәммәдгали бәк зөлкәгъдә аенда (кяфер кулыннан) шәһид[4]. Бу тактаның (ташның) аркасында язганы: «Бу ләвехне углы Тәңре Колы бәк бина кылды»[5]. Бу ташның озынлыгы ике кәздән[6] бине аз ким, киңлегә өч чирек, калынлыгы бер чиректән артыграк.

---

[1] Беренче мәчет – хәзерге К. Насыйри урамында, Мәрҗанинең үз мәчете.

[2] Сөннәт бүлмәсе – мәчет гадәттә ике бүлмәле була. Шуның ишектән керүгә беренче бүлмәсе «Сөннәт бүлмәсе» дип атала.

[3] Пәйгамбәр галәйһис-сәлам әйтте: «Дөнья – бер сәгатьлек. Сез аны гыйбадәт белән үткәрегез».

[4] Аллаһе тәгалә әйтте: «Дөньядагы бөтен нәрсәләр бетәчәк, бары олылыкка һәм хөрмәткә лаек Аллаһ үзе генә мәңгелек...» Тугыз йөз утыз алтыда (1529–30) шаһ Мөхәммәд бәк углы Мөхәммәдгали бәк зөлкәгъдә аенда (ай хисабынча, 11 нче ай) шәһид – (үтерелгән). «Аенда» сүзеннән соң «кяфер кулыннан» дигән сүзне цензор сызган.

[5] Бу тактаны (ташны) углы Тәңре Колы бәк ясатты. (Бу кеше Казан өчен сугышларда үтерелгән булса кирәк.)

[6] Кәз – аршин.

Ул таш Әхмәд бине Исмәгыйль әл-Казани әл-Айбашиның әйтүенә караганда, мең ике йөз утызынчы ел һиҗридә (1814–15) Казанның югары урамында чәй кибетләре бина кылынганда, шул урында читек-башмак сәүдәсе белән утырганда почмактагы кибет урыныннан килеп чыгуын үз күзе белән күргән. Моннан соң ул ташны мелла Ибраһим әфәнде губернаторның рөхсәте белән беренче мәчеткә китереп, урта бүлмәдә кыйбла (көньяк) ягындагы көнчыгышка караган почмакка куйдырган иде. Ул таш анда торганда намаз укучыларга тарлык һәм шик китергәнлектән, аны төньяк почмакка күчерттем. Шуңа күрә бу таш чыккан урында тагын каберләр булган дип уйларга юл бар. Хәзер дә зәңгәр мәчет[1] урамы һәм яңа урам дигән урыннарда биналар өчен нигезләр, мең ике йөз туксанынчы (1873–74) елда мунча өчен су юлы казыганда, каберләр һәм кеше сөякләре чыкканлыктан, бер заманда ул тирәләрнең дә зират булганлыгы беленә. Күл башында Әскаф (епископ) яшәгән йортта элекке мөселман каберләре бар. Шунда бина вакытында эшчеләр күп ташларны бина астына салганнар. Аны шул вакыт Казанда Әскаф, ахырдан патриарх булган Григорий күреп, эшчеләрне тыеп, беразы исән калган. Бигрәк тә капкасы төбендә, керүченең уңында бер олуг таш, бу таш гайре ташларга охшамый. Төсе кара, үзе бик каты, зур. Биеклеге биш аршин ярым, киңлегә биш чиректән артык, калынлыгы ярты аршин чамасы. Язуы яхшы, сөлес язуы белән калкытып язылган. Укырга читен. Бердән, бик еш, чорнап, вак язган. Икенчедән – язучы кайбер сүзләр арасын бүләсе урында бүлмичә, бер ягын казып, икенче ягын казымый һәм әрчеми калдырган; өченчедән – күп кешеләр язу карасы сөртеп карап, шул кара катып калган. Бу кадәр сүзләр укылды. Башта өчпочмак эчендә бик эре язган: «Һүә-л-хәййәл-ләзи лә ямүт»[2].

Моннан соңгы беренче юлда: «Һәзә мәркадес-Солтан әл-әкбәре әл-әкраме гаусес-сәлатыйн[3]»;

Икенче юлда: «Әл-әмирел-мөкәррәм»[4].

Өченче юлда: «Әл-мозаффар»[5].

Дүртенче юлда: «Әл-кирам вәл-әҗалилел-гыйзам»[6].

Бишенче юлда: «Иләл-мозаффар»[7].

Алтынчы юлда: «Әш-шәрәфәйни мөфәххәре аль»[8].

Җиденче юлда: «Вәд-дине зыйллуллаһи лил-галәмин»[9]. Әл-әкрәмел-кәрим.

---

[1] Зәңгәр мәчет урамы – Нариман урамы.

[2] Ул – терек һәм бер чакта да үлмәс.

[3] Бу – иң бөек, иң хөрмәтле һәм күп солтаннарны коткаручы солтанның кабере.

[4] Хөрмәтле әмир (җитәкче, башлык).

[5] Әл-мозаффар – җиңүче, өстен булучы.

[6] Хөрмәтлеләрдән һәм иң бөекләрдән.

[7] Җиңүчегә.

[8] Ике хөрмәтле һәм ... мактанычы.

[9] Дин, галәмгә Алланың күләгәсе.

Сигезенче, тугызынчы юлларда: «Хәсән бәк бине Мирмәхмүд».

Укылмаган сүзләр кайбер юлларда азрак, кайберсендә күбрәк. Беренче юлны «Әл-әкрәмелкәрим»[1] дип укырга мөмкин.

Дүртенче юлдагы «Әләҗәлил» сүзе, тугызынчы юлда булган сүзләр җитәрлек ачык түгел. Кыскасы, бу таш патшаларның берсенең каберенә куелган. Гасыр һәм исеме ачык билгеле булмаса да, минем уемча, Чыңгыз нәселеннән булмыйча, аннан элек булуы сүз сөреше һәм өслүбеннән беленә. Янә чиркәү янында икегә сынган бер таш бар. Күфә һәм нәсех[2] язуы белән батырып язылган. Беренче юлы – буш. Икенче юлында: «Һүә-л-хәййәл-ләзи лә йәмүт»[3]. Өченче юлда: «Вә күллү хәййин...»[4] Дүртенче юлда: «Әхмәд». Алтынчы юлда: «Рәхмәтән васигатән фани дөньядин»[5]. Җиденче юлда: «Бакый ахирәт[6] тарих алты». Сигезенче юлда: «Туштан алтыш җал эт». Тугызынчы юлда: «Айх сәкер күән иртә күән эт». Унынчы юлда: «Әл-мәүте бабән вә күллүн-нәси дәхилүһү»[7]. Унберенче юлда: «Бәгъдел-мәүт»[8]. Ягъни бу Әхмәд исемле кеше җомга көн зөлхиҗҗәнең сигезенче көнендә алты йөз алтмыш алтынчы елда вафат.

Халык телендә сөйләнүенә караганда, мөселманнар хөкүмәте вакытында яз аенда Болгар шәһәрендә, ул харап булгач, Казан шәһәрендә зур бер базар булып, анда Әстерхан, Кырым, Дагыстан, Харәзем, Урта Азия, Кашгыр якларыннан, Русия шәһәрләреннән, Кытай сәүдәгәрләреннән күп кеше килеп, зур җыелыш, кызыклы уен һәм тамашалар булган икән. Шаһгали хан Зөя крепостен төзеп, шундый ук бер базар оештыргач, Казанда тәртипсезлекләр күплектән, Казан базары сүнеп, Зөягә күчеп, Казан руслар кулына күчкәч, Сура елгасының Иделгә кушылган урынындагы Василесурск шәһәренә, аннан Нижний[10] өлкәсендә Исад дип йөртелгән урынга каршы якка күчерелеп, шул урында күренгән дип уйланган Макар исемле изгеләренә нисбәт биреп, ул базар үзе, «Макарья», татарчада шуннан үзгәртелеп «Мәкәрҗә» дип хәзер дә мәшһүр һәм танылган.

Меӊ ике йөз утыз беренче (1815–16) елгы янгында кибетләр һәм башка биналар янып, меӊ ике йөз утыз икенче (1816–17) елда Ука елгасының Иделгә кушылган урынында кибетләр бина ителеп, хәзерге көндә зур биналар һәм

---

[1] Хөрмәтлеләрнеӊ хөрмәтлесе.

[2] Күфә һәм нәсех – гарәпчә язуның төрле формалары. Гарәпләр элек күфә язуы, аннан соӊ нәсех язуы белән язганнар.

[3] Ул (Алла) терек һәм үлмәячәк.

[4] Һәр терек...

[5] Күп рәхмәт, бетәчәк дөньядан.

[6] Мәӊгелек ахирәт.

[7] Үлем – ишек һәм барлык кеше ул ишектән керәчәк.

[8] Үлгәннән соӊ.

[10] Нижний – хәзер Нижний Новгород шәһәре.

башка төрле гыймарәтләр белән бик олы, төзек, йөз миллион, бәлки артыграк мал җыелуы (оборот ясалуы) мәшһүр. Ул базар асылда Болгар шәһәреннән Казанга күчерелгән. Соңгы заманнарда берничә авыл берләшеп, җәен җомга көннәрендә төрле урыннарда бер-бер артлы «җыен» дип аталган бер бәйрәм ясап, шул вакытта халыкның туган-тумача, дус-ишләренә кунак булып йөрүләре шул Казан базарыннан калган бер үрнәк имеш.

Мөселманнарның дин һәм дөнья эшләренә катнашу һәм тарлыклар булмыйча, татарлар арасындагы дау, низаг, мәеттән калган малны бүлү, васыятьләрне җиренә җиткерүдә үз муллалары һәм олылары бу эшләрне карап хәл итеп, һәркайда һәм һәрничек үзләре каршында яраклы табылганча, теләгән рәвештә мәчет, мәктәп һәм мәдрәсәләр бина итеп, кемне ихтыяр итсәләр, риза булса имам итеп, имамнарны төшерүдә мәхәллә һәм авыл халкы ирекле булганнар. Балаларга исем бирү, өйләнү, мәетләрне күмүдә һәркем ирекле булып, читтән һичкем катнашмаган, ягъни Русия дәүләте бу эшләргә бертөрле дә тарлык итмәгән. Шуның өстенә, бистә халкы, ягъни шәһәрнең төп халкы булган мөселманнар телендә «йомышлы Русия мөселманнары», Русиялеләр каршында «татар сәүдәгәре» исемендә һичбер язусыз-нисез тулы ирек белән һәртөрле сәүдә эшләре рөхсәтле булып, бу хәл мең ике йөз егерменче (1806–07) елга чаклы дәвам иткән. Моннан соң йомышлы мөселманнарның бу хокуклары, сәүдә тәртипләре бетерелеп, сәүдәгәрләр өч дәрәҗә, дүртенчесе мещан исемендә тәртип ителде. Беренче дәрәҗә сәүдәгәрләргә Русиядә, хәтта чит илләр белән сәүдә итү хокукы бирелде. Икенче дәрәҗәлеләр Русиянең барлык өлкәләрендә, өченче дәрәҗәдәгеләр кайбер өлкәләрдә генә, ә мещаннар исә фәкать үз шәһәрләрендә генә сәүдә итәргә хокуклы булып, һәркайсы дәрәҗәсенә күрә хәзинәгә билгеле күләмдә салым түлиләр, мещаннардан башкалары солдатка алынмыйлар иде. Авыл халкының исә дворяннарга башкалары ике төркем: берсе казак, берсе ясаклы исемендә булып, ясаклыдан фәкать имана алынып, солдатка алынмый иде. Казак дип аталганнары кирәк чакта солдатка барырга мәҗбүрләр иде. Русия дәүләтенең мәшһүр һәм мактаулы патшасы Петр бине Алексей бине Михаил бине Федор бине Никита – «Беренче Петр» яки «Бөек Петр» дип аталган һәм Русия дәүләтендә император исемен беренче алган көне, мең дә туксан дүртенче (1682–83) елда патша, мең бер йөз егерменче (1708–09) елда император булып, мең бер йөз утыз җиденче (1723) елда үлде. Күп вакытлар дошманнарына өстен булган һәм һәртөрле фидакарьлек, зур тырышлыклар белән Русия шәһәрләренә күп һөнәрләр, промышленность кертеп, законнар төзеп, илне күп агартып, тәртипкә салган. Ул заманга чаклы Русия мәмләкәтендә ел исәбе дөнья яратылыштан исәпләнә икән. Мең бер йөз унөченче ел һиҗридә (1700) дөнья яратылышыннан 7208

булганда, милади тарих буенча бер мең җиде йөз иде. Башка христиан илләренә ияреп, дин һәм шәригатьләрендә бөтен эшләре ригая һәм олылау важиб булган хәзрәти Гайсә галәйһис-сәлам тууыннан исәпләп, милади тарихны кулланырга кушып, биш мең биш йөз сигезне ташлап, Гайсә тууны ел-тарих башы исәпләп, I нче январьдан башлап, милади тарих белән бер мең дә җиде йөз дә бер дип саный башладылар. Шул заманнан бирле рус халкы милади тарих кулланып киләләр. Айлары рум һәм юнанча (грекча) исемнәр белән гыйнварь, февраль һ.б. дип саналырлар.

Спас өязе Иске Рәҗәп авылының кешеләре игенлек, печәнлек һәм урман җирләрен, күршеләрендәге башка халыкларның чикләрен билгеләп язылып, хәзинә (дәүләт) печате белән беркетелгән язуларында һәм шул вакыттагы имамнарыннан булган мелла Зәйнелгабидин бине Габделкәрим исемле кешенең тәрҗемәсендә мондый язу күренде. Язу түбәндәгечә: «Тарих җиде мең дә ике йөз өченче, декабрьның унөченче көнендә указ олуг, бөек падишаһ хәзрәте олуг князь Петр Алексеевич һәм, олуг һәм кечек ак падишаһ Русия йортын үзе тотучы, үзе биләүче, указ көче белән Казан өязенең Рәҗәп авылы татарлары югарыда язылган җирләрне сукалау һәм печәнен чабу өчен укадиләр[1] илән биләргә олуг падишаһ хәзрәтенең бердән ясак белән тармакка, ягъни түләргә, бу замандагы аңлатуны казнага түләргә яздым» (сүзе тәмам). Әмма мөселманнар һәрбер вакыйгаларда һиҗри тарихны кулланып, айларны мөхәррәм, сафар, шәһре рабигыль-әүвәл, шәһре рабигыль-ахир, җөмадиль-әүвәл, җөмадиль-ахир, рәҗәб, шәгъбан, шәһре рамазан, шәүвәл, зөлкагъдә, зөлхиҗҗә дип санап, фәкать игенчелек эшләре өчен кояш хисабы белән яз башыннан башлап, «хәмел, сәвер, җүза, сәрәтан, әсәд, сөнбелә, мизан, гакрәб, кавыс, җәди, дәлү, хут» дип гарәби исемнәр, ә кайбер чакта мөселман гарәпләрдә йөртелгән Сирьяни исемнәр белән: «азәр, нисан, ияр, хәзиран, тәмүз, аб, илүл, тәшрин әүвәл, тәшрин сани, кянун әүвәл, кянун сани, шыбат» дип саный иделәр. Ул заманнарда Казан мөселманнары унике хайванга бәйле төрки тарихын да белә һәм куллана иделәр. Бу урында Олугъ Кавал имамы мелла Сәлимҗан бине Дусмөхәммәд исемле кешенең бер китабында язган сүзен үзгәртмичә китерелде: «Руслар хисабы буенча җиде мең дә ике йөз дә сигез булган. Ул Адәм галәйһис-сәлам тарихын ташладылар, ушбу мең дә җиде йөздән алдылар. Имди Гайсәнең тарихын мең дә җиде йөз дә бер дип саный башладылар. Мең дә җиде йөз дә сигез булды печин елында биш мең дә биш йөз дә сигез елы тәмам ташланды. И, аңлы кеше, бел, кояш елының өч төрле хисабы бар: берсен фарсылар хисабы диерләр. Аның белән Болгар кешеләре файдаланганнар.

[1] Укадиләр – угодиеләр.

Берсенә Румия хисабы диерләр. Христиannар аның белән файдаланганнар. Берсе белән барлык шәһәрләрдәге мөселманнар файдаланганнар. Димәк, хәмел хисабын белү барлык мөселманнарга тиештер, чөнки намаз вакытлары аның белән беленә, төш авышуы аның белән беленә. Тагын белегез: элек фарсы нәүрүзе[1], ун көннән соң румия нәүрүзе, аннан ун көннән соң хәмел нәүрүзе була. Нитәк шәһәре Болгар галимнәре «бала нәүрүз, карт нәүрүз, эсселек нәүрүз» дип күрсәтteләр. Һәрбер нәүрүз һаваның берәр үзгәрешен күрсәтүче» (сүзе тәмам). Мәзкүр мелла Сәлимҗанның кайсы елда вафаты билгеле булмаса да, мең бер йөз сиксән икенче (1768–1769) елда 36 яшендә исән иде. Югарыда телгә алынган Беренче Петр мең бер йөз уналтынчы (1704–05) елда мәмләкәт халкын тәмам тәфтиш кылып, никадәр халык бар – исемнәре белән детальләштереп, саннарын дәфтәрләрдә беркетtереп, мең бер йөз утыз дүртенче һиҗридә (1721–22) дөрес сан буенча шул халыклардан имана (салым) алына башлады. Бу тикшерү – рус телендә беренче ревизия дип танылды. Икенчесе – мең бер йөз илле җиденче (1744–45) елның ахырында аның кызы Елизавета патша заманында булды. Өченчесе — татарлар арасында «Әби патша» дип йөртелә торган Екатерина II (Алексей кызы) гасырында мең бер йөз җитмеш сигезенче (1764–65) һәм шуның ук гасырында мең бер йөз туксан алтынчы (1781–82) елның ахырында барс елында, бишенчесе – һәм сигез ел үткәч, алтынчысы – аның оныгы Александр бине Павел бине Петр гасырында мең ике йөз егерме алтынчы (1811), җиденчесе мең ике йөз утыз беренче (1815), сигезенчесе – мең ике йөз илленче (1834–35), тугызынчысы – мең ике йөз алтмыш алтынчы (1850–51) ахырында икенче оныгы Николай бине Павел гасырында, унынчысы – аның улы гасырыбызның падишаһы Александр II бине Николай заманында мең ике йөз җитмеш өченче (1856–57) ахырында үткәрелде. Әлеге Беренче Петр гасырында мең бер йөз уналтынчы (1704–05) елда берничә кешедән сайлап беренче тапкыр солдат алынды.

Мең бер йөз егерменче (1708–09) елда Русия мәмләкәте губерна дип исемләнгән өлкәләргә бүленде. Авыл халкының казак дип аталганнарына, кайбер чакта солдат бирү өстенә сугыш кораблары өчен урманнардан зур имән агачлары кисеп, билгеләнгән урынга ташу хезмәтләре йөкләнеп, солдат бирүдән азат ителгәннәр өчен бу хезмәтләр бик әйбәт саналып, хәтта аларга җан башыннан казнадан бераз хезмәт хакы да бирелгән. Безнең бабаларыбыз шушы казак дип йөртелгән төркемнән, мең бер йөз егерме өченче (1711–12) елда Беренче Петр Казанга килеп, иң башлап лашман хезмәтенә җиде йөз мең кеше билгеләнеп, мең бер йөз утыз өченче (1720–21) елда штаб ачылып, киметелеп, йөз егерме меңгә калдырылды.

[1] Нәүрүз – яңа ел башы.

Шул гасырларда сугыш көймәләре ясалып, лашман хезмәте беткәнче, имән агачын кисү кискен рәвештә тыелды. Әгәр берәүнең имән кискәне билгеле булса, яман җәза бирелер һәм кеше үтерү хөкемендә була иде. Моннан соң мең ике йөз алтмышынчы (1844) елларда ут көче белән йөри торган көймәләр уйлап табылып, Русия мәмләкәтендә дә ут көймәләре ясалып, агачтан сугыш көймәләре ясау һәм аңа бәйләнешле хезмәтләр бетеп, мең ике йөз җитмеш алтынчы (1859–60) елларда лашман хезмәтенең атлы һәм җәяүлесе тәмам бетерелеп, лашманчы казактан һәм ясаклыдан бертигез солдат алына башлады.

Башта бер өйдән бер кеше алу, соңыннан, артында булганны һәм күпле барында азлыдан алмау кебек законнар булса да, ләкин эштә күп кимчелекләр булып, ул шартлар тиешенчә сакланмыйча, күп золым һәм җәфалар тудырыла иде. Чиратта торган кеше читтә булса, я качса, чираты булмаган кеше алына иде. Шуңа күрә чираттагы кешеләрне тотып, кулларын бәйләп, каравыллап, бер ун-унбиш көн артыграк та йөртелә иде. Хәтта безнең заманда шул эшләр булып, чираттагы кеше качмасын дип, бер богау белән һичбер гаебе булмаган икенче бер кешенең аякларына богаулыйлар иде. Бөтен эштә, хәтта йоклаганда һәм бәдрәфкә чыкканда, икесе бергә булалар иде. Бу – үз күзебез белән күргән хәлләрдән. Безнең заман хәлләреннән: бер чит кешене бер-бер эштә шаһит дип ерактан, төрле мәшәкатьләргә очратып китертеп, килә алмаса, баш бирмәүче дип җәзалап, әгәр килсә, гаепсезгә ябып куеп күп кенә яраклы эшләрне һәлак итү кебек.

Сиксән дүртенче набордан башлап, мөселман урынына русны һәм киресенчә алу тыелды, ә бер мең ике йөз җитмеш беренче (1854–55) елда бу шарт бетерелде. Солдат алу законы тирәсендә вак-төяк үзгәрешләр һаман булып торса да, озынайту һәм детальләштерүдән хөкүмәт һаман сакланып килде. Ниһаять, мең ике йөз туксан беренче (1874–75) елда чыгарылган яңа закон буенча, һәммә халыктан гомумән, 21 яшь тулган егетләр кирәк кадәр алына башлады. Казан сәүдәгәрләреннән мөселманнардан беренче булып, Шәмседдин бине Сәгъдеддин әл-Күгәрчени углы Җәладеддин алынды. Юныс бай балаларыннан ике кеше өчен акча түләнде. Ата-аналарының берсе эшкә яраксыз яки ятим, авыру, зәгыйфь кардәшләре булып, башка ярдәм һәм тәрбия итәрлек кешеләре булмаган кешеләр бу законга кертелмиләр. Солдат хезмәте башта егерме биш елга чаклы сузылып, хәзер унбиш ел, ә күбесенчә алты ел хезмәт соңында рөхсәт белән илләренә кайтаралар. (2–12 битләр)...

*Текстны басмага әзерләүче, искәрмәләрне язучы*

***Гарипова Ләйлә Шамил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 929

***Гали Рәхим***

# ИСКЕ ШАГЫЙРЬЛӘР

Представленная критическая статья известного татарского писателя и ученого-литературоведа Гали Рахима (1892–1943) была напечатана в третьем томе «Истории татарской литературы», изданном в 1922 году. Этот монографический труд в трех томах был написан в соавторстве с Газизом Губайдуллиным и охватывает историю татарской литературы с древних времен до начала XIX века. В свое время этот колоссальный труд был опровергнут критиками марксизма. Предлагаемая статья посвящена освещению становления татарской поэзии и первых поэтов. Автор коротко останавливается на основных литературных течениях и направлениях средневековой поэзии, размышляет о влияние Востока на татарскую поэзию, пользуется трудами таких ученых как Ш. Марджани и Р. Фахретдина.

**Ключевые слова**: Гали Рахим, татарская литература, поэзия, творчество, литературоведение.

XVIII–XIX гасыр эчләрендә яшәп, Шәрык мәдәнияте тәэсирендә булган нәзым төзүчеләрне без шушы исем астында җыябыз. Икенче тәгъбир белән әйткәндә аларны «мәрсияче шагыйрьләр» дип тә атарга мөмкин булыр иде; ләкин бу тәгъбир, әлбәттә, ихатале вә тулы булмаячак. Бу шагыйрьләр чын мәгънәсе белән иске заман кешеләре. Әдәбиятыбызда яңалык дәвере башлану белән алар беттеләр, тәмамән тарих күләгәсенә керделәр. Алар, бездә бөтен куәте белән иске шәрык даирәи фикериясе, борынгы чыгтай вә госманлы әдәбиятлары хөкем сөргән дәвердә килгән кешеләр; миллият, халыкчылык, тәрәккый, уяну, Яурупа артыннан бару шикелле идеяләр белән аларның, катрә (*тамчы*) кадәр булсын, мөнәсәбәте юк. Алар бөтенләй шәрык тәэсирендә, динчелек вә тәсаувыф (*суфилык)* тәэсире астында җитешкән адәмнәр. Алар тудырган әдәбиятның хакыйкый төсен аңлар өчен бу шагыйрьләрнең нинди сыйныфтан чыгуларына күз салу җитә. Бу сыйныф, заманасының бердәнбер кулына каләм тотарга кадир булган *(көче җиткән*) һәм «гыйлем»не үзләренә монополия итеп алган сыйныфы, ягъни муллалардыр.

Гәрчә үткән гасырлар безгә, гадәт булып киткән караш буенча, бары тик караңгылык вә торгынлык дәвере булып кына күренсә дә, бу заманнарда бездә туңган динчелек вә схоластика чуалчыгыннан башка нәрсә булмаган төсле тоелса да, иҗат, фитърәт (*яратылыштан булган үзенчәлек*) вә алга омтылу чаткылары ул вакытта да бөтенләй юк булмаган. Дин бабында Курсави вә Мәрҗани күк, хакыйкатькә ирешү юлында фикерләре эшләгән затлар булганы шикелле, алар арасында, «Мөндеш» авылының

«Мөнәҗҗим» (*астроном)* дип йөртелгән Фәйзулла мулла шикелле, чын дөньяви фәннәр бабында гакыллары йөргән, риязият (*математика*) вә һәйәт (*хәрәкәт күренеше буларак күк йөзендә әйләнә торган җир һәм барлык галәм һәм шул турыда фән)* белән шөгыльләнгән кешеләр[1], «Кышкар» Сәгыйд хәзрәт шикелле, соңгы рәвештә алтын ясау фикере белән шашкан «алхимик»лар[2], «Шекә»нең[3] мәшһүр Яхья мулла шикелле, эспиритизм (рух чакыру, җаннарны мөсәххәр итү (*сихерләү)* белән исем чыгарган шәхесләр[4] дә килеп чыккалаган.

Шулай ук әдәбият вә шигырь бабы да безнең аңлы муллаларыбыга ят нәрсә булмаган. Алар арасында Гареб һәм Иран әдәбияты белән сөеп шөгыльләнүчеләр булгалаган. Ачык фикерле шәкертләр, мәдрәсәдә укыган чакларында, гади программадагы фәннәр, сарыф-нәхү, фикһы, кәлям, мантыйк, тәфсир, хәдис белән генә канәгатьләнмичә, Шәрыкның мәхү (*югалган*) әдәбиятка хасланган гыйлемнәрен, гаруз, кафия, бәлягать (*төзеклек*), бәдигъ (*гүзәл*), бәян шикелле фәннәрне дә моталәгә кылганнар (*өйрәнгәннәр*). «Мәкамате Хәрири»ләрне[5], Сәгъди вә Хафизларны укучылар булгалаган, гыйлем тәхсил итәр (*алу*) өчен Борынгы Шәрык мәдәниятенең ояларыннан булган Төркестанга, Бохарага бару һәм хаҗ сәфәрләре аларга борынгы ислам мәдәнияте әсәрләре белән танышырга ярдәм иткән. Газали шикелле, атаклы, ләкин шәрыкта онытылгын, ислам галимнәренең әсәрләре бәгъзән, тәсадефи (*очраклы*) рәвешендә булса да, аларның кулларына төшеп, иң сизгер вә үткен гакыллыларының фикерләренә яшен күк тәэсир иткән (Курсави, Мәрҗани). Шулай ук Шәрык шагыйрьләре белән дә алар Урта Азиядә вә Истанбулда танышканнар[6]. Төркестанда торып укыгында алар фарсы телен өйрәнергә мәҗбүр булып, фарсыча белү аркасында аларга Иран әдәбиятының бакчасына юл ачылган, шунда ук алар чыгтай әдәбиятының классик әсәрләре белән дә таныша алганнар. Хаҗиләр аркылы безнең Русиягә госманлы шагыйрьләренең дә әсәрләре килеп эләккәләгән. Безнең муллалар, бигрәк тә Фөзүлине яратып укыганнар. Бик күп муллаларның ата-бабадан калган көтебханәләрендә, байтак икенче дәрәҗәдәге борынгы төрек шагыйрьләренең диваннары белән бергә, Фөзүлинең дә диванын очратырга мөмкин.

Шул шәкертләрнең бәгъзеләре күңелләренә кергән әдәбият мәхәббәтен безнең Идел буена, Ерак Шимальдәге «Болгар иленә»дә алып кайтканнар. Бохарадан кайтып та, караңгы татар авылларында надан мужикка биш вакыт намаз укытып, кечкенә генә мәдрәсәдә шәкерт җыеп дәрес әйтеп гомер уздырырга мәхкүм булган (*хөкем ителгән*) бу «хәзрәт»ләр озын, эч пошыргыч кышкы төннәрне Сәгъдинең «Гөлстан» вә «Бөстан»ын[7], Фөзүлинең, Хафизның диванын, ихтимал Нәваиның «Көллият»ен[8] укып кыскартканнардыр, мәдәни дөньядан аерылуның кайгысын, «абыстай»

белән уртаклаша алмаганга, шулар белән бүлешкәннәр; шәрыкның шигырь диңгезләренә чумып, надан «остабикә»нең гаилә хәятендә бирә алмаганы рухани вә гыйшкы ләззәтләрене шуннан табарга тырышканнардыр.

Менә шул бөек мисаллар, даһи «сәләф»ләрнең (*борынгыларның)* әсәрләре безнең әдәбият сөюче хәзрәтне иҗат юлына сәвекъ итәләр (*этәрәләр)*, аны кулына каләм алырга кыстыйлар, рухын канатландырып шигырьләр илһам итәләр ... Менә ул, борынгы заманның шагыйре, күз алдына җанлы картина булып килә: Кич. Тышта буран, яки шатырдаган Русия салкыны. Бакчага каратып салынган мулла йортының тәрәзәләрен кар каплаган. Хәзрәтнең өендә җылы, хәтта эссе, өй эчендә тынлык хөкем сөрә. Йомшак түшәккә батып, чыбылдык эчендә рәхәтрәхәт йоклаган «абыстай»ның мышнавы да тынычлыкны бозмый, бәлки арттыра гына. Хәзрәтнең «фәрзәнд»ләре (*балалары*): мәхзүмнәр, мәхзүмәләр дә (*мулла малайлары-кызлары да*) йоклыйлар. Әнә, тәбәнәк аяклы өстәл янында, май шәменең зәгыйфь яктысында, аягын бөкләп хәзрәт утырган. Башында сарт кәләпүше. Ул үзен, шул эчендә яши торган галәменнән бөтенләй еракта, бер мәдәни кеше, Бохара мәдрәсәләренең берсендә дәрес әйтүче, буш вакытында шигырь белән шөгыльләнергә яратучы сарт дамеллясы, һич булмаганда шул мәдрәсәдә хөҗрә (*бүлмә)* биләүче «пишкадәм» (*укуда башкалардан алда булган шәкерт*) итеп хыял итә. Хәзрәтнең кулында күркә канатыннан ясалган, бик шәпләп юнылган каурый каләм. Ул шомартылган, калын, саргылт кәгазь өстенә, мулларга махсус, тәгъликътан (*гарәп хәрефе белән языла торган язу төрләреннән берсе)* үзгәргән, рәсми хат белән шытыр-шытыр нәрсәдер яза. Фикере, хыялы белән ул әллә кайларда. Шәех Сәгъдиләр, чәйханәле, шау-шулы базарлы, балчык өйле эссе шәһәрләр, мәһабәт таш мәчетләр галәмендә.

Ул үзен шәех Сәгъди дәрәҗәсендә үк булмаса да, теге сарт дамеллясы төсле «шагыйрь» итеп фараз кыла ... Тәгаен ул үзенең күптән түгел генә вафат булган остазына яисә «шәехенә» багышлап мәрсия яза торгандыр...

Омтылу бер нәрсә – истигъдад (*сәләтлелек*) икенче нәрсә. «Үзләрен «шагыйрь» итеп фараз иткән муллалардан, әлбәттә, күбесе, әсәрләрен укып мәфтүн (*үзенә-үзе сокланган)* булган шагыйрьләренә якын килү түгел, хәтта аларга азмы-күпме тәкълид тә итә *(иярә дә, охшата да)* алмаганнар; күбрәк, ни өчен кирәк алай, нәзым оештырудан мәрсия, мәдхия, мөнәҗәт, касыйдә язудан үтмәгәннәр.

Гомерендә бер мәртәбә һич шагыйрь булмаган кеше дә, азапланып, көчәнеп булса да, шигырь тәртип итә ала. Әгәр дә без Мәрҗанинең «Мөстафад әл-әхбар»ын, Риза хәзрәтнең «Асар»ын актарып карасак, анда берничә дистәләп шагыйрьләр табабыз; бөтенләй диярлек, муллалар. Алар арасында киң Русиянең һәртөрле почмакларында, һәм авылларда, һәм шәһәрләрендә яшәгән кешеләр бар. Күбрәге

XIX гасыр адәмнәре, ләкин XVIII гасырда торганнары да юк түгел. Күбесенчә, алардан берике шигырь сакланып калган: китап артына язылган берәр бәет яки мәнзумә *(дастан),* аерым кәгазь парчаларында берәр мөнәҗәт, яисә берәүгә багышланып, икенче кешеләр кулында сакланган мәрсия яки мәдхия. Бу төрле шагыйрьләрдән тарихта исемнәре вә әсәрләре сакланганнарының саннары 30–40 лап булса, онытылганнары, әсәрләре тәләф *(әрәм-шәрәм)* булып, югалып, янып киткәннәре, яки караңгы бер авылда, һичбер нәрсә белән кызыксынмый торган, надан мулланың ата-бабасыннан калган, гомердә бер мәртәбә ачылмыйча, шүрлектә тузан җыеп ята торган иске китаплары арасында яшеренеп ятканнары, ихтимал ки, йөзләп саналырга тиештер.

Бу кешеләр, әлбәттә, фи нәфсиһи *(үзләре)* шагыйрь булмаганнар. Иң элек алар мәхәлләләрендә имам, аннан соң мәдрәсәләрендә мөдәррисе яки мөрид тәрбияләүче ишан, аннан соң гына алар шагыйрь. Шигырь язу аларның тормышында әһәмиятле бер эш түгел; ул болай гына буш вакытны тутырыр өчен, «зиһен шаяртыр» өчен генә эшләнә. Ләкин шулай булса да, нәзым тәртип итү мәсьәләсендә виртоузлык дәрәҗәсенә килеп җиткән муллалар да булгалаган. Мәсәлән, алар бер-берсенә язган гади хатларында нәзым белән язалар икән. (Габделкаһир мулла, Чүпрәле Вәли мулла).

Шигырь язарга һәвәс иткән муллаларның гади татар муллалары массасыннан аерылып тора торган кешеләр, үз сыйныфларының каймагы булулары бәдиһи (*ачык*). Бер заманда бер халыкта гыйлем-укымыш кайсы сыйныф кулында булса, мәдәният тезгенен кай сыйныф үз кулында тотып алып барса, гадәттә ул халыкның әдипләре дә шул сыйныф эченнән чыгалар. Мисал: ике йөз елга якын урыс әдәбиятын, урысларның бердәнбер чын зыялы, сыйныфы булып килгән дворяннар үз кулларында тоттылар. Безнең татарның зыялы сыйныфы исә, элеккеге гасырларда бары тик муллалар-руханилар иде. Шуңар күрә, әдәбият та алар кулында булды. Без монда бары нәфис әдәбиятны гына алмыйбыз. Гомумән, һәрбер кулына каләм тотып язучы шул сыйныфтан буладыр иде. «Мөстафад әл-әхбар» вә «Асар»да борынгы муллаларыбызның тәрҗемәи хәлләрен укысак, аларның һәрвакыт язучылык белән мәшгуль булуларын күрәбез. Алар, мәдрәсәдә торганда үзләренә укыр өчен, мулла булгач моталәга итәр *(укыр, өйрәнер)* һәм көтебханәләрендә булындырыр өчен, үз куллары белән дистәләрчә китаплар күчергәннәр. Ләкин бу эш һәрбер гади мулла өчен дә мөмкин эш булган. Моның нәтиҗәсе, әлбәттә, хәзерге заманда матбагалар ида итә *(үти)* торган хезмәт, ягъни китап күбәйтүдән башка нәрсә булмаган. Ләкин безнең муллаларның галимрәкләре болай матбага ролен уйнау белән генә канәгатьләнмәгәннәр; үзләре китап «тасниф» итәргә *(язарга)* җөрьәт иткәннәр. Мосаннифлекнең (*китап төзү,*

*язуның)* муллалар карашында нинди зур һәм мөкаддәс эш булып танылганлыгын искә алсак, «мосанниф» дигән сүз артына һәрвакыт «рәхмәтулла гая» кушылып йөртелүен хәтергә төшерсәк, ни өчен монда «җөрьәт» дигән тәгъбирне кулланыуыбыз аңлашылса кирәк. Бу җөрьәт күбесенчә иске китапларга шәрех язудан ары китә алмаган. Андый шәрех язучы муллаларны без бик күп очратабыз. Ләкин Курсави, Мәрҗани шикелле үзләреннән чыгарып яңа китаплар язган галимнәрнең саны, әлбәттә, бармак белән санарлык кына. Кирәк «мосанниф»лар, кирәк «шәрех»ләр булсын, дини мәүзугъларда *(сюжетларда)* әсәрләр язучы муллалар үзләренең китапларын, җитди әсәрләр өчен бердәнбер әдәби тел итеп хисапланган. Гарәп телендә язганнар. «Голяма» өчен булган бу әсәрләрне «төрки» теле шикелле «әкъбәхел-лисан» *(начар, ямьсез тел)* булган, «тупас» телдә язу гадәте булган. Хәтта, гарәп теленә багыну шул дәрәҗәгә барып җиткән – «Сөбател-гаҗизин» шикелле төрки китапларга да гарәпчә шәрех баглаучы муллалар булгалаган. «Әфсахел-лисан» (*матур, төзек тел)* дип игътикад ителгән *(ышанган, инанган)* тел, Коръән иңгән һәм оҗмаг әһле сөйләшәчәк тел, гарәп теле, шул кадәр рәвәҗдә *(таралган)* булгач, аны мөкәммәл *(камил)* рәвештә белү һәрбер үзен галим дип санаган татар мулласы өчен лязим булган; һәм аны мөкәммәл белгәннәр дә шагыйрь муллалар арасында гарәпчә шигырь язучыларны байтак кына очратырга мөмкин. Фарсычаны алар күбесенчә яхшы белгәннәр. Фарсы телендә дә шигырь сөйләгән һәм китаплар язган муллалар юк түгел. Бу ике «шәриф» *(хөрмәтле)* телдә язарлык, хосусан, шигырь тәртип итәрлек куәткә малик булу, шөбһәсез, алар каршында кәмаләтнең *(җитешкәнлекнең)* соң дәрәҗәсе итеп хисапланган. Ихтимал, алар «төркичә» язуны гаҗизлектән, гарәп-фарсыны кирәгенчә белмәгәнлектән генә җаиз (*яраклы*) күргәннәрдер.

«Мәрсияче» шагыйрьләрнең теле хакында сөйләгәндә «төркичә» дигән тәгъбирдән башканы кулланыр хәл юк; чөнки аларның телен татарча дип әйтеп булмый. Бу бик күп гарәби вә фарсы сүзләр, хәтта гыйбарәләр белән чуарланган, чыгтайча, госманлыча, татарчадан үстерелгән бер әдәби шивә, анда кайда чыгтайча тәэсире башланып, кайда госманлыча яки татарчаныкы эшләнгәнен һич аңларга мөмкин түгел. Аларның әдәби теленә үзләренең ана телләренең тәэсире булганлыгы шикелле, шул заманда бик модада булган, хәтта халык арасында да укылган чыгтай вә госманлы китаплары да тәэсир итми калмаганнар. Шулай итеп, безнең борынгы әдәби телебез мәйданга килгән. Ләкин, бу тел дә бөтенләй бер төрле түгел; шул ук «мәрсияче»ләр дә җиңел мәүзугъларга шигырь язганда (мәсәлән, һәҗүви бәетләрдә) сөйләшү теле белән бер диярлек татарча тел кулланганнар. Авырлык вә җиңеллектә төрле шагыйрьләрнең өслүбләрендә байтак аермалар табыла. Һәрхәлдә аларның телен аз-маз укыган Идел

буе татары аңлый алганы шикелле, Урта Азия вә госманлы төрекләренә дә ул аңлашылырлык булган. Чынлап та, бу «Тәрҗеман бабай»ның[9] гомуми тел идеалына бик якын килә торган бер тел инде!

Мөндәриҗә *(эчтәлек)* ягына килсәк, без үзебезнең шагыйрь – муллаларыбызда зур истигъдад, даһилык дәрәҗәсенә ашкан шигъри ялкын тапмыйбыз. Гомуми фикер торгынлыгы, халкыбызның мәдәни түбәнлеге, икътисади изелүе әдәбиятта бөек истигъдадларның, тирән фикерләрнең, даһилык мөһере сугылган әсәрләрнең мәйданга килүенә манигъ *(сәбәп)* булган. Үзләренең остазларына, ишаннарына, заманасындагы мәшһүр бер галимгә, аларның фикерләрене тулкынлаткан әсәрләренә багышлап язылган мәдхияләр, вафатлары мөнәсәбәте белән язылып, аларның кәмаләтләрен зикер иткән мәрсияләр, пәйгамбәрне мактаулар, Ходага мөнәҗәтләр, тәсаувыфи касыйдә вә мәнзумәләр *(тезмәләр)* – менә, безнең иске заман шагыйрьләренең каләмнәрен тибрәткән мәүзугълар күбесенчә шулар. Гомумән, шәрык әдәбиятларына тәкълид иткәнлекләреннән *(ияргәннәреннән)*, аларның шигырьләрендә тәсаувыф вә тарикать фикерләре, дөньядан бизү идеяләре хөкем сөрәләр. Бу шагыйрьләр арасында без байтак кына тәсаувыф вә тарикатъ әһелләрен, ишаннарыны, очратабыз (мәсәлән, Вәлид ишан, Һибәтулла ишан, Яхья ишан, Мәхмүд ишан шикелле).

Шагыйрь-муллаларның күбесе соңында безгә берәр-икешәр генә шигырь сакланып калса да, араларында шигырь белән җитди рәвештә шөгыльләнгәннәре, нәзым белән язылган бөтен-бөтен рисаләләр калдырганнары да бар. Мәсәлән, Багдад шәһәрендә дөньяга килеп, соңыннан Русиягә Сәгыйд бистәсендә имам булып торган, «Хаҗи Багдади» дип мәшһүр булган шагыйрьнең Мөхәммәд пәйгамбәрнең дөньяга килүе (мәүлид) хакында нәзым белән язылган бер китабы бар; бу китапның ахырында ул «Шарикдәштәи хаҗи» сәрләүхәсе *(исеме)* астында шигырь белән үзенең тәрҗемәи хәлен яза (Асар, алтынчы җөзьә); Һибәтулла ишанның бик күп газәл, касыйдә вә мәрсияләреннән башка «Мәҗмәгыл-әдәб» һәм «Төхфәтел-әүляд» исемнәрендә басылып таралган мәнзум рисаләләре бар; Әбелмәних хаҗинең нәзым белән язылган әсәре шулай ук басылган катаплардан; Габдерәхим Утыз Имәнинең язган әсәрләрнең саны уннан артык, күбесе нәзым белән язылган; XIX гасырның соңгы яртысындагы язучылардан «Чокыр» авылының мулласы Гали Чокрыйның да шигырь вә нәсер белән язылган байтак әсәрләре бар. Иске шагыйрьләр арасында, мөстәсна *(аерым)* булып кына, Шәмсетдин суфи шикелле чын шигъри хиссияткә малик булган, «шагыйрь» исемен камил лиякать бән *(лаек булуны)* күтәрерлек затлар да очрый.

Әлхасыйль, татар халкының үткән гасырлардагы мәдәният тарихына күз йөрткәндә, ул заманда да үзенә бер төрле әдәби хәрәкәт, әдәби хәят булганлыгы күзгә чалына. Муллаларның

алгы сафта тора торган, аңлы, күзе ачык булганнары әдәбият вә шигырьгә махсус фәннәрне өйрәнгәннәр, гарәп, иран вә төрек шагыйрьләренең әсәрләрен ләззәтләнеп укыганнар; үзләре дә шигырь белән шөгыльләнеп, һәртөрле мәнзум китаплар вә шигырьләр тәртип иткәннәр; бербересенә көйле хатлар язганнар; шигырь аркылы бер-берсен илзам итү *(бәхәстә җиңеп чыгу)* өчен, бер-берсенә каршы бәетләр язышканнар (Чүпрәле Вәли мулла, Гали Чокрый, Кәрим Хафиз). Һәҗү (сатира) һәм мәзах (юмор)га да өлеш чыгаручылар булган (шулар ук һәм «фәлсәфә Шакир»).

Шагыйрьлек бер муллаларга гына хас булмаган. Мәсәлән, Казандагы XIX гасыр шагыйрьләреннән «Кәрим Хафиз» мулла түгел, бәлки «Коръән хафиз» гына. Ул хәтта хафизлыгын да бер якка ташлап, һәртөрле юлда көчен сынап баккан (мәсәлән, балта остасы – столярлык кылган); бу кешене бик үткен телле, һәҗүче шагыйрь булган дип сөйлиләр; ләкин, хәзергә кадәр аның шигырьләрен кулга төшерә алганбыз юк. Казанның мәшһүр Апанаевлар нәселеннән килгән «фәлсәфә Шакир» ләкабе *(кушаматы)* белән мәшһүр булган зат, шулай ук үткен вә ачы теллелеге, кешегә туры әйтүе, тормышка фәлсәфи карашы белән атказанган; һәр туры килгән урында экспромт рәвешендә шигырь әйтә ала икән. «Фәлсәфә Шакир»ның заманасындагы төрле кешеләрдән көлеп язган бәетләре хәзердә дә бәгъзе бер төп казанлылар кулында табыла. «Чутай Мостафа» – бәгъзе бер «сәер» эшләре белән легендарный зат булып киткән бер адәм; Казанда XIX гасыр ахырында үзенең хәттатлыгы *(каллиграфлыгы)* белән мәшһүр булып, тәгъликъ язуында аның тиңдәше булмаган; дәрвишләр шикелле ялгыз яшәп, балаларга хөсне хат *(матур язуны)* өйрәтү белән шөгыльләнеп гомер кичергән; тәсаувыф шигърияттен тирәнтен аңлаучы Иран әдәбиятының мохлисе, фарсы теленең мөтәхәссисе *(сизүчесе)* булган; Хафиз, Сәгъди, Фирдәүси аның һәрвакыт укый торган шагыйрьләре икән («Мөстафад»нең беренче җөзьәнең ахырында бу кешенең Шиһаб хәзрәт вафатына багышланган бер мәрсиясе бар). Татарстанның төрле урыннарында мондый кешеләрнең охшашлары, әлбәттә, тагын булгандыр.

Язуда яки күңелдә сакланып калган хатирәләргә карағанда, бу шагыйрьләрнең күбесенең үзләренә бертөрле «сәер табигатьле» (оригинал) адәмнәр булганлыгын күрәбез. Алар арасында, дөньяга, байлыкка һич исләре китмәүче, әфкяре гаммә *(күпчелек)* белән хисаплашырга теләмәүче, дәрвиш табигатьлеләре булганы шикелле, байларга тәлинкә тотып, дөньяви әүкатларын (*вакытларын)* шуңар бина кылучылары да булган. Соңгылары, мәшһүр байларның заказлары буенча, аларның үлгән аталарына вә кардәшләренә багышлап бик мөбаләгале (*күпертелгән, арттырылган)*, бөтен кагыйдәләргә туры китереп төзелгән, мәрсияләр тәртип иткәннәр. Аларның эшләгән «хәйрат» *(изге)* эшләрен, мәсәлән, салдырган мәчет-мәдрәсәләрен мактап

мәдхияләр язганнар. Шуның барәбәренә, әлбәттә, «гайре рәсми гонорар» йөзеннән, «ингам-ихсан» *(сыйлау-ярдәмнәре)* белән файдаланганнар. Заманасындагы буржуазиянең мәдәният ягыннан алдагы сафта торучылары, «әһле гыйлем»не сөюче, зирәклек вә үткен сүзне тәкъдир итүчеләре алар өчен «меценат» ролен уйнаганнар. Алар бер яктан, үзләрен мактау вә күтәрү бәрабәренә, шагыйрьләрне матди яктан күтәрсәләр, икенче яктан аларның әсәрләрен бастырганнар, яки бастыру юлында ярдәм итешкәннәр. Шулай ук китап бастыручы һәртөрле «Казан мещан»нары да алар өчен шул ук рольны уйнаганнардыр.

Шулай итеп, без электә (хосусан XIX гасырда) Идел буе татарлары арасында, даирәне таррак алып әйткәндә аларның югары сыйныфларның каймагы эчендә, заманасының иҗтимагый вә мәдәни әхваленә мөтәнасиб *(тигез)* рәвештә кечерәк кенә, чын шәрыкча, ләкин үзенә бер төрле җанлылыктан хали *(буш)* булмаган бер әдәби хәрәкәт булганлыгын мөшаһәдә итәбез (*күрәбез*). Яурупа тәэсире керә башлау белән, яңа фикерләр белән ашланган яшь буынның җитешүе белән бу әдәби хәрәкәт туктамады. Бәлки башка, яңа формаларга гына куелып дәвам итте. Насыйри, Халиди шикелле бер аягы белән Шәрыкта, бер аягы белән Гарębтә тора торган кешеләр бу юлда күпер булдылар.

**Искәрмәләр**

1. «Мөстафад әл-әхбар», җөзьэ 2, 258 бит *(Г. Рәхим искәрмәсе).*
2. Шунда ук, 249 бит. *(Г. Рәхим искәрмәсе).*
3. Шекә – Арча районындагы авыл.
4. Шунда ук, 243 бит. *(Г. Рәхим искәрмәсе).*
5. «Мәкамәте Хәрири» борынгы гарәп язучысы һәм шагыйре Әбү Мөхәммәт әл-Касыйм бине Гали әл-Басрый әл-Хәриринең (1054–1122) канун һәм әхлакка караган «Мәкамәт» җыентыгы.
6. Күп иске көтебханәләрдә «Гөлстан»ның ташбасма белән Истанбулда басылган нөсхәләре табыла *(Г. Рәхим искәрмәсе).*
7. Мәрҗани («Мөстафад» 2, 218 нче биттә). Элек заманнарда татар мәдрәсәләрендә шәех Сәгъдинең «Бөстан»ы дәрес итеп укылганын сөйли *(Г. Рәхим искәрмәсе).*
8. Мәсәлән, XIX гасыр шагыйрьләреннән Чүпрәле Вәли мулладан калган язуларда аның Нәваи һәм Хөсәен Байкыра белән таныш булганлыгы күренә. Вәлиулла Алкаев Сембер губернасында «Яңа Чүпрәле» авылының имамы булып, мәрсияче, һәҗүче һәм экспереметчы (ягъни күз алдында булып торган бер вакыйга мөнәсәбәте белән, шундый ук, тәвәкъкыфсыз (*туктаусыз*) шигырь әйтергә көче җитә торган шагыйрь) булган. Казанда Зәңгәр мәчет мәдрәсәсендә укып, мулла булгач та, Казан белән галякасын (*элемтәсен*) өзмәгән. Шул вакыттагы, казанлы һәҗүче шагыйрь «Кәрим Хафиз» белән һәрвакыт шигырь белән моназарә (*бәхәсләшә)* һәм мөнакашә кылыша (*сүз көрәштерә*) торган булганнар. Мәшһүр шагыйрь вә язучы Гали Чокрый белән дә гасырдаш булып, шулай ук шигырь белән көч сынашканнар. Аның һәҗүви шигырьләре күбесенчә бик садә татарча язылган. Кулымда бу затның байтак шигырьләре, нәзым белән

язылган хатлары бар. Кирәкле материал җыелып беткәч, бу кеше хакында аерым бер мәкалә язарга өмет итәм *(Г. Рәхим искәрмәсе)*. Г. Рәхим бу кеше хакында 1929 елдагы «Безнең юл» журналының 9–10 санында «Крестьян шагыйре (Вәли Җиһаншин)» исемле мәкаләсен бастыра.

9. Монда сүз мәгърифәтче, педагог, нашир Исмәгыйль Гаспринский (1851–1914) хакында. Чөнки ул «телдә, фикердә вә эштә берлек» нигезендә Россиядәге барлык төрки халыкларны берләштерү идеясен күтәрә.

*Текстны басмага әзерләүче, искәрмәләрне язучы*

***Хөснетдинова Гөлназ Азат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145+398

*И.Г. Закирова, О.Р. Хисамов, И.Г. Гомәров*

## ИРКУТСК ӨЛКӘСЕНДӘ УЗГАН КОМПЛЕКСЛЫ ЭКСПЕДИЦИЯ ТУРЫНДА

В июне 2018 года Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ была проведена комплексная экспедиция в Иркутскую область РФ. Представленная статья посвящена кратким итогам данной научный работы.

**Ключевые слова:** комплексная экспедиция, Иркутская область, топонимия, фольклор, диалект.

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының чираттагы комплекслы экспедициясе 2018 елның июнь аенда Иркутск өлкәсендә эшләде.

Иркутск шәһәрен татарлар Өркет дип атаган. Бу атама хәзерге вакытта онытылган. Иркутск Ангара елгасының ике ярына урнашкан. Сүз уңаеннан әйткәндә, Ангараның да татарча Әнгәр дигән атамасы булган. Татарларның бу якларга күпләп килә башлавы XIX йөз урталарына карый. 1835 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча Иркутскида 350 татар кешесе яшәгән. Татарларның бу якларга күченүе, Столыпинның аграр мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән реформасы белән бәйле рәвештә, XX гасыр башында активлаша. Иркутск өлкәсендәге татар авылларының күпчелегенә шул елларда нигез салына. Бу авыллар тайга эчендә, сазлыклар арасында, юлсыз җирләрдә урнашкан була. Мәсәлән, Чирмешән авылына нигез салучылар турындагы хатирәләр Иркутск якларына килеп чыгучыларның нинди шартларда яшәп китүен бәян итә.

Салкыннар башланып киткән ноябрь аенда, поезд күченеп килүчеләрне, бернинди станция дә, ут та булмаган җирдә туктап, бушатып китеп бара. Ирләр, яннарындагы гаиләләрен, бигрәк тә яшь балаларны саклап калырга омтылып, землянка казыйлар, аннан соң, әкренләп, көч җиткән кадәр агач егып, йорт сала башлыйлар. Мең газап белән бу якларга килеп урнашкан кешеләр салкын тиеп үлә башлый. Балаларны да саклап кала алмыйлар. Кечкенә генә булса да, йортлар салына бара. Ауга йөреп, туенырга кәсеп табып, иялэшә-тынычлана башлаганда гына, яз җитә. Кар эри башлау белән булачак авылның селкенеп торган сазда урнашканлыгы сизелә башлый. Тизрәк барлы-юклы әйберләрен биегрәк урынга күчереп, яңадан йорт салырга керешәләр. Чирмешән авылының тарихы шулай башлана.

Себер үзләштерелә башлагач, бу якларга сөргенгә җибәрелүчеләр арасында татарлар да күп

була. Мәсәлән, 1878–1879 һәм 1885 елларда Казан губернасындагы крестьян хәрәкәтләрендә катнашучыларны Иркутск якларына сөрәләр. Алар да шул җирләрдә төпләнеп кала. Сөрелгәннәр артыннан аларның гаиләләре дә күченгән. Кызганыч, туган җирләреннән сөрелгән әлеге катлам турында информантларыбызда мәгълүмат сакланмаган.

Илдә барган үзгәрешләрдән качып чыгып киткән катлам да бар анда. Берәүләре бәхет эзләп үзе чыгып китсә, икенчеләре алдарак киткән туганнары, якташлары янына барып урнашкан. Урман төпләп, җир ачып, авыр хезмәт белән интексәләр дә, биредә кешене рәнҗетү, түбәнсетү азрак булган. Татарлар берләшеп, бер-берсенә ярдәм итеп яшәргә омтылган. Туган якларына язылган хатлар, аннан килгән хәбәрләр аша, Себердә дә тормыш барын ишетеп, халык килә торган.

XX гасыр башларыннан Иркутск губернасына тайга төпләп җирләрне үзләштерү, шахта-рудникларда эшләү өчен «вербовка» белән дә татарлар күпләп килә. Бу хәрәкәт гасыр башында активлашып XX йөзнең 70 елларына кадәр дәвам итә.

2010 елгы Бөтенроссия халык санын алу нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Иркутск шәһәрендә һәм шушы өлкәгә караган авылларда 22 882 милләттәшебез яши. Иркутск өлкәсендә татарлар яши торган дистәләгән авыл бар. Халык телләрен, гореф-гадәтләрен саклап гомер кичерә.

Иркутск өлкәсенең табигате турында да берничә сүз әйтеп үтү урынлы булыр. Иркутск – ул гаҗәеп саф сулы Байкал күле, Саян таулары, үтеп чыкмаслык урманнар, Ангара елгасы, күпсанлы елга-күлләр иле. Байкал салкын сулы күл. Температурасы 6 градус чамасы гына булганга анда су коену мөмкин түгел. Әмма ул шулкадәр үз-үзен чистартып торучы сулык, Байкалга беренче мәртәбә генә килүчеләр дә, Байкал күлен сакральләштергән бурят халкы да, теләкләрен тели-тели, аның суын эчәләр.

Экспедиция вакытында Иркутск, Ангарск, Усолье Сибирское шәһәрләрендә, Заларинск районы үзәге Залари поселогында һәм шушы районның Сенная Падь, Тройцк, Холмогой, Черемшанка авылларында, Аларск районының Шаховск, Новоселово авылларында, район үзәге Кутулик поселогында, Бохан районы Хохорск, Усольск районының Билектуй авылында бай материал тупланды. Галимнәр Иркутск өлкәсендә яшәүче милләттәшләребезнең тарихын, рухи мирасын өйрәнде, мәдәни кыйммәтләрен барлады.

Экспедиция җитәкчесе, Институтның фән эшләре буенча директор урынбасары, филология фәннәре кандидаты Олег Хисамов Иркутск өлкәсендәге топонимнарны һәм микротопонимнарны өйрәнде. Иркутск өлкәсендәге топонимнар берничә катламнан тора. Биредә электән яшәүче бурят халкыннан калган атамалар да, Идел буеннан алып килгән татар, рус атамалары да очрый, Столыпин реформасы вакытында бу якларга күчеп урнашкан белоруслар да үз топонимнарын алып килгән.

Топонимик атамаларда халыкның үткәне, тарихы, гореф-гадәтләре, ышанулары, мифологик карашлары хакындагы мәгълүматлар саклана. Һәр микротопоним аерым бер авыл, яки урам өчен кадерле берәр вакыйганы хәтерләтә, якыннарының исемен саклый. Мәсәлән, Новоселово авылында Һади чишмәсе, Әхтәм чишмәсе, Хәбип коесы, Бари урманы дигән микротопонимнар бу чишмә-коеларны карап торган, күп итеп шомыртлар-каеннар утырткан кешеләрнең исемнәрен киләчәк буыннарга җиткерә. Иске базар юлы дигән микротопоним да үткәннәр белән бәйле, ул халыкның үзе җитештергән товарын арба-чанасына төяп базарга китүен искә төшерә кебек. Сүз уңаеннан әйткәндә, бу авылга нигез салынганда һәр хуҗалык үзенең коесын казыган булган. Аларның кайберләреннән, ташлангач та, саф су саркып тору тукталмаган. Авылда чишмәләрнең күп булуы шуның белән аңлатыла да.

Язма һәм кулъязма мирас үзәге мөдире, филология фәннәре кандидаты Илһам Гомәров халыкта сакланган гарәп язулы кулъязмаларны, китапларны барлады, татар зиратларындагы эпитафияне укыды. Китапларның кайберләрендә, татар халкына хас булганча, гаилә тормышындагы зур вакыйгалар теркәлгән. Халык туган җирләреннән алып килгән, иң кадерле урында сакланган китап битләренең кырыйларында, тышлыкларында авылдан чыгып китүләре, барып урнашулары, балалары туу яки балаларының никахы турында әлеге вакыйгаларның төгәл датасы күрсәтелгән язмалар саклана.

Иркутск шәһәренең зират ташлары, ягъни эпитафик истәлекләре аерым игътибарга лаек. Биредәге кебек кабер ташлары, башка халыкларда сирәк кенә очраса да, татар зиратларында әлегә кадәр очраганы юк иде. Ул ташлар, беренче карашка, ботаклары киселгән агач төбен хәтерләтә. Мондый ташлар, сирәк кенә булса да, зиратларда очрый әле. Агач төбе рәвешендә эшләнгән таш, кагыйдә буларак, әлеге кешенең исән вакытта масоннар ложасына керүен күрсәтә. Бу традиция, кабер ташлары «мода»сы буларак, башка халыкларга да күчкән, һәм аларны төрле конфессиягә караган зиратларда очратырга мөмкин. Аларны бала яки күп балалы ана кабере өстенә, нәселе өзелгән, нәселендә соңгы булган, үзеннән алда уллары үлгән кеше өстенә куйганнар. Иркутск зиратында бу ташларның кемнәр каберенә, нинди максатта куелганын белмибез. Бу сорау ачык кала. Мондый күренешне татар халкында кешенең җаны кош булып очып кайтып, кабер өстендә кунарга агач эзли дигән ышану белән дә бәйләргә мөмкин. Икенче яктан, дөнья мифологиясендә, шул исәптән татар халкында да агач – кеше, ботаклары бала белән тиңләштерелә, киселгән агач, ягъни агач төбе символик рәвештә кешенең гомере киселүен, икенче дөньяга күчүен дә аңлатырга мөмкин.

Иркутск шәһәре мәчетендә сакланган китапларны экспедициянең тагын бер табышы дип карарга мөмкин. Халык гарәп

язулы китапларны еллар дәвамында Иркутск мәчетенә тапшыра килгән. Илһам Гомәров әлеге китапларның каталогын төзеде, аларны яхшы саклансын өчен, чистартып, кәгазь тартмаларга урнаштырып, тәртипкә китереп калдырды. Мәчеттә сакланып калган китаплар арасында, Коръән басмалары, дини эчтәлекле китаплар белән бергә, география, математика, мантыйк, фәлсәфә буенча дәреслекләр, хәтта трактатлар да очрый.

Халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре Илсөяр Закирова халык иҗаты, фольклор үрнәкләрен язып алды. Һәрбер информант белән әңгәмә гаилә тарихын искә төшерүдән башланып китте. Яшьләр дә, өлкәннәр дә нәселләренең каян чыкканнарын яхшы беләләр.

Һәрбер авылда, Иркутск, Усолье Сибирское, Ангарск шәһәрләрендә татар ансамбльләре бар. Татар җырлары халыкка туган телне саклап калырга да ярдәм итә.

Экспедициядә язып алынган риваять-легендалар арасында шәехләргә багышланган ике текст аерым урынны алып тора. Аларны Залари районы Чирмешән авылында яшәүче Насыйпов Шәехзаман абый һәм аның Усолье Сибирское шәһәрендә яшәүче кызы Котлыәхмәтова Әнисә апа сөйләделәр. Шәехләр турындагы әлеге риваятьләрне укучылар игътибарына да тәкъдим итәбез.

**Мөхәммәтсалих карт турында**

Минем әткәй – Шәйхелиман, әткәйнең атасы – Мөхәммәтнасыйп, аның атасы Мөхәммәтсалих исемле була. Менә шул Мөхәммәтсалих очып та йөргән, су өстеннән дә йөргән. Бервакыт ул Үрмәт авылында яшәүче малаена кунакка килгән. Минем әткәйкә ул вакыт җиде-сигез яшь булган. Мөхәммәтсалих бабай бераз булгач кайтырга җыенган. Әткәйгә атасы әйткән: «Картаңны озат», – дигән.

Әткәй болай дип сөйли иде: «Озатам, басу капкасына җиттек, картәтәй әйтте, ди, улым, кич булды инде, мин кичке намазга соңга калмаем, диде, ди. Капканы яптык та, картәти әйтә, улым мин очсам, курыкмассыңмы, ди. Авыл унике чакрым, болай өлгермәм, ди. Акшам вакыты җитә, ди. Курыкмыйм, картәтәй, дип әйттем, ди. Әз генә йөгереп барды да, очып китте, ди».

Суда да батмаган ул, су өстеннән йөгереп йөргән. Бәләкәй генә карт булган үзе.

Залари районы Чирмешән<br>авылында Насыйпов Шәехзаман<br>Шәйхелиман улыннан (1921 елгы)<br>язып алынды

Минем пра-прадедушка, картәтәй Мөхәммәтсалих исемле булган. Бервакыт аңа Агыйдел аркылы чыгарга кирәк булган. Кешеләрдән сораган, кәмәле кешеләрдән, алып чыгарга. Кәмәдә урын табылмаган аңа. Су буенда утырган да, аякларын чикатып утыра икән. Әйткән: «Сез Салих картны алмадыгыз, ә Салих карт сездән алда барып җитә әле ул каршы якка», – ди. Аннан торган да, судан җәяү чәп-чәп киткән теге якка. Кешеләр кәмәдә килеп җиткән вакытта, Салих карт

теге якта аякларын суда чикатып утыра, ди.

Усолье Сибирское шәһәрендә
Котлыәхмәтова Әнисә Шәехзаман
кызыннан (1956 елгы)
язып алынды

Лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Алина Хөсәенова Иркутск өлкәсендә яшәүче татарларның тел-сөйләм үзенчәлекләрен барлады. Иркутск өлкәсендә Татарстанның һәм Башкортстанның төрле авылларыннан күчеп килгән халык яшәү сәбәпле, биредә тел дә шушы якларның сөйләм үзенчәлекләрен саклый, татар теленең урта һәм көнбатыш диалектларында, нигездә, әдәби телгә якын телдә сөйләшәләр. Өлкән буын телне яхшы белсә дә, яшьләр телне оныта баралар. Шулай да, яшьләр дә телне, милли традицияләрне сакларга тырыша. Алар милли бәйрәмнәрдә, фольклор бәйрәмнәрендә актив катнаша, туган як, халык тарихы белән кызыксыналар.

Театр һәм музыка бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре Наилә Нургаянова халыкның музыкаль мирасын өйрәнде, музыка уен коралларын барлады, җырлы-биюле уеннарын язып алды. Биредә татар халкының иң популяр җырлары – кыска җырлар да, тарихи һәм лирик озын җырлар да очрый. Сюжетлы җырлардан Залари поселогында Нәгыймә апа Вәлиевадан язып алынган җыр үзенчәлекле. «Авыл читендә, бабай йортында» җырында гражданнар сугышы елларында икесе ике юнәлеш алган туганнар турында сүз бара. Абыйлы-энеле кардәшләр, ике идеологияне яклап, бер-берсенә корал күтәрәләр, берсе – Советларны яклап, икенчесе – аклар ягында калып, һәрберсе үзен хаклы саный. Җырда мондый юллар бар:

– Атма, туганкай, куй
мылтыгыңны,
Мин синең энекәең бит.
– Юк минем энем,
Энем түгел син,
Бүгенге көндә без – дошман.

Иркутск өлкәсендә көйләп башкарыла торган бәетләр, мөнәҗәтләр дә язып алынды.

Тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре Наталья Гаврилова халыкның матди мәдәниятен, кул эшләрен, гамәли сәнгатен өйрәнде. Кул эшләреннән чигү, бәйләү кебек эшләрне һәр хатын-кыз белгән. Шулай ук хатын-кызлар толып (биредә аны доха диләр) теккәннәр. Ирләр тире эшкәрткән, агач эшләрен яхшы белгәннәр.

Татар халкының сәнгать югарылыгына җиткән ризыкларын әзерләү ысуллары, кунак кабул итү культурасы да Натальяның игътибарыннан читтә калмады.

Халыкның гамәли сәнгать үрнәкләре фотога төшереп алынды.

Бер яктан, экспедиция вакытында тупланган материаллар күпсанлы мәкаләләрдә, китапларда урын алса, икенче яктан, экспедициянең халыкны уятып җибәрүе, уйланырга мәҗбүр итүе дә зур әһәмияткә ия. Институт галимнәре белән аралашу нәтиҗәсендә халык үткәннәрен, нәсел тарихларын, ата-бабалары

турындагы хатирәләрен яңартып кына калмады, телдән-телгә күчеп сакланган вакыйгалар аша татарларның бай тарихлы, эшчән, һәрьяклап ихтирамга лаек халык булуына тагын бер инанды.

***Закирова Илсөяр Гамил кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*халык иҗаты бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Хисамов Олег Ришат улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фән эшләре буенча*
*директор урынбасары*

***Гомәров Илһам Госаман улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире*

## АЛТАТА АВЫЛЫ ТАРИХЫ

[Бәяләмә: Хабибуллин А.А. Алтата – татарское село
в степном Заволжье]

Артур Әхәт улы Хәбибуллинның «Идел аръягы даласындагы татар авылы Алтата» (25,34 басма табак)[1] исемле китабының уңышын тәэмин иткән беренче сәбәп, авторның, тарих фәннәре кандидаты[2] буларак, фәнни методиканы уңышлы кулланып, күптөрле чыганакларны җәлеп итеп (Саратов, Самара, Уфа төбәк архивлары, Алтата мәктәбе музее экспонатлары, өлкән буын вәкилләренең истәлек-хәтирәләре, хатлары, укучылар иншалары, халык иҗаты үрнәкләре, басма чыганаклар) эшләвендә.Уңышның икенче сәбәбе – авторның, Алтатаның үткәнен өйрәнүче дүртенче буын вәкиле буларак, авыл тарихын язуны эзлекле алып барып, аны яңа биеклеккә күтәрүдә. Биредә, беренче чиратта, Мөхәммәдфатих Кармышевның (1843–1916) шушы төбәк авылларының барлыкка килүенә һәм яшәешенә багышланган 200 битлек «Тәварих-и Алты-Ата» исемле 1910 елда тәмамлаган кульязмалары аеруча зур әһәмияткә ия. Алтата тарихын укытучылар Абдулла Нәрбиков (1894–1970) һәм Фәүзия Абдрахманова (1926–2006) да өйрәнгәннәр. Аларның язмаларын үз мәкаләләре белән баетып, А. Хәбибуллин 2007 елда «Алтата авылы. Тарих һәм халык авыз иҗаты» исемле җыентык бастыра. Ул, шулай ук, авылдашы Р.М. Ишмөхәммәдова белән хезмәттәшлектә Саратов өлкәсенең Дергачев районында яшәүче колхозчы татарларның 1941–1945 еллардагы хезмәт батырлыгы турында «Этот день вы приближали как могли» дигән китабын да 2015 елда дөньяга чыгара. Алтатага кагылышлы басмалар исемлеген алман галиме Аллен Франкның Новоузен өязе һәм Эчке казакъ урдасындагы мөселманнар тормышына багышланган хезмәте дә тулыландыра

Авторның вакыйгаларны төбәк дәрәҗәсендә тасвирлавы хезмәткә системалылык биргән. «Керештән» соң «Алтата авылы: алты атадан алып биш мәхәлләгә кадәр» дип аталган беренче бүлем төбәк тарихының борынгы чорларын яктырта, авылга нигез салынуны һәм аның үсешен тасвирлый. Кара туфраклы җирләрнең күплеге, хакимият күзәтүенең йомшак, салымнарның кайтыш булуы татарларның күченүләренә сәбәп була. Шулай итеп автор XVIII йөзнең икенче яртысыннан XIX гасыр уртасына кадәр Идел аръягына юнәлгән миграция агымнарын шәрехли.

---

[1] *Хабибуллин А.А.* Алтата – татарское село в степном Заволжье. Саратов: Издательский центр «Наука», 2017. 436 с.

[2] *Хәбибуллин А.А.* Социально-экономическое и культурное развитие татарского села в годы довоенных пятилеток (1928–1941 гг.) (на материалах Саратовского Заволжья): дис. ... канд. ист. наук. Казань, 2013. 279 с.

А. Хәбибуллин төрле төбәкләрдән күчеп килүчеләрдән авыл барлыкка килү моделен уңышлы сурәтләгән. Автор авылга нигез салган алты шәхес турында мәгълүматлары белән уртаклаша. Күченгән төркемнәр күрше община тәртибендә йортларын янәшә һәм күч сыман аерыбрак салганнар. «Югары оч»ка (Югары Кормыш очы) Пенза төбәге Кузнецк өязеннән килеп урнашалар. «Уртанчы оч»ка килеп төпләнүчеләр – XVIII гасыр азагында Хвалын өязенең Атлаш авылыннан күчеп килгән кешеләр. Алар «очы» кибетләр һәм товар складлары белән аерылып торган (биредә 3 нче гильдия сәүдәгәр хуҗалыклары урнашкан). Өченче – «Алтынбай» исемле – «оч»ка шулай ук Хвалын өязе татарлары килеп төпләнә. Шулай итеп, Алтадада өч «оч» яки өч җәмгыять оешкан, аларны уртак игенче җәмгыяте (община) берләштергән. Яңа хуҗалар укый-яза белгән кардәшләреннән һәр «оч»ка имам сайлап куялар. Бу шартларда һәр «оч»та мөстәкыйль мәхәллә оешу, һәрберсенең зираты булу төбәкчелек менталитетына корылган берләшүне аңлата.

Автор җирле җәмәгать тарафыннан сайланган имам җитәкчелегендәге рәсми булмаган мәхәлләләрнең Осинов Гай (Узин) авылы ахуны Гомәргә буйсынуын билгеләп үтә. Минемчә, бу ахун – төбәктәге руханилар белән җитәкчелек һәм җирле хакимият белән хезмәттәшлек итү өчен Оренбургтагы мәхкамә-и шәргыя тарафыннан билгеләнгән шәхес. XIX гасыр башында мәхәлләләр теркәлгән булса кирәк. Алтатага чит төбәктән муллалар килеп урнашу шушы фикерне куәтли.

Авыл халкын уку-язу, дин нигезләренә өйрәтүчеләр, әхлак тәрбиясе бирүчеләр Казан һәм башка төбәкләрдә мәдрәсәләрдә белем эстәгән шәхесләр була. Крестьян җәмгыятенә берләшеп яшәү, муллаларның дини-агарту эшчәнлеге һәм башка сәбәпләр Алтатага килеп төпләнгән кешеләр арасындагы аерымлыкларны «эретә», биредә ислам кануннары һәм яңа төбәкчелек менталитеты ныгый, шулай да кешеләрдә туган яклары һәм бабалары хакында тарихи хәтер саклана.

А. Хәбибуллинның мәхәлләләрдәге мәктәпләр тарихын яктыртуы зур уңыш буларак бәяләнергә лаек. Биредәге мәдрәсәләр (белем бирү дәрәҗәсе буенча – мәктәпләр) авыл халкы, тирә-яктагы башкортлар һәм казакълар өчен дә гыйлем учагы булып торган. Ә бердәнбер җәдид мәктәбе 1907–1909 елларда гына эшләп кала, ул кадимчеләр һөҗүменнән соң ябыла, ә укытучысы авылдан чыгып качарга мәҗбүр була.

Авторның дала шартларында тормыш итүче татарларның игенчелек белән шөгыльләнүен сурәтләве дә игътибарны җәлеп итә. Хакимият 1845 елда Алтата басуларының 2/3 өлешен күрше җәмгыятьләргә бүлеп бирә, ә аңа кадәр халык нык, иркен яшәгән дип әйтергә тулы нигез бар (1795 елда җан башына уртача 46,6 дисәтинә җир туры килгән). Мул тормыш мал-туар белән үлчәнгән: XVIII йөз азагы –

XIX гасыр башында күпчелек алтаталылар 20 дән 100 гә кадәр ат, 20–30 баш мөгезле эре терлек, 300 ләп сарык асраган. Кем күпме булдыра алган, шуның кадәр иген чәчкән. 1883 елда гына имана җирләрен җан башыннан бүлү тәртибе кергән. Игенне сату өчен иккәннәр. Әле XX гасыр башында да җирләрнең яртысы бодай басуларына туры килгән. Баштарак көзге арышны гомумән чәчмәгәннәр.

XIX–XX гасыр чигендә, халык саны арту сәбәпле, имана җире мәсьәләсе катлауланган әлбәттә. Автор татарларның чагыштырмача аз чәчеп, җирләрен арзан бәягә арендага бирү гадәтен терлек асраугa һәм сәүдә итүгә өстенлек бирүләре белән аңлата. Алтаталылырны хуторлар төзеп, аерым хуҗалык итү кызыктырмаган. Киресенчә, чәчү-уру вакытында күрше авылларга батрак булып ялланган ярлыларның имана җирендә башка милләт вәкилләре хуторлар оештырган. XIX гасыр башында атсызларның 16,8%, ә бер атлы хуҗалыклар 38,9% булуы тормыш авырайганны дәлилли (2–3 ат асраучы хуҗалыклар – 28,5%, 20 дән артык атлылары 2% булган).

Китапның иң уңышлы өлеше – 1917–1940 елларны колачлаган икенче бүлеме. Автор авыл халкының яңа сәяси һәм икътисади шартларга яраклашуын күпсанлы гыйбрәтле мисаллар ярдәмендә сурәтли. Галим илдә барган кискен үзгәрешләрне Алтата авыл җәмгыяте һәм аерым шәхесләр язмышлары мисалында тирәнтен ачып бирә алган. Алтаталыларның гражданнар сугышы елларында Кызыл Армия яклы булулары, НЭП чорында артельләргә берләшеп хуҗалык алып бару рәвеше, авыл җәмгыятендәге ярлы-ябагайның күмәк хуҗалыкка берләшүе, 1921 елда ачлыктан, 1930–1933 елларда «кулак» дип гаепләнеп Урта Азиягә күченүләре турында һәм укырга-язарга өйрәтү кампаниясе, дингә каршы көрәш, мәчетләрне һәм дини уку йортларын ябу, репрессия корбаннары, II һәм III бишьеллыкларда «Путь Ленина» колхозының эшчәнлеге хакында мавыктыргыч итеп язылган.

Бөек Ватан сугышы чоры турындагы бүлем ике теманы берләштерә: алтаталылар – сугышта һәм тылда.

Солдатка алынган 396 иргетнең яртысы гына исән-сау туган авылларына әйләнеп кайткан. Китапта сугыш кырларында ятып калган һәм исән кайткан солдатлар, шул исәптән Советлар Союзы Герое Касыйм Әхмәров турында биографик характердагы 37 белешмә урнаштырылган.

Икенче бүлектә авылда калган кешеләрнең ачлы-туклы хәлдә колхоз эшендә катнашулары, ярдәмләшеп яшәүләре, кайгы-хәсрәтне бергә күтәрүләре сурәтләнә. Бөек Ватан сугышына багышланган бүлемнең иң көчле һәм шул ук вакытта йомшак ягы – аның, башлыча, авылдашлары истәлекләре нигезендә язылуы. Бу истәлекләрдә – архивларда табарга мөмкин булмаган бик кыйммәтле, кеше хәтеренә уелып калган хатирәләр. Ләкин алдагы бүлектә сурәтләнгән колхоз

темасы 1941–1945 еллар аралыгында киселеп калган сыман. Шул хәтле тилмереп яшәп, ир туганнарын югалтып, бернигә дә карамыйча хезмәт бурычларын үтәгән алтаталыларның хезмәт уңышлары нинди? Авылда ачлык кайчан башланган? Күпме кеше туган яки үлгән? Колхозчы хуҗалыгында мал-туар, кош-корт нинди санда булган? Бу хактагы мәгълүматларны авыл советында тутырылган йорт кенәгәләреннән табып булыр иде. Сугыш чоры колхоз эшчәнлеге хакында да чыганаклар юк түгел.

Автор «Алтата XX гасырның икенче яртысында» дип аталган өч бүлектән торган бүлемен татар авылының социалистик җәмгыять шартларындагы киңкырлы тормышын яктыртуга багышлаган. Колхозның авыл хуҗалыгы өлкәсендә уңышлары, башлыча, күмәк хуҗалыкны җитәкләгән рәисләр, алдынгы тракторчылар, шоферлар биографияләре, Дергач районы газетасы «Социалистическая стройка» материаллары һәм, өлешчә, архив документлары аша яктыртыла. Игенчелек, терлекчелек тармаклары, ит, сөт, йомырка җитештерү, иген үстерү, техника белән тәэмин ителеш, хезмәтне оештыруны механикалаштыру һәм электрлаштыру, колхоз хисабына мәктәп, мәдәният йорты төзү һ.б. күрсәткечләр «Путь Ленина» күмәк хуҗалыгының алгынгылар рәтендә булуын дәлилли. Күмәк тырышлык һәм Совет хөкүмәте ярдәме белән булдырылган матди-техник нигез 1990 елларның икенче яртысыннан таркала башлый, дип йомгаклый автор.

Тормыш шартлары хакындагы теманы аерып чыгару колхозчыларның моңарчы авыл тарихларында игътибардан читтәрәк калган көнкүреше яхшыруның динамикасын күрсәтергә мөмкинлек биргән. 1950–1960 еллар башындагы хәерче тормыштан соң яшәү шартлары уңай якка үзгәреш кичерә. Китапта авыл кешеләре тормышы җиңеләя һәм яхшыра баруы хуҗалыкларның электрлы, радиолы, телефонлы, телевизорлы, мотоциклы, җиңел машиналы булулары, йортларны башта ташкүмер белән, соңрак газ белән җылытуга күчүләре, кибетләр, фельдшер-акушерлык пункты, яңа балалар бакчасы төзелү кебек яңалыклар аша сурәтләнә.

Соңгы бүлекнең үзәген 1960 еллар башына кадәр татар телендә генә белем биргән, аннан соң да милли мәгариф үзәге булып хезмәт иткән урта мәктәп һәм авыл укытучылары тәшкил итә. 2010 елдан татар телен укыту сәгатьләре кыскара башлады, дип белдерә автор. Авыл мәдәният йорты каршында эшләгән төрле түгәрәкләр яшьләрне сәнгатькә тартуда мөһим чара булган, тынлы уен кораллары оркестры, вокаль-инструменталь ансамбль авыл мәдәни тормышына яңа сулыш өргән. Мәдәният йорты кино һәм бәйрәм концертларын карау, сәяси темаларга докладлар тыңлау урыны буларак хезмәт иткән. Дини чаралар исә (1990 елларга кадәр) гаилә кысаларына уздырылган.

Китапның «Йомгагы» һәм «Чыганаклар һәм әдәбият исемлегеннән» соң кушымтада халык иҗаты үрнәкләре, истәлекләр

урнаштырылган һәм, алардан тыш, 1930–1933 елларда репрессиягә эләгеп, «кулак» буларак сөргенгә җибәрелгән (32 кеше), 1932–1937 елларда сәяси яктан гаепләнеп, җәзага тартылган (10 кеше), сугышта һәлак булганнар һәм хәбәрсез югалганнар (207 кеше), тулы булмаса да, сугыштан исән кайтканнарның (127 кеше) исемлеге теркәлгән. Дәүләт бүләкләренә лаек булган алтаталыларның да исемлекләре совет чорын хөрмәтләү билгесе булып тора. 1930–1985 елларда «Путь Ленина» һәм күрше күмәк хуҗалыкларның икътисадына кагылышлы таблицалар, авылга күченүчеләрне ачыкларга ярдәм иткән 13 нәсел шәҗәрәсе, мәчетләр, имамнар һәм мөәзиннәр исемлеге, 1940–1990 елларда өйләрдә эшләгән мәчетләр турындагы мәгълүматлар да төп текстны тулыландыручы мөһим материаллар буларак кабул ителә.

Китапта тупланган күпсанлы фотосурәтләр хакында аерым әйтү зарур. Аларда совет чоры һәм хәзерге заман авылы урамнары, җәмәгать биналары, алтаталыларның фотолары, йорт-җирләре, мәктәп, балалар бакчасы, ферма, техника паркы, колхоз идарәсе хезмәт коллективларының күмәк фоторәсемнәре, ял һәм бәйрәм итү күренешләре текстны тулыландырып кына калмый, ә мөстәкыйль тарихи чыганак вазифасын да үти.

Бер сүз белән әйткәндә, А. Хәбибуллинның китабы басылып чыгу зур вакыйга, авыл тарихы буенча үрнәк әсәр буларак бәяләнергә хаклы. Авторга, ирешелгәннәр белән тукталып калмыйча, сугышка кадәрге татар авылын һәм күмәк хуҗалыгын өйрәнү буенча методик кулланма язарга тәкъдим итәм. Мондый кулланма авыл тарихын өйрәнүчеләргә көтеп алынган затлы бүләк булыр иде.

***Заһидуллин Илдус Котдус улы,***
*тарих фәннәре докторы,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*яңа тарих бүлеге мөдире*

**2018 елның 11–14 октябрендә** Казан федераль университетының Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Күпмилләтле дәүләт шартларында туган телләрне саклау һәм үстерү: проблемалар һәм перспективалар» темасына Халыкара фәнни-гамәли форум үткәрелде.

Форум кысаларында Татарстан Республикасының халык шагыйре Роберт Миңнуллинның 70 яшьлек юбилеена багышланган «Шәрык һәм Гареб мәдәниятләре контекстында төрки халыклар әдәбияты һәм сәнгате» темасына VI Халыкара фәнни-гамәли конференция, «Мәдәниятара бәйләнешләр контекстында сәнгать һәм аны укыту» дип аталган VII Халыкара фәнни-гамәли конференция, «Мәдәниятнең рухи факторы буларак хәзерге шәһәрнең сәнгати-тарихи тирәлеген саклау» дип аталган III Халыкара фәнни-гамәли конференцияләр оештырылды, «Телләргә өйрәтүдә ачык белем бирүдән файдалану» темасына түгәрәк өстәл уздырылды.

**2018 елның 12 октябрендә** Казан федераль университетының Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында Татарстан Республикасының халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, күренекле шагыйрь, балалар язучысы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Роберт Миңнуллинның 70 яшьлек юбилее уңаеннан уздырылган Халыкара фәнни-гамәли конференция эшендә Россиянең Татарстан, Чувашстан, Марий Эл, Башкортстан Республикаларыннан, Казакъстан, Үзбәкстан, Каракалпакстан, Черногория, Азәрбайҗан, Төркиядән галимнәр катнашты.

Конференциянең пленар утырышында сәламләү сүзе белән Азәрбайҗанның халык шагыйре, филология фәннәре докторы Сабир Рөстәмханлы, филология фәннәре докторы, Баку дәүләт университеты профессоры Әскәр Рамис, Каракалпакстаннан филология фәннәре кандидаты, Каракалпакстан дәүләт университеты доценты Джумамуратова Мәликә, Казакъстаннан филология фәннәре кандидаты, Л.Н. Гумилев исемендәге Евразия дәүләт университеты доценты Кеменгер Кайырбек, Казакъстанның атказанган артисты Серик Оспан һ.б. чыгыш ясады. Аларның чыгышларында татар әдәбияты тарихында Роберт Миңнуллинның иҗаты, аның тоткан урыны бәяләнде, күпкырлы эшчәнлегенең төрки әдәбиятлар арасында нык-лы күпер вазифасын башкаруы ассызыкланды.

Чара кысаларында әдип белән очрашу һәм аның яңа китапларын тәкъдим итү оештырылды.

**2018 елның 15–18 октябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан «XXI гасырда филология һәм сәнгать белеме» темасына II халыкара яшьләр фәнни мәктәбе эше оештырылды.

II халыкара яшьләр фәнни мәктәбенең максаты фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү эшен камилләштерү, яшь галимнәрне фән үсешенең өстенлекле юнәлешләре буенча фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләргә җәлеп итү,

яшь галимнәрнең һәм аспирантларның белем дәрәҗәсен үстерү һәм аралашу даирәсен киңәйтүдән гыйбарәт иде.

Фәнни мәктәпкә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Казан федераль университеты, Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты, Башкорт дәүләт университеты, М. Акмулла исемендәге Башкортстан дәүләт педагогика университеты һ.б. уку йортларының аспирантлары һәм магистрантлары чакырылды.

Эш программасы нигезендә танылган әдәбият белеме, чыганакчылык, текстология, фольклористика, тел гыйлеме һәм туган телләрне укыту методикасы, сәнгать тарихы һәм үсеше мәсьәләләре буенча лекцияләр, семинарлар оештырылды. Фәнни мәктәп эшендә чит илләрдән (Үзбәкстан, Казакъстан, Азәрбайҗан) һәм Санкт-Петербург, Уфа, Казан шәһәрләреннән галимнәр, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, фәнни оешмалар, белем бирү оешмалары, вакытлы матбугат вәкилләре һ.б. катнашты.

Фәнни мәктәп эшчәнлеге кысаларында Казакъстанның күренекле шагыйре Магжан Жомабаевның тууына 125 ел тулу уңаеннан «Магҗан Җомабаев иҗаты һәм төрки әдәбиятлар» темасына кичә-утырыш уздырылды.

**2018 елның 16 октябрендә** Габдулла Тукай әдәби музеенда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре (З.З. Рәмиев, М.И. Ибраһимов, Ә.Х. Алиева, Г.М. Ханнанова, Р.Ф. Харрасова, Н.Ш. Насыйбуллина, А.И. Әхмәтова) тарафыннан әзерләнгән «Габдулла Тукай: тормышы һәм иҗаты (Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар (1886–1907)» китабын тәкъдим итү кичәсе узды.

Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы» исемле әлеге проектның беренче китабында Г. Тукайның 1886–1907 еллардагы тормыш һәм иҗат юлы күзәтелә. Төрле чыганаклар нигезендә шагыйрьнең Казан арты һәм Җаектагы тормышы һәм иҗаты яктыртыла. Китап татар әдәбияты тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

Басманы тәкъдим итү кичәсен Татарстан Республикасы Милли музее төп саклаучысы Л.И. Саттарова ачып җибәрде. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, профессор К.М. Миңнуллин үзенең чыгышында Г. Тукайга багышланган әлеге хезмәтнең фәнни әһәмиятенә тукталды. Кичәдә әдәбият галиме З.З. Рәмиев Г. Тукай иҗатын өйрәнү тарихына кыскача күзәтү ясады. Хезмәтнең концепциясе, структурасы һәм максатлары белән проектның җитәкчесе, китапның фәнни мөхәррире М.И. Ибраһимов таныштырды. Күренекле әдәбият белеме галимнәре Т.Н. Галиуллин, Ф.Г. Галимуллин, Х.Й. Миңнегулов, Җ.Г. Сафиуллин һ.б. әлеге хезмәткә мөнәсәбәтле фикерләре белән уртаклаштылар.

Чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, фәнни оешмалар, белем бирү оешмалары, вакытлы матбугат вәкилләре, II халыкара яшьләр фәнни мәктәбе галимнәре һ.б. катнашты.

**2018 елның 31 октябреннән 2 ноябренә кадәр** Финляндиядә «Татар мәгарифе көннәре» оештырылды. Делегация составында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Казан федераль университеты галимнәре, урта гомуми белем бирү оешмалары укытучылары катнашты.

Чара кысаларында Хельсинкидагы «Ислам җәмгыяте» бинасында Ш. Мәрҗанинең тууына 200 ел тулу уңае белән фәнни-гамәли конференция уздырылды. Әлеге конференциядә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты Д.Ф. Заһидуллина, Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры И.А. Гыйләҗев, Казан федераль университеты профессоры Х.Й. Миңнегулов һәм Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры урынбасары М.М. Гибатдинов докладлар белән чыгыш ясадылар.

**2018 елның 12–14 ноябрендә** Казан федераль университетының Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтында төрки дөньяның бөек әдипләре Аяз Гыйләҗев белән Чыңгыз Айтматовның 90 еллыгына багышланган «Аяз Гыйләҗев: дөнья мәдәниятләрендә әдипнең мирасы» һәм «Шәрык һәм гарәп традицияләре контекстында Чыңгыз Айтматов иҗаты» дигән халыкара фәнни-гамәли конференцияләр булып үтте.

Аяз Гыйләҗевкә багышланган конференция кысаларында «Аяз Гыйләҗев һәм ул яшәгән чор: татарлар һәм Татарстан» дип исемләнгән фотокүргәзмә эшләде. Әлеге күргәзмәдә язучының шәхси архивында, шулай ук фотографлар Эдвард Хәкимов, Зөфәр Бәширов, Рифкат Якупов коллекциясендә булган фотосурәтләр урын алган иде.

Конференциянең тантаналы ачылышында катнашучыларны Венгриянең Генераль консулы Адам Штифтер, Казакъстан Республикасының Генераль консулы Еркин Валитханович Тукумов, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсенең бүлекчә мөдире Рүзәл Фәиз улы Мөхәммәтшин, Казан федераль университеты проректоры Рияз Гатаулла улы Минзарипов сәламләде.

«Шәрык һәм гарәп традицияләре контекстында Чыңгыз Айтматов иҗаты» халыкара фәнни-гамәли конференциясендә Төркиядән Шурубу Кайхан, Расим Озйурук, Харун Демиркая, Казакъстаннан Жаныл Жунусова, Кыргызстаннан Садык Тиллебаев, Азәрбайҗаннан Җәваншир Мурадов, Мәскәүдән Жанна Критарова, Башкортстаннан Галимә Галина, Удмуртиядән Татьяна Зайцева, Юлия Разина, Чувашстаннан Ирина Софронова, Татарстаннан язучы Фәүзия Бәйрәмова, Фоат Галимуллин һ.б. чыгыш ясады. Аларның докладларында Ч. Айтматовның тормышы, иҗаты һәм киңкырлы эшчәнлеге яктыртылды.

**2018 елның 15–18 ноябрендә** Баку шәһәрендә Азәрбайҗан Милли фәннәр академиясенең Низами Гәнҗәви исемендәге Әдәбият институтының 85 еллыгына багышланган юбилей чаралары

үткәрелде. Аларда катнашу өчен Татарстан Республикасыннан Фәннәр академиясе вице-президенты Д.Ф. Заһидуллина һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К.М. Миңнуллин чакырылган иде. Визит барышында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән Азәрбайҗан Милли фәннәр академиясе арасындагы Килешү кысаларында фәнни элемтәләрне тагын да ныгыту һәм үстерү максатыннан эшлекле сөйләшүләр үткәрелде.

16–17 ноябрьдә узган «Физика һәм лирика: Берләшкән милләтләр әдәбиятларында һәм фәндәге дөньяви тәҗрибә һәм чынбарлык» дип исемләнгән халыкара фәнни конференциядә Казан галимнәре фәнни докладлар белән чыгыш ясады.

**2018 елның 16 ноябрендә** Мәскәүдә Россия Сәүдә-сәнәгать палатасында Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык тарафыннан «Тел сәясәте: Гомумроссия экспертизасы» темасына форум оештырылды. Форумга Россия Федерациясе Мәгариф министры Ольга Васильева, Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министры Михаил Котюков, төбәк җитәкчеләре, Дәүләт думасы депутатлары чакырылган иде. Форум кысаларында өч секция эшләде.

Әлеге чарада Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасары И.Г. Һадиуллин, Татарстан Республикасы Президенты Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментының Милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсенең баш белгече А.И. Хәйруллина, Казан федераль университетының Рус һәм чит ил филологиясе югары мәктәбе җитәкчесе Р.Ф. Мөхәммәтшина, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары О.Р. Хисамов, Татарстан халыклары Ассамблеясе Рәисе урынбасары, Казан шәһәренең 93 нче гимназиясе директоры И.А. Александровская катнашты.

**2018 елның 20 ноябрендә** татар мәгърифәтчесе, галим Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тулу уңаенан Казан шәһәрендә һәйкәл ачылды. Ачылу тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, галимнәр, дин әһелләре, язучылар һәм киң җәмәгатьчелек катнашты.

**2018 елның 20 ноябрендә** Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты тарафыннан татар галиме һәм педагогы, җәмәгать эшлеклесе Хөсәен Фәезхановның тууына 130 ел тулу уңаеннан «Татар халкының мәгарифе һәм педагогик фикере үсеше» темасына Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе оештырылды.

Конференциядә Хөсәен Фәезхановның педагогик мирасына, татар мәктәбендәге реформалар тарихына, татар мәгърифәтчеләренең мәгариф үсешенә керткән өлеше, татар студентларының чит илләрдәге уку йортларында белем алу тарихына багышланган чыгышлар ясалды. Шулай ук туган телләрне укытуга, мөселман уку йортларында яшьләргә тәрбия бирүгә бәйле мәсьәләләр буенча да докладлар тыңланды.

**2018 елның 23 ноябрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, гомуми тел белеме бүлеге баш хезмәткәре, «Татар әдәби теле тарихы», «Татар әдәби теле. Семасиология», «Төрки-татар әдәби теле нәзарияте» һ.б. фундаменталь хезмәтләре белән танылган галим Илида Басыйр кызы Бәшировага 80 яшь тулу уңаеннан оештырылган түгәрәк өстәл үтте.

Чара кысаларында И.Б. Бәширова татар әдәби теленең бүгенге торышы мәсьәләләренә багышланган лекция укыды. Шулай ук галимнең агымдагы елда дөнья күргән «Төрки-татар әдәби теле нәзарияте» хезмәте дә тәкъдим ителде.

Фәндәге казанышлары өчен юбиляр Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең көмеш медале белән бүләкләнде.

**2018 елның 30 ноябре – 1 декабрендә** Новосибирск шәһәрендә «Себер чәйханәсе» VIII Халыкара төрки халыклар фестивале узды. Чарада Россиянең төрле төбәкләреннән килгән галим-тюркологлар, фән эшлеклеләре, мәдәният хезмәткәрләре, иҗат коллективлары катнашты. Фестиваль кысаларында «Себер – Төньяк Азия төрки халыкларының мәдәни мирасы: кичә, бүген, иртәгә» темасына оештырылган IV фәнни-гамәли конференциядә Татарстан Республикасыннан Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары О.Р. Хисамов катнашты.

**2018 елның 6 декабрендә** Башкорт дәүләт университетының Стәрлетамак филиалында татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләнә башлауга 25 ел тулу уңаеннан «XXI гасырда төрки филология: проблемалар һәм перспективалар» III Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе уздырылды. Конференция эшендә Башкортстан, Татарстан һәм Россиянең башка төбәкләре, чит ил галимнәре докладлар белән чыгыш ясады.

**2018 елның 12 декабрендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Чыңгыз Айтматовның тууына 90 ел тулуга багышланган «XX гасырның икенче яртысында милли әдәбиятлар яңарышы һәм Чыңгыз Айтматов» дип исемләнгән Халыкара фәнни-гамәли конференция узды. Әлеге чараның төп оештыручысы Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты иде.

Конференциядә катнашу өчен 70 кә якын фәнни доклад кабул ителде. Конференция эшендә чит илләрдән (Кыргызстан, Үзбәкстан, Казакъстан, Азәрбайҗан) һәм Санкт-Петербург, Мәскәү, Чебоксар, Йошкар-Ола, Саранск, Ижевск, Казан, Яр Чаллы һ.б. шәһәрләрдән галимнәр, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзалары, вакытлы матбугат вәкилләре, укытучылар һ.б. катнашты.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2018. № 4

Бизәлеш авторы – Э. Бәшәрова
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 24.12.2018. Басылды: 28.12.2018.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,75. Тираж 500 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ, К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20

Журнал бушлай таратыла